Безнен
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
МИРАС
12
декабрь 2020
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Татарча талак
*4 бит*

Казан нигә җан бирде?
*16 бит*

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +
11
(324)
**декабрь 2020**

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

*Баш мөхәррир*
**Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)**
(843) 222-09-83 (17-92)

*Баш мөхәррир урынбасары*
**Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)**
(843) 222-09-83 (17-92)

Киңәшче идарә

**Ирада Әюпова**
*(ТРның мәдәният министры)*
**Айрат Зарипов**
*(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)*
**Айдар Сәлимгәрәев**
*(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)*
**Васил Шәйхразиев**
*(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)*

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

*Җаваплы мөхәррир*
**Ленар Гобәйдуллин**
89196911406

*Дизайнер һәм биткә салучы*
**Ләйлә Лерон**
(843) 222-09-83 (17-93)

*Мөхәррир*
**Ләйсән Данилова**
(843) 222-09-83 (17-91)

*Сайт мөхәррире һәм корректор*
**Энҗе Хөсәенова**
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

**«Безнең мирас» (Наше наследие)**
**Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)**

# Эчтәлек

## ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Хәсән Туфан

## ТАРИХИ МИРАС

4 Татарча талак: «Минем белән мунча кергәне юк». *Г.Хисамиев*
9 Барданың серле балбалы. *М.Госманов*
16 Казан нигә җан бирде? *Ә.Исхакый*
21 Кышкы сынамышлар. *Х.Мәхмүтов*
22 Әлифба китаплары. *Р.Мәрданов, И.Һадиев*
26 Бәрәңге хәзинәләре – Казан университетында. *Ә.Бостанов*
30 Үткәннәргә сәяхәт. *Н.Гариф*
34 Шәмсуар йолдызлыгы. *Ф.Бәйрәмова*
40 «Безнең тавыш» газетасы. *Л.Гобәйдуллин, Р.Шәрәфиева*

## ТАТАР ГАМЕ

44 Әтрәч укулары: болгар-татар нумизматик мирасы
50 Әзгәри суккан Әтрәч. *М.Вәлиев*

**Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.**
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

**«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.**

56 Әтрәч тәңкәләре. *А.Бугарчев, О.Степанов*
60 Әтрәч керәшеннәренең ислам өчен көрәше. *Э.Сәлахова*
64 Без дә ярлы түгел... *А.Әхмәтгалиева*
68 Диләрә Нәүрүзованың китап дөньясы

## ДИНИ МИРАС

74 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

## ӘДӘБИ МИРАС

80 Хәсән Хәмидулла (1960-1986) шигырьләре
84 Утыз-Имәни һәм «Госман Коръәне». *Р.Исламов*
92 Дөнья фанатлар белән матур. *Э.Шәрифуллина*

## ХӘТЕР САНДЫГЫ

96 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
98 Истә, һаман да истә!

Заказ №А-3243. Тираж – 2624 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 30.11.2020. Чыгу көне: 05.12.2020.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: татарның ике мәшһүр әдибе Хәсән Туфан һәм Гомәр Бәширов. 1973 ел. Зөфәр Бәширов фотосы

## ФИКЕР ДӘРЬЯСЫ

100 Хәтер. Р.Садриев

## СӘНГАТИ МИРАС

102 Аны яраталар иде... *Н.Сәйдәшев*
105 Сәйдәш (поэмадан өзек). *Р.Фәйзуллин*
106 Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында. *З.Гыйльметдинова*
109 «Зиләйлүк» җыры

## ШАЯН МИРАС

110 Көлке куа килә...

112 «Безнең мирас» хәбәрләре
114 «Безнең мирас» журналының 2020 елга библиографиясе
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Декабрь*

*Татар үзенең туган өенең түренә, сәхнәсенә кергәндә бүреген салмаса да, аяк киемен — кәвешен салып керә.*

*Хәсән Туфан*

Шагыйрь Хәсән Туфан белән композитор Сара Садыйкованың уртак серләре бар. 1980 ел

# Хәсән Туфан

## (9.12.1900-10.06.1981)



* * *

Философ булу кирәкмәсә дә, акыллы булу кирәк.

* * *

Язучы ул – иҗат итүче генә түгел, ул – барыннан элек, алдынгы идеяләр белән сугарылган һәм халыкның алгы сафы эчендә үзенең кайнар йөрәген факел итеп алган, халыкка җан азыгы бирә алган, бөтен тормышын шул миссиягә багышлаган кеше.

* * *

Дөньяда кешеләр бәхетен күбәйтүчеләр, халыкка бәйләм-бәйләм чәчәк өләшкән кебек, җан азыгы, шатлык, күңеллелек өләшүчеләр арасында безнең өчен байтак кадерле кешеләр бар. Алар – әдәбият, сәнгать осталары, талантлы шагыйрьләр, җырчылар, композиторлар, рәссамнар, артистлар…

* * *

Үз халкын (милләтен) ярата белмәгән бәндә – башка милләтләрне дә ярата алмый торган космополит ул. Әгәр дә мин татарны якын күрәм икән, шундый кешеләрдән торган осетин, чечен, балкар, ингуш, калмык һ.б.ларны да үз итәм. Аларның шатлыгы минем өчен дә – шатлык, кайгылары минем өчен дә – кайгы.

* * *

Безнең поэзиянең төп проблемаларыннан берсе – поэзияне «рифмоплетлар»дан – ясалма поэзиядән аралау.

* * *

Балкып, дөрләп торган шигъри хисең, фикерең була торып, аны чатак, ватык тел белән әйтү – шигырьгә генә түгел, туган теленә һәм шул ритмик телләрнең хуҗасы булган халыкның, илнең зәукына хыянәт ул.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

*Татар хатыныниләр күрми*

# Татарча талак: «Минем белән мунча кергәне юк»

**Галим Хисамиев**




**Хәбибҗамал «Эш»енең беренче бите. Башкортстан Республикасының Милли архивы. 295 нче фонд, 3 нче опись, 1326 нчы саклау берәмлеге**

## Диния нәзарәтенә рапорт

Әлеге «Эш» Чистай өязе ахуны, казый һәм Чәчәк авыруына каршы көрәш комитеты[1] әгъзасы Габдешәкүр Габдерәхимовның Диния нәзарәтенә җибәргән рапорты белән башланып китә. Анда: *«Чистай өязенең Чулпан авылыннан Хәбибҗамал Зәйнетдинова 1835 елның 22 мартында миңа мөрәҗәгать итеп, ире Габденнасыйр Габдүшевнең аны кыйнавы, аңа талак әйтүе һәм башка кыланышлары сәбәпле тикшерү үткәрүне сорап, үтенеч хатын юллаган. Аның үтенече буенча тикшерү материалларын сезнең карамакка җибәрәм. №20, 18 февраль, 1836 ел»*, – дип язылган.

Әйтергә кирәк, Кама аръягында Габдешәкүр ахун бик мәртәбәле шәхес булган, аның турында күп кенә риваятьләр таралган. XIX гасырдагы татарлар аны изге кеше – әүлия итеп санаганнар, ахунга халык ташкын булып агылган. Хәзрәтнең 1829-1846 нчы елларда Биккол авылында имамлык итүе мәгълүм. Вафатыннан соң да, шифа алу максатында, халык аның каберен зиярәт кылуны дәвам иткән.

## Хәбибҗамал: «Миңа каты холкын күрсәтә!»

Хәбибҗамал үзенең үтенеч хатында болай яза: *«Хөрмәтлеләрдән хөрмәтле ахун, казый һәм Оспа комитеты әгъзасы Габдешәкүр Габдерәхимовка! Былтыр, ягъни 1834 елның гыйнвар аенда мине, тол хатынны, Чистай өязендәге Иске Җирекле волостена караган Савин Чулпаны авылыннан йомышлы татар Габденнасыйр Габдүшевкә кияүгә бирделәр. Никах мәһәре шартлыча 100 сум булып,*

[1] Комитет 1811-1813 нче елларда оештырылган. *– Г.Х.*



**Дөрес шаһитлык бирү турында ант (сулда)**

*алардан 40 сумы акчалата, калганнары 30 сумлык соры сыер, 30 сумлык туры йонлы (гнедая) ат иде. Аларны мин, иремнең йортына күчеп килгәч, тулысы белән алдым. Тора башлагач, Габденнасыйр миңа каты холкын күрсәтә – еш кына кыйный, әшәке сүзләр әйтә, кит, сиңа миннән талак, дип, өйдән куа башлады. Башта түздем. Сентябрьдән бирле алты ай буена минем белән мунча кергәне, минем белән бер түшәктә ятканы юк. Мине хатын дип тә белми. Аның бу кыланышларын мәхәллә мулласы Мәһди Мәкъсүтовка да хәбәр иткән идем. Моның турында Габделвәли Сәфәров, Мөхәммәт исемле кешеләргә дә мәгълүм. Быелгысы елның 12 мартында, кызым Гайния Мохтарова һәм башка туганнарым белән күрешү өчен, иремнән мине Биккол авылына җибәрүен сорадым. Ул, ризалыгын бирсә дә, ат бирмәде, беренче хатыны Бәдигөлҗамал һәм кызы Фазия Габденнасыйрова каршында: «Җәяү бар, синең белән ир һәм хатын кебек яшисем килми», – дип әйтте. Мин җәяү китәргә мәҗбүр булдым. Йорттан чыккач та, Мөхәммәткә кереп, иремнең ризалыгы буенча, Биккол авылына җәяүләп, әйберләрсез китүем, иремнең ат бирмәве турында сөйләп бирдем. Биккол авылына баргач та, җәмгыять җитәкчесе Ногман Вәлишевкә барып, абыем Бикбай Биккинында кунуымны хәбәр иттем. Икенче көнне ирем, минем арттан Биккол авылына килеп, Рафик Моратов йортына чакыртып, анда мине әрли, кыйный, әшәке сүзләр әйтә: «Минем ризалыгымнан башка мыштым гына китеп баргансың», – дип, миннән мәһәр (калым) акчаларын таләп итә башлады, миңа гаеп тагарга тырышты. Бу дөрес түгел. Аның сүгенүенә, кыйнавына җәмгыять җитәкчесе Ногман Вәлишев, Ибәтулла Ишмөхәммәтов, Биктимер*



**Ахун Г.Габдерәхимовның Диния нәзарәтенә биргән рапорты. 1937 ел**

*Ишбулатов, Әюп Әхмәров, Низаметдин Абдулмәнов шаһитлар. Алар ишетеп-күргәннәрен, әйберсез килүемне раслый алалар. Югарыда тасвирлаган хатымны кабул итеп, ислам дине кагыйдәләре буенча безнең арадагы эшне тикшерүегезне үтенеп калам. Карар чыкканчы, ирем янына яшәргә кайтмаячагымны, Сезнең миһербанлы карар чыгаруыгызны көтеп калам». Хат ахырында: «22 март, 1835 ел. Үтенеч хаты Чистай мещаны Павел Сурков тарафыннан язылды, Хәбибҗамал Зәйнетдинова үзенең* ***«Х»*** *рәвешендәге тамгасын куйды»,* – диелә.

## Габденнасыйр: «Хатыннар арасында тигезлекне сакладым»

«Эш»тән күренгәнчә, ахун хәзрәтләренең тикшерү, сорау алу, документ язу тәртипләре шул чордагы дәүләт органнары, полиция чиновниклары – приставларныкыннан бер дә аерылмый. Ул 1835 елның 15 июлендә Хәбибҗамалның ире Габдүшевтән сорау ала: *«Мине Габденнасыйр Габдүш улы дип атыйлар. Миңа 40 яшь, штрафка һәм хөкемгә тартылганым булмады. Чыннан да, 1834 елда Хәбибҗамалга өйләндем, мәһәр – 110 сум, шулардан 50 сумы акчалата, 60 сумлык җирән бия һәм бер чуар сыердан иде. Миңа күченеп килгәч тә, аны «сөйрәлчек», «күркә» дип атамадым, кыйнамадым, бервакытта да аңа талак әйтмәдем, хатыннар арасында тигезлекне сакладым. Ни сәбәптәндер, мин өйдә булмаган чакта Хәбибҗамал Биккол авылына качып киткән иде. Икенче көнне мин аны Рафик Моратов йортында эзләп табып, өйгә кайтырга чакырдым, тик ул катгый*

*рәвештә кайтмас булды. Мин ул чагында аңа бернинди зыян салмадым, сукмәдем, кыйнамадым, «сөйрәлчек», «куркә», «кәфер» дип, талак та әйтмәдем. Ул шулай Биккол авылында калып, шунда яши. Милеккә килгәндә, мендәрләр белән ястыктан (16 сум 60 тиен), ике сыер (60 сум), тайлар белән бия (30 сум), ике сарык (10 сум), йозагын ватып сандыктан алынган өч күлмәк, камзолдан тыш башка әйбер юк. Хәбибҗамал үзе белән бер алтын полуимпериал[2], ике бер сумлык металл акча алып киткән. Тик моны раслый алмыйм»,* – дип җавап тоткан һәм беркетмәгә ***«Х»*** рәвешендәге тамгасын куйган. Сорау Габдүшев ягыннан, аның туганнан туган энесе Бөркәй Монасыйпов, Хәбибҗамал ягыннан – Биккол авылыннан Сәйфелмөлек Рафиков катнашында ахун Габдерәхимов тарафыннан алынган.

Чулпан авылы мулласы Мәһди Мәкъсүтов ахун Габдерәхимовка язган аңлатмасында: *«Бу авылның йомышлы татары Габденнасыйр Габдүшевнең хатыны Хәбибҗамал Зәйнетдинова иренең кыйнавы, сүгенгәне турында 1834 һәм 1835 елларда миңа хәбәр иткәләгән иде. Тик алар арасындагы ызгышның ни сәбәптән булуы миңа билгесез»,* – дип язган, күрсәтмәләрен имзалаган.

Шуннан соң, ни сәбәптәндер, тикшерү эшләре янә ярты елдан соң гына дәвам ителгән. Биккол җәмгыяте җитәкчесе Ногман Вәлишев: *«Миңа 30 яшь, штрафка һәм хөкемгә тартылганым булмады. Чыннан да, 1835 елның март аенда мин җәмгыять җитәкчесе идем, Чулпан авылыннан килеп, Хәбибҗамал миңа Бикбай исемле абыйларында төн кунганын әйтте. Икенче көнне аның ире Габденнасыйр Габдүшев, имеш, хатынын эзләп килгән. Аны тапканнан соң, ул кешеләр алдында аны мыштым гына качып киткәне өчен әрләде, мәһәр акчаларын кире кайтаруны таләп итте. Соңыннан: «Кит минем яннан, сиңа миннән талак», – дип әйтте, аны кыйнады, төрле әшәке сүзләр кычкырды, мин Хәбибҗамалны анардан авылдашларым ярдәмендә генә аерып алдым, шуннан соң да Габдүшев аны куркытырга, кисәтергә омтылды»,* – дип җавап тотып, үзенең тамгасын куйган.

Соңыннан 62 яшьлек Әюп Әхмәров тә, 22 яшьлек Низаметдин Абделмәнов та, 35 яшьлек Биктимер Ишбулатов та, 98 яшьлек Ибәтулла Ишмөхәммәтов та ахунга: *«Без анда булдык, Ногман Вәлишев сөйләгәннәр барысы да дөрес, без Габдүшевнең кыланмышларын күреп, ишетеп тордык, башка нәрсә өсти алмыйбыз»,* – дип җавап биргәннәр.

Шул ук шаһитлар өч көн алдан, ягъни 15 февральдә: *«Биккол авылына хатыны Хәбибҗамалны эзләп килгәч тә, Габденнасыйр Габдүшев хатынының бер алтын полуимпериал һәм ике бер сумлык акча алып китүе турында хәбәр итмәде, ә безнең алда хатыныннан акча таләп итә башлады, урлау-югалту булмады. Зәйнетдинованың милке югалмаган, нәрсәгә соң аны эзләргә, дип әйтүен без ишеттек»,* – дип җавап бирәләр һәм үзләренең тамгаларын куялар.

## Диния нәзарәте: «Йәмәни мугалләзи» антын бирдертергә!

Диния нәзарәтендә «Эш» 29 июньдә тыңлана. Анда: «Шаһитлар Габденнасыйр Габдүшевнең сүгенүләрен һәм хатынын кыйнавын раслап торалар», – диелә. Хәбибҗамалның рөхсәт алдым дип баруын, ә иренең рөхсәт бирмәдем диюен, аларның бер-берсенә сылтавын һәм икесенең дә моны раслаучы җитди дәлил китерә алмауларын исәпкә алып, Диния нәзарәте: *«Шәригать кануннарына*

[2] Россиядә 1755 елда 5 сумлык 190/96 мыскал авырлыктагы акча 88 нче пробалы алтыннан сугылган. 1817 елдан 1885 елга кадәр сугылган полуимпериал 147/88 мыскал торган; 1 мыскал = 4,266 г. ***– Г.Х.***

*таянып, дөреслекне ачыклау максатында, ягъни аның хатынына рөхсәт бирүбирмәве турында хатыны Хәбибҗамал каршында Габденнасыйр Габдүшевтән «Йәмәни мугалләзи» антын бирдертергә, бу эшне Диния нәзарәте ышанычлысы – ахун һәм казый Габдешәкүр Габдерәхимовка тапшырырга»,* – дигән карар кабул иткән. Карар ахунга 24 августта җибәрелгән.

Ахун Габдерәхимовның 1837 елның 1 ноябрендәге рапортында: *«Диния нәзарәтенең указын үтәмәк өчен Чулпан авылыннан Габденнасыйр Габдүшевкә берничә тапкыр күрсәтмә җибәрсәм дә, ул «Йәмәни мугалләзи» антыннан баш тартты, янәсе, Зәйнетдинова аңа хатын түгел, янәсе, аның башка хатыны бар. Шул сәбәпле указны үти алмыйм»,* – диелә.

1838 елның 17 мартында Диния нәзарәте утырышында ахунның әлеге рапортын карап чыкканнан соң: *«Хәбибҗамалның иренә карата дәгъвасы булмавын, иренең башка хатын белән яшәвен, икесенең дә аерылышуга риза булуларын исәпкә алып, Хәбибҗамал һәм Габденнасыйрның никахын юкка чыгарырга, моны метрика кенәгәсенә теркәп куярга»,* – дигән карар кабул ителгән.

* * *

Архив документыннан күренгәнчә, татар җәмгыятендә аерылышу процессы, күпләр уйлаганча, өч мәртәбә талак әйтү белән генә чикләнмәгән, ә шактый катлаулы күренеш булган. Аеруча мал-мөлкәт бүлү белән бәйле «Эш»ләр озак вакытка сузылган. Мәсәлән, 1835 елның 22 мартында башланган әлеге аерылышу процессына 1838 елның июлендә генә нокта куела, ягъни Хәбибҗамал белән Габденнасыйрга гаилә хәле акты хәбәр ителеп, метрикага теркәлеп, бу хакта Диния нәзарәтенә рапорт бирелә. Шулай итеп, бер ел дәвам иткән никахны (1834-1835) таркату өчен өч ел вакыт (1835-1838) үтеп китә!

**«**

**Ә менә тикшерү һәм аеру (талак) процессында дин әһелләренә, аеруча казыйларга полиция функциясен дә башкарырга, аерылышачак парларның интим тормышына кадәр үтеп керергә туры килгән.**

Мондый эшләр шактый катлаулы булганлыктан, әби-бабаларыбыз аерылышып мәшәкатьләнмәгән, түзгән, сабыр иткән. Хатын бик зирәк яки хәйләкәр булган очракта гына явыз иреннән котыла алган. Килешәсездер, төбәкнең иң дәрәҗәле кешесе янына – ахунга килеп: *«Минем белән мунча кергәне, йоклаганы юк»*, – дип дәгъва белдерү (ә бәлки, ялганлау), шаһитларны үз ягыңа күндерү өчен шактый тәвәккәллек һәм җитезлек кирәк! Ә менә тикшерү һәм аеру (талак) процессында дин әһелләренә, аеруча казыйларга полиция функциясен дә башкарырга, аерылышачак парларның интим тормышына кадәр үтеп керергә туры килгән. Бу эштә алар аеруча зур җаваплылык тоеп хезмәт иткән, чөнки Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткән, әмма Ул иң яратмаган гамәлләрнең берсе – талак. ■

*Археографик көндәлек*

# Барданың серле балбалы

Миркасыйм Госманов

## *IV сәфәр*



**Миркасыйм Госманов серле ташны өйрәнә**

### Пермь өлкәсе, Барда районы

6-22 июль, 1965 ел

*Бу юлы без Пермь өлкәсенең Барда районында яшәгән татарлар арасында кульязмалар эзләргә булдык. Юлга өч кеше әзерләндек: мин, Камил Дәүләтшин һәм Рита Сабитова. Соңгы туташны кыстырудан сәбәп – ул Барда районы кызы, районны яхшы белә. Идея буенча, безгә яхшы юлдаш, файдалы киңәштәш булырга тиеш.*

*Бу төбәкне сайлауда тагы бер сәбәп бар. Ул да булса – Камил алып кайткан бер мавыктыргыч хәбәр: имештер, Барда районыннан татар авылларының берсендә җир казыган чакта әллә нинди «серле язулы» таш чыккан. Аны күп кешеләр күргән, имеш... вә әлх!.. Менә шул ташны да эзләп табасы килде. Һәм без юлга әзерләндек. Шуны да әйтергә кирәк: хәбәрне китерүче Камил булган кебек, сәяхәтне тырышып әзерләүче дә Камил иде. Шулай итеп, рун язуын эзләп тапмак булдык. Безнең фикерләр бик гади: бик борынгы гасырлардан башлап төрки халыклар яшәгән Уралда руник язулар табылса, бер дә гаҗәп түгел! Әйе, бу, чыннан да, гаҗәп түгел!*

***6.07.65.*** Көндезге сәгать 12дә, «Писанский» дигән иске генә бер пароходка утырып, юлга чыктык. Өчәү идек. ЛәкинРитаның егете Марсель Сафуров та безгә кушылды. Ул Чистайга хәтле безнең белән барачак...

Сәфәр күңелле генә башланды: ресторанга кереп, затлы тәгамнәр, тәмле шәраплар алып, «хәерле сәфәр» өчен утырдык. Барасы шактый иде: Пермь шәһәренә 9 июльдә генә җитәчәкбез...

Әйләнә-тирә күңелле генә. Каманың югарырак ягына күтәрелгәч, тагы да күңелле булды. Ләкин пароходта гел карт-корылар гына...

***9.07.65.*** Иртәнге 7дә Пермьгә җиттек. Иң элек аэропортка барып, Бардага китәр өчен билетлар алдык. Аннары шәһәргә барып, Облисполкомга кереп, тиешле кәгазьләрне әзерләдек.

Пермь алаша гына бер шәһәр икән: ярты авыл, ярты шәһәр. Иске агач йортлар, бик пычрак. Шулай да бер «Иван кисәге», бик горур гына итеп: «У нас в Перми очень культурно!» – дип масайды. Мескен, күрәсең, без кара кешеләр булгач, ул безне кыргый азиатлар дип уйлады бугай. Их, һәрбер кырмыска үз түмгәген Памир дип белә бугай!

Бардага киттек. 45 минут очтык. Авыл матур гына тәэсир уятты: Тол дигән матур гына су буенда. Әйләнә-тирә урманнар, сөзәк зәңгәр таулар… Серле генә, моңлы гына табигать… Белгәннәр утырасы җирне!

Бардадан 2 км җирдә Риталар авылы – Әрҗән (русча Краснояр). Авыл бик матур икән. Халыкның тормышы дә ярыйсы сыман: гел яңа йортлар.

Безне бик ачык чырай белән каршы алдылар. Мул табын күптән әзер иде. Бигрәк тәРитаның әнисе җилбәрләнеп каударланды. Кәшифә апа бик күңелле кеше икән.

Мунча кердек.. Чабындык… Җирле вакыт белән төнге 3кә хәтле әче бал эчеп утырдык. Шактый эчелде. Ә иртәгә әлеге «серле таш» булган Акбашка барырга тиешбез…

***10.07.65.*** Районга (ягъни Бардага) килеп, колхозның партком секретаре Байназар Юлаев дигән кеше белән сөйләштек. Яхшы гына хәбәрдар кеше. Ул да әлеге таш турында ишеткән. Безгә ышанычлы координатларны әйтте. Бигрәк тә Таһиров Рифкать дигән мәктәп укытучысын тәкъдим итте. Ә таш исә Мурзаева Роза дигән хатынның йортында баз казыган чакта табылган булган…

Барырга лаек дип берничә авылны да атады.

Төштән соң колхоз парторгы биргән машина белән Акбашка киттек. Юл гел урман ерып барды. Юл бик матур иде. Әйләнә-тирә урман, сөзәк зәңгәр таулар. Тау арасында бормаланган йомшак юл. Һәрбер 4-5 км саен бер авыл. Авыллар зур һәм шактый хәлле генә. Иске агач йортлар бер дә юк диярлек, булса да бик сирәк. Йортлар биек, барысы да таза такталар белән ябылган. Акбашка килеп, фатирга урнаштык.

Шаккатыргыч: һәммә җирдә пөхтәлек, тазалык, чисталык; өйләрнең идәннәре гарәбә кебек сап-сары итеп юылган – ятып аунарлык чиста. Бусагага җитү белән үк түфлиләр үзләреннән-үзләре аяктан төшәләр… Хәтта бәдрәфләренә дә аякларны салып керәсе килә. Бу һәрбер авылда шулай иде.

Эзли торгач, Рифкать Таһировны эзләп таптык (кинодан чакырып чыгардык). Ул шунда ук әлеге ташны үзе күрүе, анда бик ачык язылган серле язуларның булуы турында «күкрәк сугып» сөйләде.

Бергә-бергә Рифкатьләрнең сеңлесе Роза Мурзаевалар йортына киттек – таш шулар базыннан чыккан бит!

Базны карадык. Тыңладык. Шул арасында бер малай бакча казыганда табылган бер таш кисәге китерде. Ә өстендә берничә хәреф бар иде – руник хәрефләр, менә «р» хәрефе! Шауладык, гөрләдек, борын заманда басып торган балбалларны, андагы язуларны күз алдына китердек.

Ә ташлар, әлеге язулы ташлар кайда икән соң? Алар хәзер Роза Мурзаеваның каенише Рафаэль дигән егетнең йорт нигезендә яталар икән. Баздан таш чыккач (дүрт зур таш бит!), Рафаэль, абыйсына бер ярты куеп, аларны үзенә алып кайта: лом белән чукалап, балта белән аугып, урам буйлап тәгәрәтә һ.б.

Шуларның йортына килдек. Менә нигез почмагыннан бер ташның кырые күренеп тора… Рафаэль элек безне якын җибәрергә дә теләмәде: сүз чыгу белән

үк: «Бу гади ташлар, анда бернинди язу юк!» – дип киреләнеп маташса да, безнең сүзләрдән үзе дә кызып китеп, ташны, андагы иске «язулар»ны, ул ташларның формаларын үзе үк мавыгып тасвирлый башлады. Әлеге ташларның берсендә болан кебегрәк бер җәнлек рәсеме дә бар, имеш! Ә язулар уртадагы ташта берничә юлдан гыйбарәт булган.

Без тыңладык кына. Рифкать тә, Рафаэль дә мавыгып сөйләделәр. Камил белән без үз планнарыбызны ачып салмадык. Бары, сүз уңае китереп, танышлык өчен эчеп алырга булдык һәм сумкабыздан бер «кызылбаш»ны чыгардык. Хуҗаның йөзе яктырып китте. Сыттык шешәне.

Фатирга киттек. Төн бик матур иде.


IV сәфәр
Пермь өлкәсе, Барда р-ны
6 – 22 июль, 1965 ел.

***11.07.65.*** Без, Камил белән икәү, балбал чыккан җиргә килдек. Хуҗалар өйдә юк иде.

Манзараны күзәтеп, үзебезгә шул төбәкнең «план»ын алдык.

Уймуж* дигән (русча Пермячка) суның озынлыгы нибары 12-15 км булыр. Шул Уймужның (ул җәйләрен кибеп бетә яза икән) төньягында – елгадан 25-30 метрга калкып торган яссы тау. Шул тауның инештән 10-12 метр биеклектәге көньяк (инешкә караган) итәгендә, 1958 елны Мөнир Мурзаев баз казыган вакытта, бер метр тирәнлектән әлеге хикмәтле ташлар чыга – дүрт таш. Һәм алар хәзер Рафаэль Мурзаев йорты нигезендә яталар.

Нигә нәкъ шушы төшкә балбал куйдылар икән? Әлбәттә, төгәл җавапны бары археологик казулар нәтиҗәсендә генә табып булачак. Шулай да кабер өстенә куелганмы? Ләкин шунысы гаҗәп: ник тауның өстендә үк түгел ул? Аннары, кабер булса, ник түбәнге, сайдан гына су чыга торган җиргә куймаганнар? Минемчә, бу ташлар, ягъни балбаллар кабер өстенә түгел, бәлки, гыйбадәт урынына куелган булырга тиеш.

Әйләнә-тирә матур гына. Көн җилле генә иде. Күптән яңгыр булмаганга, һәр машина узган саен, авыл тузанга күмелеп кала. Ә күктә ак болытлар көтүе.

Тау битеннән казып ком алган җиргә карыйбыз. Якынча ярты метрлы кызыл туфрак, аннары ком башлана. Ә берәр метрдан ком бөтенләй юеш, ботка хәленә килә. Димәк, су, югарыда әйткәнемчә, бик сайдан гына. Ерак түгел генә чишмә дә чыгып ята. Шулай, биредә кабер булу ихтималдан бик ерак. Ә көн, һава җилле булуга карамастан, әллә ничек күңелле иде.

...Халык телендә авыл турында түбәндәгеләр сөйләнә. Имештер, Болгар чоры заманында шул яклардан бер Акбаш исемле кеше килеп, калын урманнар куенына яшеренеп, юлбасарлык белән шөгыльләнеп яткан. Соңрак аны тотып үтергәннәр, аның йортының урыны да билгеле икән, имеш... Авыл исеме исә шул Акбаштан калган.

* Уймуж – Олы Әмҗе / Большая Амзя елгасының кушылдыгы.



**Көндәлекнең ташны тасвирлаган бите**

Халык телендә Пугачев, Салават исемнәре дә еш яңгырый. Салават бу якларны шактый айкап йөргән. Бирегә башкортлар да шул вакытларда килгәннәр, имеш, һәм татарлар белән аралашып яши башлаганнар. Бу дөрес булу бик ихтимал: халык, үз теле буенча башкорт булмаса да, сөйләшүе белән башкорт элементларын шактый саклаган. Бигрәк тә сузык авазлар системасында. Ләкин әдәби телне бик яхшы беләләр.

Кичен Рафаэль Мурзаевны бик озак яучыладык: көчкә-көчкә күндереп, фундаментны казый башладык. Бер ташның әйләнә-тирәсен туфрактан арчыдык. «Тасвирламалар»га нигезләнгәндә, бу өстәл өчен таш булырга охшый. Ләкин язу-мазар юк. Аны шул килеш калдырып, икенче почмакны казый башладык. Бу озынча таш икән. Тик анда да язу юк. Гаҗәп!.. Күзләрне чекерәйтә-чекерәйтә язу эзлибез, мәгәр, нәтиҗәсез… Гаҗәп, язу иң астагы ташта микән?!.

Караңгы төшә башлады. Фатирга кайттык. Арылган иде.

***12.07.1965.*** Өченче, дүртенче почмакларны да казыдык. Ләкин ташларны чыгармадык, чөнки хуҗаларның беркеме дә өйдә юк иде… Читтән караганда, язу-мазар юк иде. Кая киткән соң ул?!.

Урманга барып җиләк җыйдык. Урман әкияттәге кебек шәп иде: бил тиңентен яшел үлән, аның өсте исә, тигез үскән җире, ак чәчәктән ак җәймә ябылган сыман!.. Ә каеннар!..

Инеш буена төшеп су коендык. Кояшта кызындык. Бүген көн шундый ачык, шундый саф иде. Күктә бер болыт әсәре дә юк. Ул зәп-зәңгәр…

Төшке чәйдән соң, иске кулъязмалар эзләп, Рәхилә абыстай дигән карчыкка бардык. Ләкин рәтле бернәрсә дә чыкмады. Дөрес, бер «прокламация» бар, имештер, тагы ике елдан… ахырзаман була!.. Бу гыйлем өчен түгел, «Чаян» өчен генә ярарлык!

Кичен тагын әлеге эргәндәге ташлар тирәсендә дүрт аяклап йөри башладык. Ятып та карыйбыз – нәтиҗәсез. Рифкать тә аптырый. Үзе күргән язуларны таба

алмый. Ә Рафаэль исә мыек астыннан гына елмаеп куя: «Әйттем бит, бернәрсә дә юк дип!»

Юк, без иртәгә бу ташларны тагы тикшерәчәкбез!

***13.07.1965.*** Тагы ташка киттек. Бик тырыша торгач, зур ташны чыгардык. Ләкин, һәй-һәй, аның акбур измәсенә яткызган аскы ягы бөтенләй кубып чыкты! Бармак калынлыгы бер катлы таш кубып чыгып, җиргә ишелеп төште... Икенче зур ташны да чыгардык: аның да бер ягы суелган чыкты – бөтен катламы белән. Йомшак известняк менә шулай бик тиз, гаҗәп җиңел суела икән!..

Хәзер аңлашыла: язулы яклар измә өстенә куелган һәм аннары ябышып катканда суелып юкка чыккан.

Менә шулай. Язу табылуга өмет калмады. Ничә айга татлы хыяллар, 4 көнлек җир казу, көчәнү – барысы да җилгә китте.

Шулай да ташларның шәкелен ясап алдым (күләм см белән күрсәтелә).

Бу, әлбәттә, ташларның характерыннан чыгып ясалган фаразлы реконструкция генә. Үлчәгән вакытта бу ташларның бик пөхтә эшләнгән булуы беленде. Аскы ике ташның арткы ягы эшкәртелмәгән, димәк, ул җиргә күмелгән.

Фараз буенча, язу уртадагы ике ташта булырга тиеш. 2 нче ташта тукылган эзләр бар, ләкин алар соңгы вакытларда бик нык бозылганнар – аның йөзеннән бармак калынлыгы катлам суелган... Аскы ике таш та бик нык какшаган.

Шулай «язу»лар җилгә очты, алар белән матур өметләр дә... Бәлки, андый язулы ташлар киләчәктә тагы табылырлар?!. Ярар, әмма бу ташларда язуның булуы бик ихтимал иде! Бер генә кеше күрмәгән бит аны. «Язу»ны шул елларда район газетасында эшләгән Рафаэль Нурсубин күргән, ул, имеш, аны фотога да төшереп маташкан. Аннары тере шаһитебез – Рифкать, Рафаэль Мурзаевның үзе. Аның атасы Сабир Мурзаев та ул язуны «укып» маташкан. Үзе әйтте. (Ә хәзер кулларын гына җәя!) Бу кешеләрнең барысы да үзләре күргән нәрсәләрне сөйлиләр. Алар белән аерым-аерым сөйләштек. Барысы бергә ялганлавы мөмкин түгел ләбаса! Кыскасы, язу булган һәм ул юкка чыккан. Дөресрәге, «һәлак булган»...

Су буена киттек. Коендык. Кызындык. Ә һава ут иткән кебек шәп иде!

Төштән соң бер-ике картка кереп, кулъязмалар карадык. Нәтиҗә биредә дә начар...

Ә кичен, кичен йортның нигезләрен күмдек. Өметләрне, хыялларны да бергә...

***14.07.1965.*** Авыл советына килеп, иртәгә кайту турында сөйләштек. Шулай, иртәгә китәбез. Соңгы көн дип озак кына ял иттек. Бераз балык та чирттердек. Көннәр гаҗәп матур иде, каһәр!..

Кичен тагын берничә йортка кереп, кулъязма теләнеп йөрдек. 1-2 нәстәкәй бар. Гарәп теле буенча дәреслекләр. Шәкертләр сукалаган. Минем уйда һаман «руник» язулар.

Бер фикер куәтләнә бара: аларны Рафаэль үзе үк юк итмәде микән?.. Рифкать болай ди: «Беркөнне Рафаэль шул ташларны үз йорты янына ташып маташканны күргәч, мин, аны барыбер алачаклар, дидем, – язулы әйберне синең эргәңдә калдырмаслар!» Моңа каршы Рафаэль: «Ничево, ул анда вечно ятачак!» – дип җавап биргән. Гомумән, сары танау Рафаэльнең гел киреләнеп, ара-тирә мыек астыннан көлеп йөрүе дә бик шөбһәле...

Әйе, язулар булган! Бәлкем, киләчәк бу фикерне тулысынча раслар! Моңа мин бик ышанам!

***15.07.1965.*** Акбаштан киттек. Матур, тыныч авыл, саф инеш, яшел болыннар, калын, серле урманнар артта калды. Алар белән татлы хыяллар да...

Бай (Куземьярово) авылы шактый олы гына икән, 350-400 йорт. Элек авылда 3 мәчет, 3 мәдрәсә булган. Тирә-яктан җыелган шәкертләр шунда укыганнар.

Мансуров Лотфулла дигән берәүләрдә тукталдык. (Пединститутта укый торган бер кызы бар икән.) Бер кулъязма да табылмады: халык, нигәдер, бик куркак, йомык, хәтта күрше күршесе турында сөйләүдән баш тарта. Кайберәүләрнең әйтүләренә караганда, теге елларны бик өркеп, бик куркып калган булырга тиеш. Шулай мөдһиш 30 нчы еллар әле дә халык күңеленнән чыгып бетми...

Азметов Госман дигән бер укытучыны эзләп барган идек. Имеш, тарихны яхшы белә, дип. Ул шыр исерек иде. Өстәвенә, сагыз кебек бәйләнүчән. Тәмам теңкәгә тиде үзенең әшәке балы, сасы аракысы белән.

***16.07.1965.*** Бүген көне буе өйдә аунап яттым: бик каты салкын тигән – сызламаган төшем юк... Чак кына йокыга китсәм, шыбыр тиргә батам. Бил бөтенләй каткан.

Кичен берничә өйгә кереп чыккан булдык. Бер иләмсез кулъязма да бар. Ләкин хәл бик мөшкел...

***17.07.1965.*** Бүген кәеф шәп кенә, арурак. Юлга чыктык. Бу авылда, шулай итеп, ике куныпп, бер чирләп, шактый сасы сыра эчеп киттек (әшәке тәме һаман авызда!..).

Җәяүләп кенә Чуашаево дигән бер бәләкәй генә сәләмә авылга килдек. Шактый йөргәч, Акбаев Вахит дигән йөзне узган бер картка кердем – мәгънәсез...

Каен (Березники) авылына юнәлдек. Анда Актукаев Мортаза дигән бер агайга кереп, бераз ял итеп, чәй эчеп алдык. Кулъязмалар турында әллә нәрсәләр ишетелми. Аны-моны сөйләгән була, ләкин конкрет бернәрсә дә юк. Имештер, Удик (Елпачиха) авылында Арзыев Сәлим дигән кешедә (укытучы) авыл тарихы бар.

Көч-хәлгә Әрҗәнгә кайтып җиттек. Рита безне көтә-көтә алҗып беткән икән. Сөйләп бирдек хәлләрне. Кичен мунча кердек. Кергә-тузанга билдән баткан идек. Күлмәк-ыштан 4-5 көндә каешланып каткан иде. Ләкин бүген Камилнең хәле хөрти: ашказаны борчып тора. Хәер, иртәнге көн өчен ишәк кайгырсын, ә бүгенгә изрәп йокларга кирәк...

***18.07.1965.*** Мунчадан соң бик озак йокланган. Арылганлык та үзен сиздергән... Ләкин Камилнең кәефе начаррак. Ул бүген беркая да бармас. Ә мин юлдан бер машина тотып, Удик (Елпачиха) авылына киттем. Тарих укытучысы Нургали Багиров дигән кешене таптым. Аның сөйләвенә караганда, бу яктагы халыкның бер өлеше булган башкортлар (хәзер алар татарлашып беткәннәр) Гайнә дигән бабадан таралган, имеш. Шуңа күрә Гайнә башкортлары дип атала. Алар Пугачев явыннан элек килеп урнашканнар. Шул ук вакытта (бәлкем, аннан элек) Кама буйлап татарлар да килеп утырганнар.

Барда районында элек зур сәүдәгәрләр, танылган байлар булган. Үдиктә элек бер мәдрәсә булган, мәчет янында.

Нургали абзый белән авыл уртасындагы зиратка килеп, бер таш карадым. Аның бик күп сүзләре җуелып беткән, бары «1177» һәм «Халид бин...» дигән сүзләрне генә укып булды. Димәк, таш 1762 елда куелган...

Арзыев Сәлим дигән кешегә килеп (яшь кенә), бик озак сәүдәләшә торгач, аның сандык төбеннән «Барда ягы тарихы»н алдырып карадык. Яңа дәвер

кулъязмасы – 1940 нчы еллардан соң аңлы гына бер һәвәскәр тарафыннан язылган (реформадан соңгы гарәп хәрефләре белән…). «Тарих»ның нигезендә риваятьләр һәм китаплардан алынган кайбер мәгълүматлар ята. Монда да сүз килеп утырган татарлар һәм башкортлар турында бара. Әһәмиятле моментлар:

а) башкортлар килеп утырганда, бу җирләрдә арлар һәм финнар яшәгәннәр;

б) беренче дата итеп 1470 ел алына;

в) башкортларның килүенә, имеш, монголлар сәбәп булган… Шул ук вакытта Кунгур татарлары да килеп утыра башлаганнар;

г) 1552 елны Казанга ярдәм итәр өчен Кама (Чулман) буйлап баралар. Ләкин соңарып баралар.

Кулъязманы алу турында сүз дә буласы түгел – Сәлим аңа теш-тырнагы белән ябышып каткан… Бәлки, киләчәктә бирер?..

Кичен Әрҗәнгә кайттым.

***19.07.1965.*** Чәйләп-мәйләп, хуҗалар белән саубуллаштык. Кәшифә апа улларын озаткан кебек калды. Кияве (кызы Лилиянең ире) Габделхәй Назаргуловның мотоциклы белән районга килдек. Райкомга саубуллашыр өчен кергәндә, Имайкап Зәбир дигән кеше белән сөйләштек. Акташтагы язулы ташны, андагы язуларны ул да күргән! Партия инструкторы башы белән ялганламас бу кеше! Их!

Габделхәй белән тагын бер шешә «сыттык». Оса шәһәренә киттек. Бик әшәке юл. Машинаның брезент фургоны кара туфрак белән тулды.

Осада гостиницада туктап, бер-ике сәгать ял итәргә булдык. Ләкин бер дә йоклап булмады. Төнге 12 сәгатьтә пристаньгә килеп, төне буе чиратта тордык… Залда сасы, ә тышта салкын…

***20.07.1965.*** Иртәнге 5тә генә «Добролюбов» пароходына утырдык. Душка кереп юынып чыккач, озак кына йокладык. Ләкин минем кәеф начар: ару, борчылу, әллә нинди мәгънәсез «бал»лар, әшәке аракылар белән агуланулар үзләрен сиздерәләр иде… Эчсәң – бер бәла, эчмәсәң – ике, хуҗалар үпкәли. Тьфу бу «кунакчыллык»ка! Нихәтле мәгънәсезлек…

***21.07.1965.*** Кич белән Чистайга җитеп, Камилнең әтиләрендә туктадык. Көн бик салкын иде. Кичен Камилнең әтисе Салих абзый белән озак кына сөйләшеп утырдык. Ичмасам, бүген ял булды: аракы белән кыстау юк!

***22.07.1965.*** Мәчет мулласы ялга киткән булып чыкты. (Гаҗәп, муллага ни пычагыма ял?!) Шулай итеп, монда да юллар уңмады.

Бүген үк Казанга китәр өчен самолетка билетлар алдык. Кичкә хәтле Чистайның пычрак урамнарында йөрендек. Кичен өйдә булдым.

Экспедиция менә шул ярлы гына нәтиҗәләр, җимерелгән хыяллар белән очланды. «Теоретик» йомгаклар ясап торырга кирәкми дә кебек. Шулай да:

1. Киләчәктә бу якларда язулы ташларның табылуы бик ихтимал. Сак булып торырга кирәк…

2. Кулъязмалар табылу турында әллә ни өметләрем юк: бик таланган як.

3. Халык рухи җәһәттән бик караңгы, ләкин матди яктан шактый хәлле яши. Яхшы гына куркак…

*Көндәлекне басмага **Диләрә Госманова** әзерләде.* ■

# Казан нигә җан бирде?

**(Ризаэддин Фәхреддиннең Орск мөселманнары белән очрашуы)**

**Ризаэддин Фәхреддин. Уфа, 1892 ел**

*Дин галиме һәм мөхәррир Ризаэддин Фәхреддин 1908 елның 17 маенда Орскида яшәүче мөселман яшьләре һәм 23 майда шәһәрнең аксакаллары белән очраша. Беренче мәҗлестә ул яшьләрнең әдәбиятка битараф булмавына сөенсә, икенчесендә мөселманнар арасындагы хөсетлек, хыянәт һәм таркаулык кебек тискәре сыйфатлар турында ачынып сөйли. Шуның нәтиҗәсендә дәүләтләрнең таркалуына, аерым шәхесләрнең, халыкларның хур һәм мескен булып калуларына мисаллар китерә. Әлеге күренешнең нигезендә наданлык һәм әхлаксызлык ята, ди галим. Ә бу хәлдән чыгу өчен, байларга хәйрия җәмгыятьләре оештырып, мөселман балаларын укытырга кирәклеген әйтә.*

*Р.Фәхреддиннең әлеге очрашуларда сөйләгән сүзләре Оренбургтагы «Вакыт» газетасының 1908 елгы 14 июнь һәм 31 июль саннарында басылып чыга. Мәкаләләрнең авторы – шагыйрь, тәрҗемәче һәм тәнкыйтьче* ***Әхмәд Габдулла улы Исхакый****.*

## Орск шәһәрендә әдәби мәҗлес

Остаз Ризаэддин әфәнденең Орск шәһәренә килүе мөнәсәбәте илә, Орскида булган яшьләр тарафыннан аның хөрмәтенә кунак мәҗлесе ясалды. «Центральная» исемле могтәбәр миһманханә (кунак йорты) залында 17 май ахшам соңында мәҗлес ясалып, шәһәрдә булган имамнарыбыздан ахун Мөхәммәдкәрим әфәнде вә могтәбәр затлар чакырылган иде.

Чакырылганнар җыелып, урнашып җиткәннән соң, мәдрәсәи «Хөсәения»дә гыйлем алган Расих әфәнде: *«Ошбу мәҗлес шәһәребезнең яшьләре тарафыннан остазыбыз Ризаэддин әфәнде хөрмәтенә ясалды»,* – дип, мәҗлесне ачты. Моннан соң яшьләр Ризаэддин әфәндегә адрес (мөрәҗәгать) тәкъдим иттеләр. Адресның эчтәлеге моннан гыйбарәт иде: *«Мөхтәрәм бабабыз! Шәһәребезгә килеп безне чиксез шат иттегез, безләр бик сөендек. Белгәнебезчә, сез тәртипсез, низамсыз вә һәр җәһәттән зәгыйфь, вә начар, вә сәламәтлеккә зарарлы булган иске мәдрәсәләрдә гыйлем алдыгыз. Фәкать милләтебезнең аяныч хәлләрен күрүегез илә бу турыда иҗтиһад итәргә тиешле идекне аңладыгыз вә форсатны югалтмыйча бу юлда хезмәт итәргә керештегез. Хәтта бу турыда тагын да гайрәт тиеш икәнлекне белеп, урыннарыгызны ташлап, Собраниедән чыктыгыз[1]. Сүз аңламас адәмнәрнең хурлау вә сүгүләренә һич игътибар итмичә, һаман фикерегездә нык торып, хезмәтегезне дәвам иттерәсез. Арабызда әдәбият вә тарихның исеме дә булмаган бер вакытта сез боларны барлыкка китердегез. Бары тик кәеф вә сафа өчен генә яратылган дип танылган аналарыбызның вә кыз карендәшләребезнең хокуклы инсаннар булуын сөйләдегез. Хезмәтегезне безләр тәкъдир итеп (бәяләп бетерә) алмасак та, шөбһә юктыр ки, тарих тәкъдир әйләр!»*

Ошбу адресларына каршы Ризаэддин әфәнде, яшьләргә мөрәҗәгать итеп, ошбу эчтәлектә бер җөмлә сөйләде: *«Карендәшләр! Адәм баласы өчен сәгадәт (бәхет) вә бәхтиярлек (бәхеткә ирешү) үз хезмәтләренең җимешләрен күрүдер. Игенче зәхмәтләр тартып-сөреп йөргән җирендә ашлык үскәнен күрсә, бөтен гаиләсе илә сөенер. Көнлекче бер фәкыйрь эшләгәне бәрабәренә хак алган сәгатьтә көнозын маңгай тирләрен агызып чиккән мәшәкатьләрен онытыр. Моның сәбәбе исә, югарыда әйткәнемчә, үз кәсепләренең уңышын үз күзләре илә күрмәк насыйп булуыдыр.*

*Үз туганнарыбызга кыенлык илә булса да каләм хезмәте илә мәшгульбез. Әгәр дә көч-куәтебез камил булса иде, әлбәттә, олуг хезмәтләр итәр идек. Кыенлык илә булган бу хезмәтләрнең игелеген күрү хыялыбызга да килмәс иде. Бәлки, милләтнең тәрәккыйсын (үсешен), бөек фикерен, мәңгелеген вә тормыш низагларында җиңүен бездән соңнар күрәчәк булсалар, мең мәртәбә риза булачакбыз.*

*Ләкин дөньяда хыялларга килми торган шәйләр күп вакыт хакыйкать булып күз уңына килер. Каләм хезмәте илә мәшгуль булуыбыз өчен сүгүдән башка бернәрсә ишетмәячәкбез дип йөргәндә, сезнең ихласлык белдерүегезне күреп, бик тәэсирләндек.*

*Максат бөек бер нокта булганлыктан, аның юлында булган хурлау, яла ягуларның әһәмияте булмас. Дөресен әйтик, аның үзендә аерым бер ләззәт бардыр, чөнки яман сүз илә яхшы сүз арасында булган аерма бик биектер.*

*Имди милләтнең бәхтияр булуын күрү сезләргә насыйп булсын! Сезләрне дә халыкларыгыз ихтирам әйләсен!»*

[1] 1906 елда Ризаэддин Фәхреддин, бертуган Рәмиевләрнең чакыруы буенча, Уфадагы казыйлык хезмәтен калдырып, Оренбургка килә һәм «Вакыт» редакциясендә эшли башлый. ***– Ред.***

Моннан соң мәдрәсәи «Хөсәения» мөгаллимнәреннән Закир әл-Кадыйри, Һади әфәнделәр кыскача гына хөтбәләр ирештерделәр. Озын гына вакыт каршы-каршы сөйләшеп утырышканнан соң, мәҗлес әһелләре бер-береннән канәгать вә разый булган хәлдә таралдылар.

## Орск шәһәрендә картлар мәҗлесе

Ошбу май аеның 17 көнендә Орск шәһәрендә булган яшьләр мәҗлесе хакында бер мәктүб *(хат)* язган идем. Инде бу мәртәбә әлеге шәһәрдә булган картлар мәҗлесе хакында язачакмын.

23 май җомга намазыннан соң шәһәребезнең могтәбәр аксакалларыннан хаҗи Әхмәдсафа әфәнде Борнаев ханәсендә бөек бер кунак мәҗлесе булды. Шәһәрнең бөтен галимнәре (имам, мөәзин һәм мөдәррис, ахуннары), хаҗилары, сәүдәгәрләре, мөгаллим вә хәлфәләре монда бар иде. Шәһәребездә мөсафир булган остаз Ризаэддин әфәнде «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллимнәре белән бергә килеп мәҗлестә берләшкәннән соң, бер зат, Ризаэддин әфәндегә мөрәҗәгать итеп: *«Тәкъсыйр[2]! Дамелла Галимҗан хәзрәтләре хөкүмәт тарафыннанмы җибәрелделәрме?[3] Юкса хакларында берәр төрле шикаять-фәлән булдымы? Бу турыда берәр хәбәр ишетмәдеңме?»* – дип сорау бирде. Моңа җавап буларак, Ризаэддин әфәнде бер сәгатьтән артык вакыт сүз сөйләде ки, сөйләгәннәрен җыеп әйткәндә ошбудыр:

– Бу тугрыда һаман да дөрес бер мәгълүмат алмадык, хакыйкатьне Җәнабе Аллаһ белер. Шулай да кайбер уйларыбыз бардыр. Якынча уйлаган фикер илә бер адәмне тәгаен итеп сөйләү дөрес булмаса да, тәгаен ителмәгән сурәттә *(ягъни аерым бер кешегә бәйләмичә. **– Ред.**)* моны сөйләүдән зарар юктыр.

**Закир Кадыйри** (1878-1954) Бохара, Мәдинә, Истанбул һәм Каһирә калаларында белем ала. «Ислам мәдәнияте тарихы», «Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең хәяте», «Гарәп сарфы» һәм «Гарәп нәхүе», «Кызлар дөньясы», «Хатын-кыз мәсьәләсе» исемле китаплар авторы. Ризаэддин Фәхреддин чакыруы буенча, 1907-1917 нче елларда Оренбургның «Хөсәения» һәм Уфаның «Галия» мәдрәсәләрендә фәлсәфә, психология һәм логика фәннәрен укыта. Хатыны Сания Гыйффәт белән Кытайда татар балалар бакчасы, өч сыйныфлы татар башлангыч мәктәбе ача. Төркиядә вафат була.

Ислам диненә иң бөек җинаять итүчеләр, башкалардан тыш, мөселманнар булганы кебек, ислам өчен хезмәт итүчеләрнең зарарларына тырышучылар да мөселманнар була килде. Моның исбаты исә тарих булыр. Дөрес, кыпчак хөкүмәте җиһан йөзенә берничә дәүләт булып чыкты, шан вә данга ирешкәннән соң, табигый әҗәле җитмәстән элек һәлак булды. Дәште-кыпчак хөкүмәтенең бөеклеген аңлатырга шул җитсә кирәктер ки: ханнарның ярлык вә фәрманнары Москвага барганда, Москва кенәзләре каршы чыгып алырлар иде. Кремльдәге биек чиркәүдә булган вакытта чиркәүдә булган халыклар барчасы, бөек кенәз илә гаиләсе вә хөкүмәт адәмнәре хан хәзрәтләренә ихтирам йөзеннән тезләнеп торырлар иде. Ошбу бөек ислам дәүләте кайбер мөселманнарның зарар итүләре сәбәпле һәлак булды.

---

[2] Тәкъсыйр – руханиларга олылап эндәшү. ***– Ред.***

[3] Сүз дин галиме, журналист **Галимҗан Баруди** хакында бара. 1908 елда ул, панисламизмда гаепләнеп, ике елга Вологда губернасына сөргенгә җибәрелә. ***– Ред.***

Бервакытлар Казан хөкүмәте төзелде. Бабаларыбыз булган болгар төрекләре һәммәсе Казан хөкүмәтенә җыелдылар. Казанның тирә-ягында, Волга буйларында булган чирмеш, чуаш вә мордвалар барчасы, килеп, боларның канат асларына сыгынды. Ошбу халыклар мөселманнарга кылыч куәте илә түгел, бәлки, күркәм әхлак, гадел идарә сәбәбеннән булдылар. Чуашлар, чирмешләр, мордвалар ничаклы безнең кан карендәшләремез булса да, ата вә ана бертуганнарыбыз түгел, бәлки, ерак бабаларыбыздан таралмышлардыр. Шул җәһәттән алар нәсел өчен түгел, бәлки, бөеклек вә күркәм идарәгә кызыгып буйсындылар. Казан ханнары кайбер вакытларда «великий кенәз»ләрне әсир итеп кайттылар вә кайбер вакытларда Москваны камап алып, Москва халкыннан әман кычкырттылар[4]. Әмма бу дәүләт тә, камиллеккә җитмичә, яшь вакытында җан бирде. Казанны Русия яулап алды, фәкать мөселманнар көче вә алар ярдәме илә яулап алды.

> **Кремльдәге биек чиркәүдә булган вакытта чиркәүдә булган халыклар барчасы, бөек кенәз илә гаиләсе вә хөкүмәт адәмнәре хан хәзрәтләренә ихтирам йөзеннән тезләнеп торырлар иде.**

Төркестан вилаятендә бөек бер ислам җәмәгате бар иде. Боларны да Русия дәүләте үз араларыннан булган мөселманнар арадашлыгы илә үз мәмләкәтенә кушты. Диңгез рәвешендә җәелеп яткан башкорт вә казакъ җирләрен дә Русиягә мөселманнар бирделәр. Башкортларны амбарларга тутырып яндыручылар мөселманнар иде.

Бу хәл безнең мәмләкәтебездә генә түгел, бәлки, башка ислам мәмләкәтләрендә дә шулай вә шулай булгандыр. Вәлилек *(патша)* мәртәбәсенә мендерелмеш бер хәлифә, Андалус *(Андалусия)* мөселманнарын үтертүен сорап, француз падишаһына бүләкләр күндереп, үтенечен белдермеш иде. Төркия илә Иран һәр икесе бер Коръән, бер кабилә, бер пәйгамбәребезгә (с.г.в.) буйсынганнары хәлдә, инде ничә гасырлар бер-беренең каннарын агызалар. Әл-Җәзаир *(Алжир)* өстенә читләр килгән вакытта Тунис мөселманнары читкә китеп тордылар. Тунислылар тупка тотылган вакытта Мара *(Марокко)* кешеләренең хәмиять *(саклау)* тамырлары селкенмәде. Бу көндә Мара кешеләр кырылып яталар, Африка мөселманнары бер хәрәкәт булса да күрсәтмәделәр...

Мулла Батыршаны, мөселманнар тотып, дворянлык вә медальләр бәрабәренә шул вакытның хөкүмәтенә бирделәр. Һәммәгезгә мәгълүм шәех Зәйнулла хәзрәтләренә *(Троицк мулласы, ишан Зәйнулла Рәсүлов. – **Ред.**)* дин исеменнән муллалар донос ясап, шәһәр читенә кудырдылар. Мөгаллимнәргә яңача укытуны күрсәткәне өчен Габделгани хаҗины *(атаклы иганәче Габделгани бай Хөсәенов. – **Ред.**)* хөкүмәткә донос итүчеләр дә мөселманнар иде.

Уйлавымча, дамелла Галимҗан, дамелла Гобәйдулла вә мелла Салихҗан хәзрәтләр дә мөселманнар тарафыннан булган шикаятьләр сәбәбеннән мондый мәшәкатьләргә дучар ителделәр[5]. Моннан соң да мондый хәлләр сирәк булмаса кирәк. Мөселманнарга җәбер итүчеләр – тугрысын әйткәндә, хөкүмәт түгел, ә мөселманнар үзләредер. Кайбер җитди әйберләрне искә алмаганда, мөселманнар хөкүмәттән мәҗбүр түгелдер. Рус зарарына бер мөселман шәһадәте кабул булыр, мөселманга җәбер итүе исбат булса, христиан гаепле ителенер. Сәүдә турындагы налоглар да бөтен халыкка бер. Моны исә үзегез дә беләсез...

[4] Әман кычкырту – «Коткарыгыз, гафу итегез. Мәрхәмәтле булыгыз!» – дип ялвару, тез чүгү. – ***Ред.***
[5] Ошбу вакытта 23-24 мөселманның бер шикаятьнамә биргәне хакында хәбәр чыккан иде.

Дөньяда мондый рәвештә зәгыйфь вә түбән мөселманнар булганлыктан, бөтен мөселманнар да зәгыйфь дигән сүз түгел, исламның бозыклыгы катгый тиеш булмас! Мөселман дию ислам дип әйтү түгелдер. Хакыйкатьтә мондый түбән мөселманнарның бу әхлаксызлыклары өчен диннәре түгел, бәлки, наданлыклары гаепледер. Бездә асыл гыйлем юктыр.

Хакыйкый исламнан, хөббеннәфес *(үз-үзеңне ярату, мин-минлек)* вә гыйззәте нәфес *(үз-үзен сөючелек)*, гайрәт вә иҗтиһадтан, хөсне *(күркәм)* холык вә вафадан *(сүздә тору, бурычны үтәү, эштә тугрылык күрсәтү, тотнаклылык)* безнең мәгълүматыбыз аз. Без бозыклыкны наданлыгыбыз сәбәпле кылырга мәҗбүр булабыз. Бу көндә башыбыздагы бәлаләрнең олысы наданлык, белемсезлектер. Әгәр дә ошбу наданлыктан дип нәтиҗә ясасак, бөтен морадыбыз үзеннән-үзе хасил булыр. Гомуми наданлыкка каршы торыр өчен күмәк иҗтиһад *(тырышлык)* кирәк. Дөньяны каплаган бәла бер-ике адәмнең тырышлыгы илә бетерелмәс. Балаларны, ир вә кызларны бер калдырмый укытырга вә ислам рухы илә тәрбия итәргә кирәк. Бөтен ислам баласын укыту, байлыклары вә гыйлемнәре нисбәтенә карап, байлар вә галимнәр өстенә йөкләнгән булса кирәк. «Баласы булган ата баласын үзе укытсын!» – дию – хата бер сүздер. Ошбу шәһәрнең ярымыннан күбесе фәкыйрь мөселманнардыр дип уйлыйм. Иң күп балалар да шуларның балалары булса кирәк. Көнлекче буларак хезмәт итеп йөрүче эшче гаиләсенме туйдырсын, баласынмы укытсын? Дөньяда фәкыйрьлек кадәр мөшкел шәй булмас! Моны сөйләргә дә кирәк түгелдер.

Нәтиҗә: ошбу шәһәрнең фәкыйрь мөселманнарының балаларын укыттыру, байлыгыгызга карап, сез, байларга, тиештер. Аллаһы Тәгалә сезгә малыгыздан фәкыйрьләр өчен бер өлеш аерырга кушкан! Димәк, үз малыгыздан түгел, бәлки, шул фәкыйрьләр өлешеннән үзләренең балаларын укытырсыз. Ләкин бер-берегезгә ышанып торуыгыз вә шул сәбәптән балаларны укытудан калдыруыгыз мөмкин. Мондый куркыныч булмасын өчен, хәйрия җәмгыятьләре төзү ысулы бар. Акчагызны җәмгыятькә бирерсез дә: «Шәһәрдә булган фәкыйрьләрне укытыгыз!» – диярсез. Никадәр бала укыса, савабы сезгә булыр. Әгәр дә үз тарафыннан булмаган сәбәпләр илә *(ягъни хаерчелек сәбәпле. **– Ред.**)* бер бала укымый калса, гөнаһы хәйрия җәмгыяте әгъзаларына төшәр. Һәрхәлдә, сез Аллаһы Тәгалә һәм халык хозурында булган җаваплылыктан азат булырсыз. Бу шәй үзегез өчен бөек бер бәхтиярлектер.

Уку-укытудан соң иң дикъкать ителенәчәк шәй – әхлактыр. Балаларның әхлакларын тәрбия итү иң кирәкле әйбер! Гүзәл әхлактан мәхрүм булган инсаннарның гыйлемнәреннән тиешле дәрәҗә файда булмас. Югарыда сөйләгән нәрсәләрнең сәбәбе наданлык дисәк тә, гүзәл әхлактан мәхрүм булганнар да җаһилләрдер *(наданнар, белемсезләр)*.

Беләмен ки, сезләр мондый бер сүз ишетер өчен түгел, бәлки, бу мәҗлескә сыйхөрмәт өчен килдегез. Мин дә бу рәвештә сүз сөйләр өчен хәзерләнеп килмәгән идем. Туры килде дә моның кадәр сөйләргә мәҗбүр булдым. Сезләрне ялыктырган булсам, гафу итәрсез!

***

Мәҗлестә булган могтәбәр затлар моңа каршы рәхмәт укыдылар вә канәгать булуларын белдерделәр. Имамнар да: *«Болар чын йөрәктән вә вөҗдан белән сөйләнгән сүзләрдер, без моннан разый булдык!»* – диделәр.

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

# Кышкы сынамышлар

Хуҗи Мәхмүтов

Кышкы мизгел. *Ленар Гобәйдуллин фотосы*

Болытлар түбәннән килсә, каты суыкны көт.
Йолдызлар ачык күренсә — көн яхшыра, тонык күренсә – кар (яки яңгыр) ява.
Кар лапа-лапа төшә: карга килер.
Кояш бик еракта булып күренсә, салкын булыр.
Кояш киртәләнсә, салкын булыр.
Кояш чыкканда багана кебек нурлар күренсә, суык булыр.
Кыш көне йолдызлар бик чекерәеп, яктырып торса, көннәр суык булыр.
Кыш көне кояш кызарып чыкса, салкын булыр.
Кыш көне кояш тирәсендә алка кебек булса, бик суык булыр.
Яңа ай чалкан күренсә, бу кыш кар күп булыр.
Яңа айның очлары нәзек күренсә, салкын булыр.
Яңа туган айның баш-башы бик очлы булып, бик бөгелеп торса, суык булыр.
Әгәр кар вак кына бөртекле, сирәк кенә төшкәләсә, бик озак суык булыр.
Әгәр кыш көне төшлек тарафыннан җил иссә, көн җепшек булыр.
Әгәр кыш көнендә кояш өчәү кебек күренсә, суык булыр.
Әгәр яңа ай бик ачык ялтырап күренсә — салкынга.
Әгәр һава урман өстендә зәңгәр сыман күренсә, җылы булыр.
Кар бүрәнәгә сырышып яуса, җәй яңгырлы килер.
Кыш кар күп булса, җәй яңгырлы булыр.
Бүрәнә шартласа, суык булыр.
Кыш көне утның кызулыгы еракка китсә, салкын булыр. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2020

*Татар китабы*

# Әлифба китаплары

Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев




**Сәгыйть Хәлфин «Әлиф би...». – Мәскәү, 1778**




**Зәбири Х. «Мәктәп балаларына юлдаш яки рәсемле әлифба». – Казан: «Сабах» көтепханәсе нәшере, 1914**

**Таһиров Ш. «Рәсемле әлифба. Казан шивәсендә». – Казан: И.Н.Харитонов матбагасы, 1914**

Тарихтан мәгълүм булганча, Идел буе Болгар дәүләтендә, ягъни X-XIII гасырларда ук мәктәп-мәдрәсәләр эшләгән. Дин, әдәбият, тарих, фәлсәфә һәм медицина фәннәре буенча хезмәтләр язылып, алар кульязма китаплар рәвешендә таралган.

Халкыбызның беренче әлифбалары Идел буе Болгар дәүләте мәктәп һәм мәдрәсәләрендә төзелә башлый. Алар Алтын Урда һәм Казан ханлыгы халыкларында соңрак та файдаланыла һәм даими камилләштерелә. Киң таралган әлифбалар арасында 18 нче йөзнең икенче яртысында Мортаза Котлыгыш улы белән Ишнияз бине Ширнияз тарафыннан язылган кульязма әлифбалар билгеле.

Сакланып калган беренче басма әлифбалар XIX гасыр башы мәктәпләре өчен чыгарылган. 1802 елда Казан университеты типографиясендә 11 мең данә тираж белән Мортаза Котлыгыш улының «Шәраител-иман» («Иман шарты») әлифбасы басыла. Бу китап – иң күп нәшер ителгән татар әлифбаларының берсе. Йөз егерме алты ел дәвамында (1802-1928) аның 100гә якын басмасы дөнья күргән. Аннан соңгы заманнарда укырга-язарга өйрәтү, шул исәптән җәдитчә мәдрәсәләр өчен Галимҗан Барудиның «Сәвад хан» (1891), Мөхәммәдвәли Мөхәммәдрәхим әл-Чистайиның «Иказел-вилдан» («Балаларны уяту», 1891), Әхмәтһади Максудиның «Мөгаллиме әүвәл» («Беренче дәреслек», 1892), «Мөгаллиме сани» («Икенче дәреслек», 1902) әлифба-дәреслекләре төзеп чыгарыла. Ә.Максуди әлифбалары 1892-1917 нче елларда күп тапкырлар нәшер ителә һәм Россиянең барлык төрки телле халыклары мәктәпләрендә кулланыла. 19 нчы йөз ахырында Имаметдин Сәйфуллинның «Яңа әлифба» (1892), Шакирҗан Таһиринең «Бәдъ әт-тәгълим:

**«Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда татар мәктәпләрендә Габбас Сәйфуллин «Әлифба»сы укытыла. 1965 елдан башлап Рәмзия Вәлитова белән Сәләй Вәгыйзов «Әлифба»сы гамәлгә керә. Бу авторларның ике варианттагы әлифбалары 60тан артык басмада соңгы вакыткача дөнья күрде.**

Бәдыйгов Х. «Әлифба. Грамота мәктәпләре өчен». – Казан: Татгосиздат, 1936




Корбангалиев М., Бәдигов Х. «Әлифба». – Казан: Татгосиздат, 1937




Мөхетдин Корбангалиев «Әлифба. Башлангыч мәктәпләр өчен». – Казан: Татгосиздат, 1940

**Агиев Ф., Тимербулат Г. «Кызыл йолдыз. Әлифба». – Мәскәү, 1924**

мөкәммәл әлифба» («Башлангыч белем бирү өчен тулы әлифба», 1893) исемле беренче рәсемле әлифбалары дөнья күрә. Күп әлифбаларда математикадан башлангыч мәгълүмат бирелгән бүлек – әбҗәд (саннарны гарәп хәрефләре белән билгеләү) аерылып торган. Алар арасында Каюм Насыйриның «Иҗек: ибтидаи сабакка шөругъ кыйлгучы балаларга иҗек танытмак өчен бер тәҗрибәдер» (1895), «Иршадел-хибба илә тәгълимел-әлифба» (1891) китаплары бар.

Татар әлифбаларының бер төре – рус гимназияләрендә укучыларны татар теленә өйрәтү өчен уку ярдәмлекләре. 1778 елда Сәгыйть Хәлфин тарафыннан «Хәреф вә иҗекләре тулы тасвирланган татар теле әлифбасы» нәшер ителә. 1787 елда аның «Әлифбаи татар» дәреслеге басыла. 1809 елда Ибраһим Хәлфиннең «Гарәп укуы кагыйдәләре белән татар теленең алфавиты һәм грамматикасы» дәреслеге, 1859 елда Габдүш Ваһаповның «Мөгаллиме әүвәл фи тәгълим лисанел-гарәп вәл-фарси вәт-татари» дәреслеге, 1887 елда Мирсалих Бикчуринның «Татарларга русча, русларга татарча сөйләшергә һәм үзлегеннән укырга өйрәткеч» уку ярдәмлеге дөнья күрә. 19 нчы йөз ахыры-20 нче йөз башында мәктәптә укыту системасын үзгәртеп кору, ягъни «җәдитчә укыту»га күчү сәбәпле, яңа төр дәреслекләр, шул исәптән укытуның аваз ысулына нигезләнгән әлифбалар барлыкка килә. 1893 елда Мөхәммәтзакир Ишмөхәммәтовның «Берьюлы уку-язу» әлифбасы, 1900 елда «Әлифбага йитәкче» дигән уку ярдәмлеге, 1908 елда Хәбибрахман Зәбиринең «Рәсемле әлифба»сы басыла. XIX гасырның икенче яртысыннан керәшен татарлары өчен әлифбалар булдырыла, алар педагог-миссионер Н.И.Ильминский тарафыннан кириллица нигезендә төзелә.

Атаклы педагог Мөхетдин Корбангалиевнең «Татар әлифбасы» 1912-1918 нче еллар дәвамында 7 тапкыр, шушы һәм башка исемдәге әлифбалары 1945 елга кадәр тагын 20 тапкыр басылып чыга.

Гомуми башлангыч белем бирүне гамәлгә кертү һәм олыларны укырга-язарга өйрәтү өчен татар әлифбалары төзү 1920 нче еллар ахыры-1930 нчы еллар башында аеруча киң колач ала. Г.Шәрәф һәм Ш.Алексеевның «Беренче адым» (1923), «Якты юл» (1926), «Яңа тормыш» (1928) әлифбалары нәшер ителә. Латин графикасына күчү уңае белән, Гыймад Нугайбәк һәм Мөхәммәтхан Фазлуллинның «Яңа әлифба»сы (1926) нәшер ителә.

**«Яңа татар әлифбасы». – Казан, «Яңалиф» җәмгыяте нәшере, 1926**

Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда татар мәктәпләрендә Габбас Сәйфуллин «Әлифба»сы укытыла. 1965 елдан башлап Рәмзия Вәлитова белән Сәләй Вәгыйзов «Әлифба»сы гамәлгә керә. Бу авторларның ике варианттагы әлифбалары 60тан артык басмада соңгы вакыткача дөнья күрде. Рус телле балалар өчен 1990 нчы еллардан башлап аерым әлифбалар чыгарыла. Мәсәлән, Фәрит Йосыпов белән Лениза Новикова төзегән «Әлифба» (1994, 1998). Хәзер мәктәпләрдә Альбина Нурмөхәммәтова, Зәйтүнә Ризванова, Клара Зарипова «Әлифба»сы (2002, 2007), Фирдәвес Гарифуллина, Илсөяр Мияссарова, Рәсимә Шәмсетдинова «Әлифба»лары (2011, 2012, 2016), Рәдинә Ягъфәрова «Әлифба»сы (2012, 2016), балалар бакчаларында Лилия Гыйләҗева белән Гүзәл Нәбиуллина төзегән дүрт кисәктән торган «Нәниләр өчен әлифба» (2011, 2012), Резеда Шәехованың «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы» (2011) кулланыла.

Җәмил Зәйнуллинның гарәп язуын үзлегеннән өйрәнүчеләр өчен төзелгән, берничә тапкыр (1989, 1991, 1993) басылган әлифбалары, Вахит Хаковның латин графикасында уку һәм язу күнекмәләре бирелгән «Телен белгән ил ачар» җыентыгы (1993), югарыда телгә алынган С.Вәгыйзов белән Р.Вәлитованың «Латин графикасы нигезендә әлифба» дип аталган эксперименталь уку ярдәмлеге (2000, 2002) бар. Соңгы елларда әлифбалар төзүдә яңа технологияләр кулланыла башлады: Т.Шакирова төзегән «Нәниләргә әлифба» китабы (2012) авазларны тавышлы өйрәткеч белән, Р.Бикташев, З.Җамалетдинова, А.Хәкимуллин, Ә.Сингатуллин эшләгән «Әлифба» интерактив дәреслеге мультимедиа басма (2012) рәвешендә дөнья күрде.

Р.Вәлитова белән С.Вәгыйзов озак еллар хезмәт куйган Арча педагогия көллиятендә 1999 елдан «Әлифба музее» эшли, бирелә, татар әлифбалары тарихы киң яктыртылу белән беррәттән, йөзләгән телләрдәге башка әлифба китаплары да урын алган. ■

# Бәрәңге хәзинәләре – Казан университетында

Әлфрид Бостанов



**«Хәяли бәр шәрхе гакаид Тафтазани»**

Билгеле булганча, 1963 елдан алып Казан дәүләт университетының галимнәре (Альберт Фәтхи, Миркасыйм Госманов, Җәүдәт Миңнуллин һәм башкалар) ел саен системалы рәвештә Россиядә татар халкы яшәгән барлык урыннарны да, хәтта кайберләрендә берничә мәртәбә йөреп чыгып, шактый бай кульязма коллекциясен туплаганнар. Дөрес, университетта аларга кадәр дә кульязмаларны җыю эше алып барылган, әмма нәкъ менә бу галимнәр, махсус археографик экспедицияләр оештырып, татарлар яши торган һәр төбәккә махсус барып, сирәк китапларны китапханәгә алып кайтканнар. Университетта хәзерге вакытта да кульязмаларны туплау эше дәвам итә һәм аларның саны егерме меңгә җитте.

Бу кульязмалар тупланмасының әһәмияте бик зур. Әмма җәмгыятьтә аның кадерен белеп бетерү җитми, чөнки хәзерге вакытта китапханә фәнни үзәк түгел, ә милли мирасыбызны саклау урыны гына. Әгәр дә кульязмаларның эчтәлегенә, тарихына һәм тышкы сыйфатларына игътибар белән карыйбыз икән, шунысы ачыклана: бездәге кульязмалар җыелмасы Көнбатыштагы мәшһүр китапханәләрдән әһәмияте һәм сан ягыннан бер дә калышмый. Киресенчә, аларда сакланган китапларның күпчелеге башка халыклардан тартып алынган мирас булса, безнең кулыбызда – үзебезнең тарихи ядкярләребез. Моны без горурланып әйтә алабыз, чөнки Казан университетындагы татар-шәрык кульязмалар тупланмасы күләме буенча Россиядә беренче урында тора. Әһәмиятенә карап, игътибар да җитәрлек булырга тиеш!

Кульязмаларны өйрәнгәндә иң беренче адым – фәнни тасвирлама, чөнки бөтен китапларның эчке һәм тышкы сыйфатларын төгәл белеп бетермичә, җитди фәнни эш турында сүз йөртү мөмкин түгел. Безнең мәртәбәле сәләфләребез кульязмаларны тасвирлау юнәлешендә шактый зур эш башкарганнар. Беренчедән, 1920 нче елларда ук китапханәдә сакланган кульязмаларга тасвирламалар аерым кар-

точкаларда латин һәм гарәп хәрефләре белән язылган. Параллель рәвештә бөтен китаплар да гарәп графикасында инвентарьга теркәлә. Аннары 1950 нче елларда барлык китаби мирас өч төркемгә бүленә: төрки-татар, гарәп һәм фарсы. Мин үзем бу бүленешне бик яратып бетермим, чөнки бер китапта өч тел дә булырга мөмкин. Шуңа күрә аларны аерым теркәү буталчыклык кына тудыра.

Күренекле татар археографлары Альберт Фәтхи, Мәсгут Идиятуллин һәм Алсу Арсланова татар, гарәп һәм фарсы кульязмаларын тасвирлау юлында саллы хезмәтләр калдырганнар. Нәкъ менә аларның эшенә нигезләнеп, безнең кульязмалар чит илдән килүче һәм ватандаш галимнәр тарафыннан өйрәнелә.

Археографик экспедицияләрдә табылган кульязмаларны инвентарьга теркәү һәм тасвирлау эше әле дә тәгәлләнмәгән. Әлбәттә, бу вазгыять татар тарихын өйрәнүне тоткарлый. Әлеге гаять мөһим фондны тулаем рәвештә һәръяктан өйрәнеп бетермичә, зур һәм концептуаль күзәтүләрне ясавы кыен, хәтта бөтенләй урынсыз дип тә әйтеп була. Шуңа күрә иң беренче максат – Казан университеты китапханәсендә булган барлык кульязмаларны исәпкә алу һәм кыскача гына булса да тасвирлау.

> «
> **Кульязмаларны өйрәнгәндә иң беренче адым – фәнни тасвирлама, чөнки бөтен китапларның эчке һәм тышкы сыйфатларын төгәл белеп бетермичә, җитди фәнни эш турында сүз йөртү мөмкин түгел.**

Әйтергә кирәк, соңгы көннәрдәге тасвирлау эше барышында көтелмәгән яңа ачышлар ясау бәхетенә ирешттек. Дистә еллар дәвамында үз вакытын көтеп торган кульязмаларның кайберләре, 1960 нчы елларда ук университетның китапханәсенә кергән, әмма бу көнгә хәтле алар турында бернинди мәгълүмат булмаган һәм галимнәр алар белән таныша алмаган. Биредә мин сезне шундый бер табыш белән таныштырырга уйлыйм.

* * *

1989 елда археографик экспедиция Мари-Эл Республикасындагы татарлар яшәгән авылларда йөргән. Фәнни сәфәр күптән түгел вафат булган галим, тарихчы-археограф Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин җитәкчелегендә оештырылган. Бу елгы табышлар арасында кечкенә форматлы бер китапчык та бар. Ул Бәрәңге районының Мазарбашы авылында яшәүче Мәнфүсә ханым Гайнетдинова тарафыннан бүләк ителгән. Кызганыч, бу китапның иясе турында бездә мәгълүмат юк, әмма бүләге игътибарга бик тә лаек.

Беренчедән, әлеге мирас – мәшһүр фарсы шагыйре Сәгъдинең һолланд кәгазенә татар кешесе тарафыннан күчерелгән «Гөлестан» нөсхәсе (шифры – 813 нче ф.). Әсәрнең азагында урыны һәм вакыты билгеләнмәсә дә, кульязманың бер битендә 1701 елда күчерелүе ачык күрсәтелгән. Өстәвенә, бу дата китапның тышкы сыйфатларына – кәгазь, язу рәвеше һәм зурлыгына да туры килә. Әлбәттә, Казанда «Гөлестан»ның борынгырак нөсхәләре дә бар. Мәсәлән, С.М.Гыйләҗетдинов тарафыннан тасвирланган кульязма ТР Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Мирасханә»сендә саклана. Әлеге мирас 1563-1564 нче елларга карый. Әмма университетта сакланган кульязма татар нөсхәсе булуы белән кадерле!

دشمنان بود دوست نمایند   دوست مشمار آنکه در نعمت زند
لاف یاری و برادرخواندگی   دوست آن باشد که گیرد دست دوست
در پریشان حالی و درماندگی   دیدم متغیر شد و نصیحت من بغرض
میشنود بنزدیک صاحب دیوان رفتم بسابقهٔ معرفتی که میان ما بودی
و صورت حالش باو گفتم تا بکاری نصیبش کرد چندی برین بگذشت
لطف طبعش بدیدند و حسن تدبیرش بپسندید و کارش از آن در
گذشت و بمرتبهٔ بلندتر از آن متمکن شد همچنین نجم سعادتش
در ترقی بود تا باوج ارادت برسید و مقرب حضرت سلطان
شد و مشارالیه و معتمد علیه گشت بر سلامت حالش شاد
مان گشتم و گفتم   منشین ترش از گردش ایام که صبر تلخست
ولیکن بر شیرین دارد و از آن نزدیک با طایفهٔ اتفاق سفرم افتاد
چون از زیارت مکه باز آمدم دو منزل استقبال کرد ظاهر حالش
بدیدم پریشان و در هیأت درویشان گفتم حال چیست گفت چنانچه
تو گفتی طائفه حسد بردند و بخیانتم منسوب کردند و ملک در کشف حقیقت
آن استقصا نفرمود و یاران قدیم و دوستان رحیم از کلمهٔ حق
خاموش گشتند و صحبت قدیم فراموش کردند   بنظم خداوند
کسی افتادچه عالمش پای بر سر نهند چو بنده اقبال دستش گرفت

Сәгъдинең һолланд кәгазенә татар кешесе тарафыннан
күчерелгән «Гөлестан» нөсхәсе

**«Татар кульязмаларын эчтәлек буенча гына түгел, палеографик үзенчәлекләре буенча да тәфсилләп өйрәнеп була һәм бу эш киләчәктә татар тарихы өчен кадерле фактлар һәм күзәтүләр биреп торачак.**

Әлеге фактларның әһәмияте нәрсәдә? XVIII-XIX гасырларда Сәгъдинең «Гөлестан» белән «Бостан» әсәрләре бик күп татар мәдрәсәләрендә популяр булган. Бу күренеш татар халкының фарсы телле мәдәни даирәгә якын булуын аңлата. Сабыйларга да, укымышлы өлкәннәргә дә фарсы китаплары үзенчә файдалы булган һәм алар татар шәхсиятен тәрбияләүдә зур урын тоткан. Баштарак бу әсәрләр читтән китерелгән нөсхәләрдән укылса, соңрак татарлар тарафыннан да күчерелә башлаган. XIX гасыр башында «Бостан» тулаем татарчага юлга-юл тәрҗемә ителә, XX гасыр башында «Гөлестан» да саф татарчага күчерелгән. Тәрҗемәнең бер нөсхәсе «Мирасханә»дә саклана. Университеттагы нөсхә татар халкының классик фарсы әдәбиятын үзләштерүнең ышанычлы дәлиле булып тора.

Икенче күзәтү Мәнфүсә ханым Гайнетдинованың китап җыелмасы белән бәйле. «Хәяли бәр шәрхе гакаид Тафтазани» дигән гарәп телендәге әсәр (шифры – 5998 ар) дә 1989 елгы археографик экспедиция вакытында табылган. Бу китап исә игътибарны эчтәлеге һәм датасы белән түгел, ә үзенең тарихы белән җәлеп итә. За кәгазьдә китапның берничә хуҗасының язмалары күренә. Аларның берсе – «шәкерт Мозаффар углы Мөхәммәдҗан» һәм аның әтисе Мозаффар бине Габделгаффар (1870 елгы язма). 1894 елда бу китап Әбү-н-Нәкыйб әт-Түнтәри, ягъни мәшһүр Ишми ишан кулына килеп эләгә. Ахырдан мелла Хафизетдин бине мелла Насретдин кульязманы Хөсәен бине Фәтхулладан сатып ала. Исемлектән күренгәнчә, берничә дистә ел эчендә китап шактый гына кешеләр милкендә булып ала һәм, ниһаять, XX гасыр уртасында Мазарбашы авылына эләгеп, Казан археографларының килүен көтеп ята.

Алда телгә алынган мелла Хафизетдин бине мелла Насретдин әл-Бәрәңгәви (1827-1917) татар тарихында билгеле шәхес. Мазарбашы һәм Мәчкәрә авылларында, аннары Бохара шәһәрендә белем ала. Бохарада ул мәшһүр Шиһабетдин әл-Мәрҗани шәкертләреннән була. Берничә ел дәвамында Петропавловск шәһәрендә яши һәм, туган иленә кайтып, Бәрәңге авылында имам хезмәтен башкара. Аның улы Әхмәд (1877-1930) – «Тәварихе Бәрәңгәви» дигән зур күләмле тарихи әсәрнең авторы. Ул әсәр хәзерге вакытта берничә вариантта «Мирасханә»дә саклана һәм күптән түгел Америка галиме Аллен Франк, татар археографы Марсель Әхмәтҗанов тарафыннан тәфсилләп өйрәнелде. Шулай ук «Мирасханә»дә һәм Казан университеты китапханәсендә әлеге затлы нәселнең башка китаплары да бар.

Бу мәгълүматларга таянып, мондый фикерләрне әйтергә мөмкин. Беренчедән, Мари-Эл Республикасының Мазарбашы авылындагы Мәнфүсә ханым Гайнетдинованың Хафизетдин әл-Бәрәңгәвигә берәр туганлык мөнәсәбәте булырга мөмкин. Моны без шунда яшәүче халыктан сорап белә алырбыз дигән өмет бар. Икенчедән, шул ук кешедән алынган бер китап Хафизетдин әл-Бәрәңгәви милкендә булган икән, борынгы «Гөлестан» нөсхәсенең дә шушы кешенеке булуы бик мөмкин.

Җыеп әйткәндә, татар кульязмаларын эчтәлек буенча гына түгел, палеографик үзенчәлекләре буенча да тәфсилләп өйрәнеп була һәм бу эш киләчәктә татар тарихы өчен кадерле фактлар һәм күзәтүләр биреп торачак. Әлеге ачышлар бик вак күренсә дә, чынлыкта аларның бер-берсенә тоташып баруы нәтиҗәсендә, катлаулы һәм тирән тарихи күренеш күз алдыбызга басачак. ■

# Үткәннәргә сәяхәт

Нурулла Гариф

**Чаллы каласы.**
***Рәис Шаһи рәсеме***

Борынгы Чаллы төбәгендә[1] барлыкка килгән авыллар зур һәм борынгы тарихка ия. Борынгы Чаллы шәһәре (1183-1556) үзе дә шушы җирлектә урнашкан авылларга нигезләнеп барлыкка килгән һәм үсеш кичергән. Шул чорлардан бирле яшәп яткан яисә вакыт узышында «элекке авыл урыны» буларак халык теленә кереп калган авылларның исәбе бу төбәктә 50дән артык. Әлеге авыллар җирлегендә «борынгы, иске, изге, кирәмәт, мазарка» атамасында сакланган зират урыннары да билгеле. Алар, сирәк кенә булса да, шул чорларда куелган язма кабер ташлары белән дә билгеләнә.

Борынгы Чаллы шәһәре беренче тапкыр чыганакларда – 1183 ел[2], соңгы тапкыр 1556 ел[3] белән билгеләнә. Шәһәр тирәсендә урнашкан авылларның тарихына бәйле иң тәүге язма чыганак 1619 елгы җир бүленеше вакыйгасына бәйле искә алына[4]. Чыганакта Чаллы төбәге авылларының борынгы чорлардан килгән атамалары һәм аларда авыл башлыклары ролен үтәгән кешеләрнең («людей-старожильцов») исемнәре санап үтелгән (фотода аларның исемнәре һәм тамгалары күрсәтелә). Әлеге чыганак – борынгы чорларда барлыкка килгән авылларның атамаларын һәм аларның төбәк яулап алынганнан соң нинди үзгәрешләр кичерүен аңлатучы бердәнбер документ. Беренчел авыл атамаларыннан аермалы буларак, соңрак чордагы документлардагы авыл атамалары, 1619 елгы чыганактагы исемлектә искә алынган кешеләрнең бер өлеше, «староста»лар яисә «выборный» дип аталып, шулар исемендә бирелә.

---

[1] Әлеге җирлек бүгенгә көндә Балык Бистәсе районының көнчыгыш һәм Мамадыш районының көнбатыш җирләре белән аерымлана. Элекке Кызыл Йолдыз районы (1935-1959) биләмәсенә туры килә.

[2] Летописный сборник, именуемый Патриаршею или Никоновскою летописью. ПСРЛ.Т. IX. – М.: Наука, 1965. – л. 269; Летописный сборник, именуемый Тверской летописью. ПСРЛ.Т. XV. – М.: Наука, 1965. – VIII. – л. 186; – VII. – л. 504.

[3] Никоновская летопись. – ПСРЛ.Т.IX-XIII; «Казанский летописец». – ПСРЛ.Т.XIX.

[4] РГАДА. Ф. 1209, оп. 1, ч. 1, кн. 153, лл. 390-396, 1619 г. Подлинная дозорная книга пустоши, что было Чаллынское городище (по Зюрейской дороге), письма и дозора Григория Кузьминского. Документ белән «Гасырлар авазы» – «Эхо веков» журналының 2011 елгы 3-4 нче саннарында танышырга була. Язманы тарих фәннәре кандидаты Рәшид Галләм шәрехләгән.

Мәсәлән, 1916 елгы чыганакта ташландык (пустошь) буларак билгеләнгән Балхуҗа авылында яшәүчеләрнең җитәкчеләре Көчек Мәмәшев («Кучук Мамышев») искә алына.

1678 елгы чыганакта әлеге җирлектә өч авыл: Балхуҗа, Пимәр елгасы кушылдыгындагы Мәмәш[5] һәм Балхуҗа-Пимәр авыллары күрсәтелгән[6]:

1. «Деревня **Мамышское** Бимерское устье тож *(Пимәр елгасының түбән өлешендә. Авыл һәм зират урыны билгеле),* в ней 16 дворов, людей 16...»;

2. Починок **Болгозя** Бимер *(Пимәр авылы, зираты җирле халык телендә «Йортлар өсте» атамасында билгеле),* а в ней татары, а в нем 14 двора, 15 человек...»

3. «Починок на пустоши **Багалзинскою** *(Балхуҗа – Көчек Чаллысы – Биектау)* в ней 34 двора, людей 34...»

*Балхуҗа* авылының исеме **Көчек Чаллысына** әйләнүе дә 1619 елгы документта искә алынган **Кучук Мамышев**ка бәйле. Әле 100 елдан соң да (1719 елга караган 1 нче ревизия кенәгәсе[7]) Көчек авылының старостасы буларак **Көчек Мәмәшевнең** *(Мөхәммәднең)* оныгы **Ишманейко** *(Ишмөхәммәд)* **Кусюков** торганлыгы билгеле. Балхуҗа – Көчек Чаллысы авыллары турында мәгълүмат 1715-1716[8] нчы елларга караган чыганакларда да урын алган. 1742 елдан соңгы документларда Балгузино атамасы искә алынмый.

Көчек Чаллысы авылын, атамасы яңгырашына бәйле, совет чорында Биектауга үзгәртәләр. Әлеге зур авылның урам атамаларында элекке чордагы авыл атамалары хәзерге чорда да чагылыш таба. Авылның хәзерге *«Чутай очы»* дигән урыны 1619 елгы документта **«Новые Чаллы Нижние, Чютея Косарова»** дип искә алына. Авылның зираты да билгеле.

Тирә-якта урнашкан дистәләрчә башка авылларның атамасы үзгәреше дә Балхуҗа-Көчек Чаллысы авылы тарихына охшаш. Без аларны санап кына узабыз:

---

[5] Мәмәш авылының атамасы Көчекнең әтисе Мәмәш исеменә бәйле. Бу очракта Мәмәшне авылның сайлап куелган кешесе булган дип аңларга кирәк. Мәмәш авылының нигезе Пимәр елгасының уң ягында, хәзерге фермалардан астарак, су башнясы – чишмә янында урнашкан.

[6] РГАДА. Ф. 350, оп. 2, д. 1102, лл. 643-644, 1678 г. Чыганакта авылларның атамалары, алардагы йортлар, әлеге йортларда яшәүче кешеләр, аларның абыйлары, үз һәм ул-кызлыкка алган үги балалары, туганнары, оныкларының саны китерелә. Әлеге авылның күпме ясак түләргә тиешлеге күрсәтелә.

[7] РГАДА. Ф. 350, оп. 2, д. 1084, лл. 318-319, 1719 г. Д. Балгузино (Кусюкова Челны тож) ясашные татары.

[8] РГАДА. Ф. 350, оп. 1, д. 153, л. 962, 1716 г.

**Чаллы каласы.** ***Ф.Халиков рәсеме***

1. 1619 елгы чыганакта Югары Чаллы авылыннан сайлап куелган авыл башлыгы **Бокаш Шихназимов** искә алына. Бүгенге көндә бу авылның исеме **– Котлы Бөкәш.** Авыл исеме ике сүздән тора. Хәзерге авыл белән янәшә Котлыг авылының борынгы нигезе урнашкан.

2. *Би-Йорт* авылы башлыгы **Чураш Шихназимов.** Авылның хәзерге атамасын татарлар **Чураш** дип атап йөртә. Соңрак чоргы урысча язылган чыганакларда атамасы *«Бикчураево», «Чурашево»* буларак языла.

3. Элекке *Түбән Чаллы* авылының **Тәберде Чаллысы** авылы булып китүе дә 1619 елгы документта авыл җитәкчесе буларак искә алынган **Тереберде Уразлыев**ка бәйле.

4. *Би Йорт-Иске Йорт,* кайбер документларда **Шихаздә Сатлыганы** буларак аталып йөргән бүгенге **Сатлыган** авылы да XVII гасыр башында яшәгән авыл башы **Сатлыган Байгильдеев**ка бәйле тарихка кереп калган. Төбәктәге Кадряк (Кадрәк мирза), Бирдебәк, Мәшләк[9] (Әлмәш – әл-Мөхәммәд) кебек авылларның атамасында да кеше исемнәре ята.

Авыллар атамасының үзгәрешен соңрак чорга караган документлар буенча да билгеләргә була. Мәсәлән, элекке чорда **Чаллы (Исен)** авылында тирә-як авылларының йөзбашы **Үрәй** улы **Мансур** яшәгән[10]. Без бу авылны бүгенге көндә керәшен татарлары яшәгән Үри Чаллысы авылы буларак беләбез. Бер риваятьтә әлеге авыл атамасының килеп чыгышы үр менгәндәге авыл, икенчесендә, имеш, монда Үринә

[9] *«Починок Машляк, что было деревне Алмяшию»*, – дип, Зур Мәшләк авылында Чаллы төбәге авыллары белән идарә итүче йөзбашы Әлмәш (әл-Мөхәммәд) торганлыгы хәбәр ителә. РГАДА. Ф. 350, оп. 1, д. 153, л. 178.

[10] РГАДА. Ф. 350, оп. 2, д. 1208, л. 1а.




**Шомбыт елгасы буендагы шәһәрлекнең картасы (Толмачев, 1884)**

дигән бай хатын яшәгән дип сөйләнә иде. 1678 елга чаклы, Керәшен Казаклары *(XVII гасырдан соң көчерелгән, чукындырылган татар морзалары)* авылыннан башка, Чаллы төбәгендә бер генә керәшен авылы да булмаган.

Авыллар атамасындагы һәм аларның килеп чыгуына бәйле үзгәрешләр төбәктәге башка авылларга да хас. Тагын бер мисал: Балык Бистәсе районына кергән Балтач авылы документларда күп очракта – **Юлсубино,** халык телендә **Балтач** атамасы белән йөртелә. Аның килеп чыгышы турында төрлечә сөйлиләр. Имеш, авылга нигез салучылар, аның суын эчеп карагач: «Суы тач бал икән», – диләр дә, шуннан Балтач исеме алынган. Авылга бәйле 1642-1646 нчы елларга караган документның берсендә: «... деревни **Елсуби//ны** Тлякейко **Балтачов**», икенчесендә исә: «...деревни **Балтачевы** // Тлекея **Балтачева**», – дип аңлатып узыла[11]. Әмма авыл атамасының килеп чыгышын ялгыш аңлату бүгенгәчә дәвам итә.

Борынгы Чаллы төбәгендәге бериш авылларның барлыкка килүе аларның кайда, кайчан, нинди җирдә һәм кемнәр урнашуларына бәйле дә кушылган. Мәсәлән, Алан-Полян, Ташлык, Зәңгәркүл (Кыерлы, Алан), Чыршылы Елга, Яңа Авыл, Яңа Сала, Чаллыбашы, Шомыртбашы, Мукшы Чаллысы, Казаклар, Түләк авыллары атамалары моңа ачыклык кертә.

Соңрак чорда төбәктә урнашкан урыс авылларының атамаларында да шул бер үк дәвамчылык. Төбәктәге (бүгенге көндә инде өлешчә юкка чыккан авыллар) Степановка, Николаевка, Тукбулат-Иванай кебек авыл атамалары үзләренең беренче нигез салучыларына бәйле кушылган. ■

[11] РГАДА. Ф. 1209, оп. 2, кн. 6481. Отказные, отдельные, обыскные, межевые и мерные книги поместных, вотчинных и пустых земель Казанского уезда. 1642-1646 гг. Документ тарих фәннәре кандидаты Рәфыйк Насыйров тарафыннан табылып эшкәртелде. Фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелә.

Безнең мирас №12 декабрь 2020

# Шәмсуар йолдызлыгы

Фәүзия Бәйрәмова



**Суар кирмәне.** ***А.П.Смирнов реконструкциясе***

Без, чын мәгънәсендә, тарихның өстеннән таптап йөрибез...

Борынгы төрки-татар тарихы өстеннән, җир астында калган таш калалар, агач салалар, меңьеллык курган-каберлекләр, дәүләтчелегебез өстеннән таптап йөрибез без... Кайдадыр борынгы нигезләр таралып, ыңгырашып ята, кайдадыр кабер ташлары җиргә чүккән, кайдадыр сызгырып очкан ук башлары, сынык беләзекләр, әллә көтүче, әллә хан кесәсеннән төшеп калган тәңкә-акчалар җемелдәп ята... Кайдадыр инде буш кыр, кайдадыр музейлар эшләп тора, әле һаман кайдадыр нидер табылып тора. Болар барысы да безнең тарих – татар тарихы бит!

Шуңа игътибар иттем: төрки-татарның бөек дәүләтчелек тарихы да, ислам тарихы да нәкъ менә Чулман-Кама аръягында – Биләр, Суар һәм Болгарда башлана икән! Казан, нигездә, Казан ханлыгы белән тарихка кереп калды, аның аңа кадәрге чорыннан да, аннан соңгы дәвереннән дә күрсәтер ядкярләр, таяныр чыганаклар әллә ни юк. Ә Чулман аръягында ул борынгылык – аяк атлаган саен, гарәп-Европа чыганаклары да меңьеллык Биләр-Суар-Болгарны тарихка теркәп калдырган бит! Бу чагыштыру Казан белән Кама аръягын капма-каршы кую өчен әйтелми, ә киресенчә, борынгы бу төбәккә игътибарны күбрәк җәлеп итү өчен языла.

Болгар-Биләр тарихы буенча үзем дә шактый яздым, ә менә Суарга барып җиткәнем юк иде әле. Һәм, ниһаять, быелның август башында, мин дә борынгы Суар каласы булган урыннарга килеп җиттем. Ул Спас районының Кузнечиха авылы янында булып чыкты, ягъни Шәһре Болгардан 60-70 чакрымнар ераклыкта. Анда барганчы, тарихи Нурсуар-Шәмсуар каласы, Суар бәклеге турында галимнәр язган хезмәтләр белән таныштым, ә алар әллә ни күп түгел иде. Күргәннәремне

тасвирлый башлаганчы, Суар турында белгәннәремне укучылар белән уртаклашырга булдым.

## Суарда 10 мең кеше яшәгән!

«Википедия» сайтында Суар турында мәгълүмат әллә ни күп түгел. Моны аңларга да була, чөнки бу тема шактый аз өйрәнелгән, материал җитәрлек түгел. Булган кадәре белән укучыларны да таныштырабыз: «В сочинениях восточных авторов он упоминается, наряду с городом Булгаром, еще в 920-х годах. По сведениям арабского географа Абу Заида ал-Балхи, в Суваре, количество жителей которого достигала 10 тысяч человек, находилась «главная мечеть». Ягъни ул вакытта ук Суарда 10 мең кеше яшәгән һәм Җәмигъ мәчет булган! Галимнәрнең әйтүенчә, Суар шәһәре 100 гектар чамасы җирне биләгән, шул заман өчен бу инде шактый зур мәйдан. Ул чакта әлеге төбәктә генә түгел, бөтен Евразиядә иң зур шәһәрләрнең берсе булып Биләр саналган, аның мәйданы 800 гектар булып, халкы йөз меңгә хәтле җиткән. Биләрдән ерак түгел каян килеп тагы икенче шундый зур шәһәр үсеп чыккан соң? Һәм нигә ул Суар дип аталган?

«Татар энциклопедия сүзлеге»ндә суар-савирлар, Суар-Сувар шәһәрлеге һәм бәклеге турында шактый җентекле мәгълүмат бирелгән. Аннан күренгәнчә, бу суар-савирларның төп Ана Ватаны – Каспий диңгезе, Төньяк Кавказ тирәләре, үзләре «хәзәрләргә кардәш күчмә кабиләләр». «Этник чыгышлары һуннар токымыннан дип уйланыла, – дип яза галимнәр. – Савирларны (суарларны) беренче мәртәбә 2 нче йөздә Птоломей телгә ала. Төньяк Кавказда зур хәрби көч буларак, аларны Сасанилар Ираны һәм Византия үзара көрәштә үз максатларында файдалана».

## Суарлар Идел-Чулман буйларына ничек килеп чыкканнар?

Бу гайрәтле савир-суарлар башта Көнбатыш Төрки каһанлыгы составында булалар, чөнки үзләре дә – төрки кавем, аннан инде, 630 нчы еллар тирәсендә, Хәзәр каһанлыгы кул астына керәләр, чөнки алары да кардәш халык. Дөньякүләм танылган дәүләтләр хакимлегендә яшәсәләр дә, савир-сабирларның бередә үз мөстәкыйль патшалыклары, хәзерге Дагыстан территориясендә хәтта Суар дип аталган шәһәрләре дә була. Ә безнең якларга – Идел-Чулман буйларына ничек килеп чыккан соң бу дала-тау халкы? «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә галимнәр моңа болай дип җавап бирә: *«Гарәп-хәзәр сугышлары барышында, 8 нче йөздә савир-суарларның бер өлеше Урта Идел буйларына күчеп килә, анда Суар бәклеге оеша, алар тарихта суарлар исеме белән таныла. Соңрак суарлар җирле төрки телле кабиләләр белән этник болгар бердәмлеген тудыралар»*.

Ягъни бу суарлар Каф тауларыннан Идел-Чулман буйларына болгарлар белән бер чордарак яки алардан да алдарак күчеп килгән булалар?! Ә ни өчен нәкъ бирегә? Чөнки бу төбәк халкы да заманында иксез-чиксез Төрки каһанлыкка керә, аннан Хәзәр дәүләте составында яши башлый. Чөнки анда да, монда да бер тел – төрки тел, хәтта дин дә бер булырга тиеш, чөнки ислам дине безнең якларга инде болгарларга хәтле үк үтеп кергән була. Шулай булгач, суарлар бирегә үз кан кардәшләре янына килеп төпләнәләр. Әйтик, галим Мәсгуд Гайнетдин Биләр

төбәгендә «би ирләре» – «патша скифлары» дип аталган төрки халык яшәгәнлеге, аларның төньяктагы бөтен мех сәүдәсен үз кулларында тотуы, «татарларның борынгы скиф бабалары» булулары турында яза. Ул шулай ук «би ирләре»нең инде VII гасыр урталарында ук ислам динендә булуларын искәртә.

Суарның Биләрдән дә 70-80 чакрымнарда гына икәнлеген, бу төбәктә элек-электән, әле болгарларга хәтле үк, төп төрки кавем яшәвен, суарларның да алар арасына иңеп, бер халыкка – хәзерге татар милләтенә әйләнүен әйтергә кирәк. Инде тагы энциклопедик сүзлеккә килик. Аннан күренгәнчә, *«Суар (Сувар), урта гасырлардагы (9-14 нче йөзләр) – Идел буе Болгары шәһәре, Суар бәклеге башкаласы (948-75). Иделнең сул кушылдыгы Үтәк елгасының югары агымында урнашкан була, 10 нчы йөздә анда акча сугыла. Идел буе Болгарының эре сәяси, икътисади һәм сәүдә үзәге».*

Бу – фәндә кабул ителгән рәсми фикер. Әмма Болгар бәклеге ул вакытта үзе дә Хәзәр каһанлыгы составында була, Суар бәклеге дә, аерым, мөстәкыйль бәрәмлек булып, каһанлык хакимиятенә керә. Хәсәнгата Габәши үзенең «Мөфассал тарих кауме төрки» хезмәтендә, гарәп һәм грек тарихчыларының Болгарны да, Суарны да, хәтта Казанны да хәзәр шәһәрләре дип атауларын яза. Безнең фикеребезчә, Суар бәклеге, Болгарга караганда, «Бөек шәһәр» дип аталган Биләр белән күбрәк элемтә тоткан булырга тиеш. Галимнәрнең язуынча, Суар бәклеге 940 нчы еллар тирәсендә барлыкка килә, аның белән Габдулла бине Микаил, Талиб бине Әхмәд, Мөэмин бине Әхмәд идарә иткәнлеге билгеле. Суар бәклеге *«975 нче елда Болгар бәклеге белән берләшә. 11-13 нче йөзләрдә Идел буе Болгарының административ-терр. бүленеш төбәге (өлкәсе)»,* – дип яза «Татар энциклопедия сүзлеге».

«Википедия» сайтында да Суарның Болгардан бәйсез булуын ассызыклаганнар, моны Суар бәкләренең үз акчаларын сугулары белән дәлилләгәннәр. *«Правители Сувара Талиб ибн-Ахмад и Мумин ибн-Ахмад вплоть до 970-х годов чеканили свои собственные монеты.Данный факт свидетельствует о том,что Сувар с момента своего возникновения и практически до конца X столетия являлся центром обособленного княжества – эмирата, политически независимого от Булгарского».* Шунысын да әйтергә кирәк, Суарда сугылган акчалар узган гасырларда Рязань, Псков һәм Тверь губерналарында, хәтта ерак Скандинавия иле Даниядә дә табыла.

## Суар – халык авыз иҗатында

Игътибар итсәгез, бәклек тә, аның башкаласы да суар кабиләсенең исеме белән аталган. Аларның Каспий диңгезе буйларында яшәгәндә үк суар дип аталганнарын истә тотсак, әлеге атаманы су ирләре дип тә, гаскәри (сугышчан) ирләр дип тә тәрҗемә итәргә мөмкин. Шулай ук бу тирәдәге елгаларда сусар дип аталган су җәнлеге күп булганлыгын, җирле халыкның сусар тиресе (мехы) белән сәүдә иткәнлеген дә әйтеп үтәргә кирәк. Татар халык иҗатында Суар сирәк телгә алына, алай да бар. Мәхмүт Кашгарыйның 1074 елда дөнья күргән «Диване лөгатет-төрек» сүзлек-китабына «Суар кешеләре җыры» да кертелгән:

*«Барды саңа йәк,*
*Утру тотыб бал.*
*Барчин, кедибән,*
*Телү, йуга булып кал.*
*Арды сине кыз,*

*Буйы аның – тал.*
*Яйлыр аның артачы*
*Борны тәкый кывал».*

Мең ел элек язылган бу җыруның бүгенгегә тәрҗемәсе болайрак: *«Барды сиңа юха (шайтан), каршыңа тотып бал. Парча (ефәк) киенгән, тели, юка (зәгыйфь) булып кал. Алдады сине кыз, буе аның – тал. Артыштай чәчләре йөзен чорнаган, борыны да төз».*

Тагы берничә борынгы риваятьтә Суар Биләр-Болгарлар янәшәсендә санап кына кителә. Алай да «Гәрәй хан» риваятендә Суарга киңрәк тукталынган, чөнки Гәрәй ханның каласы Суардан ерак булмаган, аның хәрабәләре – хәзерге Әлки районының Нухрат авылы басуында. Ә бу истәлекне 1928 елда шушы як халкыннан галим Сәет Вахиди язып алган булган: *«...Гәрәй хан каласыннан Шәһри Болгарга, Биләргә, Суарга, Кашан калага урман эченнән яшерен юл булган, ди. Читтән яу чабу куркынычы булганда, бу яшерен урман сукмагыннан Шәһри Болгарга, Биләргә, Суарга һәм Кашан калага тиз арада яу килүен хәбәр итәләр икән».* Әлеге төбәктәге татарларның яшерен юллары, җир асты юлы, ханнар-солтаннар юлы турында минем дә ишеткәнем бар, очына гына чыкканым юк...

Тарихчы Равил Фәхретдинов, бу тирәдәге татар авылларында булып, гасырлар үтсә дә, халыкның Суарны онытмавын, сагынып искә алуларын яза: *«Шәһәрне, олылап, Шәм Суар дип атыйлар. Суарга карата «Шәм» эпитетын моңарчы бер җирдә дә ишеткәнем юк иде. Дөрес, шәһәрләргә карата бу сүзне куллану гомумән очрый. ... «Шәм» эпитеты, шәһәрләргә карата кулланганда, аларның бөеклеген, данлыклы, шөһрәтле булуын аңлата, ахры. Күренекле эпиграфист, этнограф һәм археолог Һарун ага Йосыпов Шәм Суардагы «Шәм»нең гүзәллек, яктылык символы булуы мөмкин дигән иде. Мөгаен, шулайдыр. «Шәмс» – гарәпчә, кояш дигән сүз. Шул сүздән булса кирәк, «шәмсә», ягъни орнамент сүзе дә ясала. Татарлар арасында Шәмсуаров фамилияле кешеләр дә очрый. Мондый фамилиянең Шәм Суарга нисбәтле булуы бик мөмкин. Гомумән, халкыбызның бүгенге көндә үзенең борынгы шәһәрен истә тотуы һәм аны олылап телгә алуы бик матур бер күренеш».*

«Идегәй» дастанында бер урында «Астаналы Сивар» дигән атама бар, ул урыс басып алган ундүрт шәһәр арасына кертелгән. Фәнни әдәбиятта ул Сувар-Сивар, дип тә, Габәшидә Сувар-Сәфәр дип, кайбер очракларда хәтта савир-сабир, саба ире, сибир-сыпыр дип тә тамгаланган. Чуашлар, үз якларына борып, аны савар,

* Фотоларда - Суар музей-тыюлыгы экспонатлары

суас дип атыйлар, Суарны үзләренеке итү өчен, алар хәтта чуаш атамасын суаска әйләндерергә дә әзер! Ул чагында Каспий диңгезе буйларында, Каф тауларында яшәгән суарлар да чуваш буламыни инде?!.

## Шиһабетдин Мәрҗани суар-бортас тәңгәллеге турында

Шиһабетдин Мәрҗанинең Казан һәм Болгар хәлләре турындагы тарихи хезмәтендә Суар бу мәмләкәттә булган 29 шәһәр арасында өченче булып телгә алынган, бу үзе үк аның аерым әһәмияткә лаек икәнен күрсәтә. Шунысын да әйтергә кирәк, 1860, 1870 нче елларда Шиһаб хәзрәт Шәһре Болгарда һәм Суар янәшәсендәге Иске Рәҗәп авылында була, аның имамы Габделваһһаб мулладан бу як тарихы турында күп мәгълүмат ала. 1872 елда Мәрҗани шушы татар-мишәр авылыннан 1344 елгы кабер ташы да таба.

Шиһаб хәзрәтнең югарыда телгә алган китабын тагы бер тапкыр җентекләп укып чыккач, ул үзе дә Суар-Кузнечиха тирәләрендә булмадымы икән дигән фикер калды. Чөнки кайда икәнлеген бик белеп яза, урынын да күрсәтә. Бу мәгълүмат бик мөһим булганга, аны укучыларга да тәкъдим итәргә булдым: *«Бу юлларны җыючы фәкыйрь әйтә (ягъни үзе. – **Ф.Б.**): бу бортас халкының нинди халык булуы безгә мәгълүм булмады, без белгән Суар шәһәренең хәрабәсе Спас өязендә шәһре Болгарга бик якын бер җирдә сакланып калган. Шул тирә мөселманнары әле дә ул урынны «Суар» дип йөртәләр. Әйләнәсендә уры бар. Җимерелгән шәһәр урынында бер урыс авылы утыра. Аны, үзләренчә, «Иске Курсиха» дип атыйлар. Тирә-ягында күчмә халыклар яшәгәннәр. Алардан калган иске каберлекләр бар. Каберләре бик беленеп тора. Аларны «нугай» халыклары диләр».*

Урларына хәтле күргәч, димәк, ул үзе дә монда булган?! Борынгы шәһәрлекне әйләндереп алган ул тирән урлар хәзер дә бар әле, заманасында анда су җибәреп, көймәләр белән йөзеп йөргәннәр, диләр. Мәрҗанинең җимерелгән шәһәр урынында бер рус авылы утыра. Аны, үзләренчә, «Иске Курсиха» дип атыйлар» дигән хәбәре дә безнең өчен бик мөһим. Сүз Кузнечиха авылы турында бара, ә ул Суар шәһәрлеге урыныннан 3-4 чакрым ераклыкта. Димәк, борынгы татар шәһәре шушы урынга хәтле таралган булган?! Җирле халык хәзер дә Кузнечиханы Суар яки Яңа Суар дип атый, ягъни бу урыс авылын татар каласы хәрабәләре өстенә китереп салганнар?!. Шулай ук халык арасында аның «Ордынский Сувар» дигән. атамасы да сакланган, ягъни Болгар чорыннан гына түгел, Алтын Урда чорыннан да калган Суар. Кузнечиха авылында Алтын Урда ядкярләренең бүген дә табылып торуы шул хакта сөйли.

Шиһабетдин Мәрҗанинең бу хезмәтендә безне кызыксындырган тагы бер әһәмиятле мизгел бар, ул – бортас темасы, чөнки автор аны суарлар белән бәйләп өйрәнгән. Ягъни суарларның ерак тарихта бортас атамалары да булган булырга мөмкин. Шиһаб хәзрәт күп кенә гарәп галимнәренең бортаслар турында әйткән фикерләрен язып үткән, ә алар бик кызыклы. Әйтик, Шәмсетдин әд-Димәшкый: *«Бортаслар – Иделгә килеп кушыла торган Бортас елгасы буена утырган аерым кавем. Аларның өйләре – агач, ә чатырлары киездән эшләнгән. ... үзләренең аерым телләре бар»,* – дип яза. Әбү Габдулла әл-Гарнатый: «*Бортас – бер кавемнең исемедер, Идел елгасы буенда киң мәмләкәтләре бар. Хәзәр белән чиктәш булып, араларында башка халык юк. Үзләренә бәйләп, илләре дә «Бортас иле» дип атала. Телләре болгар һәм хәзәр телләреннән аерыла. ... Үзләре мөселман булып, җәмигъ мәчетләре бар»,* – дигән. Әбү Гали Ибне Дастә исә бортасларның Хәзәр белән Болгар арасында яшәүләрен әйтә, болгарлар белән сугышып торуларын да яза. *«Киемнәре һәм каберләре мөселманнарныкы кебек, һәр мәхәлләләрендә бер шәехләре була, аңа хөкемгә киләләр, шуннан башка хакимнәре һәм башлыклары юк»,* – ди.

Якут әл-Хәмәви исә бортасларны аерым бер шәһәр һәм өлкә әһелләре, җәмигъ мәчетле мөселманнар, дип яза. *«Алардан ерак түгел «Суар» дип атала торган бер шәһәр бар. Аларның телләре төрки, хәзәр һәм болгар телләре шикелле түгел»,* – ди. Әбү Габдулла әл-Гарнатый Болгар каласы турында мәгълүмат бирә дә: *«Аннан ерак түгел «Суар» исемле икенче шәһәр бар. Аның да җомга укыла торган мәчете бар. Бу ике шәһәрдә ун меңләп өй бар»,* – дип яза. Ягъни Болгар белән Суар ул вакытларда кеше һәм өй саны буенча бертигез дәрәҗәдә булганнар.

Сүзебез бортас-суар тәңгәллеге турында иде. Мәрҗани үзе дә бу сорауга өздереп җавап бирә алмый. *«Бортас халкы шул тирәдә яшәгән халык түгелме икән диясе килә,* – дип яза ул. – *Чөнки аларның телләре хәзер дә Казан мөселманнары теленнән аерылып тора. Тау ягының Тәтеш өязендә «Олы Бортас», «Кече Бортас» исемле ике авыл бар».* Ул тирәдәге авылларда яшәүче халык бүген мишәрләр дип атала, борынгы суар-бортасларның нәсел дәвамчылары да алар булырга мөмкин. Бу мишәрләр төс-битләре, тышкы кыяфәтләре, хәтта холык-фигыльләре белән дә Казан татарларыннан шактый аерылып торалар. Бортасларның тарихи яктан тупланып яшәгән урыннары итеп хәзерге Пенза өлкәсен дә күрсәтәләр, борынгы Бортас, Юлау, Наровчат шәһәрлекләре дә бирелә. Һәм бу төбәктә яшәүчеләр дә – мишәрләр. Суар тарихын өйрәнгән тарихчы-археолог Фаяз Хуҗин XII гасыр галиме әл-Идрисинең Суарны бортас шәһәрләре рәтенә кертүен яза.

*Ахыры киләсе санда* ■

**Редакциядән:**

***Журналыбызның авторы, танылган язучы һәм галимә Фәүзия Бәйрәмованың 5 декабрьдә гомер бәйрәме. Аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!***

*Татар матбугаты тарихы*

# «Безнең тавыш» газетасы

**Габделгазиз Монасыйпов хатыны Зәйнәп Камалова (Галиәсгар Камалның сеңлесе) белән. 1918 ел**

**Габделгазиз Габдерахман улы Монасыйпов (1888-1922)** – шагыйрь, драматург, прозаик, журналист, сәясәтче, полк мулласы. Арча районының Байкал авылында мулла гаиләсендә туган. 1902-1908 нче елларда Кытайның Шеңҗан өлкәсендә яши. 1917 елдан Мөселман Хәрби шурасы рәисе урынбасары, «Безнең тавыш» газетасының мөхәррире, Мөселман революцион штабының рәисе, татар отрядларын («тимер дружиналар») оештыручы. 1922 елны Ташкентта нәшрият кәгазен кулга төшергән өчен төрмәгә ябыла. «Милләтчел пропаганда» алып барырга әзерләнүдә гаепләнеп, ВЧК тарафыннан хөкем ителеп, атып үтерелә.

Газетаның тулы исеме – «Безнең тавыш һәм Бөтенрусия мөселманнары Хәрби Шурасының хәбәрләре». Ул 1917 елның июнендә тарала башлый. Бөтенрусия Хәрби Шурасы органы буларак, «Безнең тавыш» мөселман гаскәриләренең съездлары яңалыкларын, фронт хәбәрләрен яктырта, мөселман роталары һәм полклары оештыру мәсьәләләрен күтәрә, татар солдатларының матди һәм рухи мәнфәгатьләрен кайгырта.

Матбугат белгече Исмәгыйль Рәмиев газета турында: *«Февраль революциясеннән соң көчәйгән милли кузгалышны буржуа һәм советка каршы контрреволюциягә борып алып китү юлында күп көч салган татар әфитсәрләренең органы иде»*, – дип яза.

«Безнең тавыш» Казандагы «Өмид» типографиясендә атнасына 2-3 мәртәбә басылган. Баш мөхәррире – солдат Габделгазиз Монасыйпов, язышучылары – Садри Җәләл, Фатих Әмирхан, Хәлил Әбелхан, Әхмәдсолтан Таһиров һ.б. Газетаның идарәханәсе «Апанаевское подворье» номерларында өске катта (88 нче номерда) урнашкан була. Соңрак ул Лобачевский урамындагы Стахиев йортына күчә.

Газетаның эшчәнлеге 1918 елның 18 мартында Хәрби Шура белән бергә туктала. Аның барлыгы 88 саны чыгарга өлгерә.

«Безнең тавыш»та басылган кайбер мәкаләләрне сезнең хозурга да тәкъдим итәбез.

## Фронттагы милли хәрәкәт

6 июльдә 2 нче армия комитетыннан подпоручик Гәрәев әфәнде белән 3 нче армиягә аларның организацияләренең хәле белән танышмакчы булып бардык. Ләкин аларда оешма-фәлән юк икән әле. Әүвәлдә муллаларына барып хәлне сөйләдек, ләкин алар оешмалар ясаудан курку кебек бер хәл аңлаттылар. Без хәлне аңлатып биргәч, алар оешмалар ясауның кирәклеген беравыздан икърар иттеләр. Безнең аларга баруыбыз гаеткә туры килгәнлектән, шунда ук халыкны җыеп, үзләре арасыннан Мөселмански комитетка 12 әгъзадан гыйбарәт президиум сайланды. Западный фронттагы һәр армиядән икешәр кеше җыелып, Мински шәһәрендә «Культурный-просветительная группа» оештыру өчен 3 нче армиядән 2 кеше Минскига килдек. Шул хакта фронтовой комитетка мөрәҗәгать кылдык, комитет, безнең сорауларыбызны кабул итеп, безгә собрание өчен йорт алып бирде. Берничә көннән соң үзебез өчен файдалы карарлар чыгардык. Шул карарларны раслатыр өчен Вакытлы хөкүмәткә җибәрергә ике кешене вәкил итеп сайладылар. Башка фронт мөселманнары да үз эшләрен безгә белдереп торсалар иде.

2 нче воздухоплавательный отряд солдаты: Гарифулла Фәйзуллин.

*Безнең тавыш. – 1917. – №19. – 8 август.*




«Безнең тавыш» газетасы

## Фронттагы милли хәят

26 июльдә көнбатыш фронт имамы Мирсәед әфәнде Хафизов белән әлеге фронт составында булган армияләргә чыгып, җәяүле дивизиядә булдык. Хәзрәт әсәрле нотыклар вә тәмле-тәмле вәгазьләр сөйләгәннән соң, фронт комитеты янында булган «Мөселманнарны яктырту группасы» файдасына иганә җыелды. Иганә исеме чыгу белән, соры шинельле Ватан каһарманнары җәйгән яулыкка ябырыла башладылар. Ике-өч минут арасында 44 сум 13 тиен акча җыйнап алдылар. Актык бер тиеннәрен бу солдатларның әллә нинди милли хисләр белән милләт файдасына иганә итүләре дикъкатьне җәлеп кылмаслык түгел иде.

Мәһди Мортазин.

*Безнең тавыш. – 1917. – №19. – 8 август.*

## Фронттан

46 нчы этапный батальон мөселманнары җыелып, батальоныбызда мөселманнар өчен китапханә ачарга карар бирдек. Батальонный комитеттан – 25 вә үзебездән 25 сум акча җыеп, китапханәбезгә юлбашчы куйдык. Бу 50 сум акча китапханәбез өчен аз булу сәбәпле, һиммәтле мөселман кардәшләребездән иганә итүләрен үтенәмез.

Адрес: Действующая армия 56-й этапн. батальон, 2-я рота.
Абдулкадиру Губайдуллину.

*Безнең тавыш. – 1917. – №19. – 8 август.*

## Казан губернасындагы мөселман гаскәриләренә мәүлид бәйрәме булу мөнәсәбәте илә зур парад

13 декабрьдә, һаваның ярыйсы гына суыклыгына карамыйча, алдан газеталарда хәбәр ителгәнчә, Казан гарнизонындагы бөтен мөселман гаскәрләренә зур парад ясалып узды. Рус гаскәриләре арасында соңгы вакытларда чын мәгънәсе белән бер башбаштаклык дәвам иткәндә, рус әфитсәрләре, рус гаскәр башлыклары ун кешедән гыйбарәт бер кечкенә команданы да тәртипле сурәттә алып бара алмаганда, безнең гаскәрләребезнең шулкадәр тәртипле, шулкадәр тантаналы бер ыстрой мәйданга китерә, алулары чыннан да, бөтен татар өчен шатлыклы бер вакыйга.

Казан гарнизонында булган бөтен мөселман җәяүле һәм атлы гаскәрләре хазир булганнар *(җыелганнар)* иде. Татар милләтенең таянычы булган шанлы мөселман гаскәриләрен күрергә Казанның бөтен кешесе: ире, хатыны, баласы-чагасы, карты, яше, кыскасы, татарның рәхәте өчен шатланган бөтен кешесе Юнысовлар мәйданына җыелган иде. Бар да тәртип белән тезелгән, дошманнарның эчендә курку, дусларның эчендә шатлык һәм мактану... Алар уяндыра торган атлы вә җәяүле гаскәриләребезгә сокланып карыйлар иде. Парадка Казанда булган Хәрби Шура, Казан округы хәрби комитеты вә Казан хәрби комитеты әгъзалары бөтенесе хазир иде. Аларның барысының да йөзендә бу көн шатлык сизелә иде.

Бөтен халык җыелып беткәч, Габдулла мелла Апанаев тарафыннан гаять тәэсирле Коръән укылды. Коръән укылганнан соң, гаскәрләр музыканың шатлыклы тавышлары астында берсе артыннан берсе уза башладылар.

*Безнең тавыш. – 1917. – №55. – 15 декабрь.*

## Балалар бакчасы

10 гыйнварда Казанда «Мөселманнар җәмгыяте» тарафыннан балалар бакчасы ачылачак. 4тән 7 яшькә кадәрле булган ир вә кыз балалардан әлегә барысы 35 бала алына. Укыту вә тәрбия хакы шул ачылу вакытыннан май 10ысына кадәр һәр балага 75 сум булып, ашату-эчертү өчен һәр айга 20 сум алыначак. Шулардан 10 урын түләп укытырга хәле булмаган ятимнәр өчен булып, болар язылып беткәннән соң, җирәбә белән алыначаклар. Балаларын бирергә теләүчеләр хәзердән Большой Мещанский урам, Ногман Габделкәримов йортындагы җәмгыять фатирына барып язылырга тиеш*.

*Безнең тавыш. – 1918. – №25. – 5 гыйнвар.*

---

* Бу Казанда татар балалары өчен ачылган иң беренче балалар бакчасы булмадымы икән? – ***Ред.***

## Фронтта мөселман ротасы

12 нче армия башкаручы комитеты дивизияләрендә иң элек төзелгән мөселман ротасына приз итеп яшел байрак бирергә вәгъдә кылган иде. Менә шул байракны 20 нче Сибирски уклы дивизия алырга муәффәкъ булды *(иреште)*. Димәк, 12 нче армиядә иң элек төзелгән беренче мөселман ротасы 20 нче дивизиядә булды.

20 нче дивизиядәге мөселман солдатларының 8-9 айдан бирле тилмереп көткән теләге бу көн инде вөҗүдкә чыкты *(гамәлгә ашты)*. 79 нчы полкта яңа гына таратылган учебный команданың урыны, 5 аты, кухнәсе вә башка кирәкле нәрсәләре мөселман ротасына бирелде.

Декабрь 18ендә парад ясалып, флаг бирелде. Рота киң генә бер площадька чыгып тезелгән иде. Менә бервакыт яшел байракны күтәреп иң алда 12 нче армия комитеты әгъзаларыннан Мостафа Сафин, аның артыннан дивизионный комитет әгъзалары һәм дә курсистлар килә иде. Флаг якынлашкач, музыка белән каршы алынды. Флаг ротаның урталыгына килеп туктагач, өч мәртәбә тәкъбир әйтелде. Курсистлар, байракны котлап, «Татар каһарманнарына» дигән шигырьне җырладылар. Бу айлы-йолдызлы байрак астында татар гаскәренең әллә нинди дәрт вә шатлык белән җырлаган җырулары, музыка тавышы йөрәкләрне тетрәтә, уйларны әллә кайсы заманнарга күчерә, әллә кайчангы Чыңгызларны, тагы әллә кемнәрне күз алдына бастыра иде. Армия комитетыннан флаг китергән вәкил Сафин, 12 нче армиянең 20 нче дивизиясен – иң элек төзелгән беренче мөселман ротасын тәбрик итә, моңа үзенең шатлыгын вә шулай ук барча мөселманнар да шатланырга тиешлеген сөйли.

Начальник дивизии: «Без – руслар белән татарлар Ватанның балалары, без – бертуганнарбыз. Без бу көнгә кадәр кулга-кул тотышып, бик татулашып килдек. Мин ышанамын ки, моннан соң да шулай ук берлектә тату яшәрбез. Һичвакыт туган туганга кул күтәрмәс.

Иптәшләр! Мин сезне, берлеккә өндәп, эшләрегезгә уңыш телим. Яшәсен рус вә татар берлеге! Яшәсен татар рота вә полклары! Яшәсен хөррият! Ура!» – ди.

Командаларның барысы да татарча бирелде. Яшь татар әфитсәре Терегулов әфәнденең: «Тигезлән! Уңга борыл!» – дигән тавышлары бик сөйкемле ишетелә иде. Чынлап та, татарның бер милләт булуы, аның да адәм төсле теле, үзенә аерым гаскәре барлыгы искә төшеп, җанга әллә нинди рәхәтләр бирә иде.

Парад гаять тәртипле үтте. Начальник дивизии дә: «Менә тәртип ичмасам!» – дип куйды.

Рота казармага кайтып җиткәнче музыка белән китерелде. Казармага кайткач та халык шат вә бу көн тарихи бер бәйрәм иде. Һаман да музыка уйналды, җырланды. Дивизионный комитет әгъзаларын «Ура!» кычкырып күтәрделәр.

Шул көн кич белән спектакль куелды. Урыслар белән латышлардан да халык күп иде. Антракт вакытларында музыка уйналып торды. Ахырда тансалар булып, халык төнге сәгать 3тә генә таралды.

Мөселман ротасына башка дивизияләрдән дә килә башладылар. Тиздән икенче рота төзеләчәк. Халык күбрәк килсә, батальон төзергә дә уйлана.

*Безнең тавыш. – 1918. – №25. – 5 гыйнвар.*

*Текстны журналга* ***Ленар Гобәйдуллин***
*һәм* ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

# Әтрәч укулары: болгар-татар нумизматик мирасы

3 нче октябрь көнне Тәтеш районының Югары һәм Кече Әтрәч авылларында «Әтрәч укулары» узды. Укуларның быелгы темасы болгар-татар нумизматик мирасына багышланган иде. Мәдәният йортында нумизматлар **Марат Нәҗип улы Минһаҗев** һәм **Ильяс Ансар улы Мөлеков** күргәзмә оештырды. Тарих белән кызыксынучы, милли мирасыбызга битараф булмаган бу егетләргә берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

## Марат Минһаҗев: *«Болгар тәңкәләре басуда чәчелеп ята иде»*

***– Марат әфәнде, бу тәңкәләрне кайлардан таптыгыз?***

– Әтрәч җирлегендә, Шонгат шәһәрлегендә, тау битләрендә табылган акчалар болар. Араларында хатын-кыз бизәнгечләре, ук очлары да бар. Дөрес, кайберләре Аллабирде авылы кырларыннан килеп чыкты. Урта гасырларда бу җирләрдәге авыл һәм калаларда борынгы бабаларыбыз яшәгән. Безнең алда менә шулардан калган мирас инде.

***– Тәңкәләрне махсус эзләдегезме, әллә аларга очраклы гына юлыктыгызмы?***

– Махсус эзләдем дип әйтергә була, әмма казып йөргәнем булмады кебек.

***– Кызыксыну кайчан башланды?***

– Кызыксынуым балачактан ук килә. Дәү әниемә аның әнисе биреп калдырган көмеш акчаларны әле дә яхшы хәтерлим. Андагы ялтыравыклы тәңкәләр күз явын алырлык, затлы итеп сугылган иде. Бәлки, нумизматика белән кызыксынып китүемнең сәбәбе шуннандыр.

Әтием һәм бабаем Шонгат иле, Әтрәч калалары турында еш сөйләде. Бервакыт, кызыксынып, алар сөйләгән җиргә үзем барырга булдым. Шул көнне үк басуда 3-4 әзгәри акчасы таптым. Шулай итеп ел саен кырга йөри башладым. Мәктәптә укыганда, тракторчылар басуны сукалагач, велосипедларга утырып килеп җитә идек. Сука артыннан шушы тәңкәләр җир өстенә чыгып, яңгырдан соң аеруча ялтырап яталар, ә без аларны җыеп йөри торган идек. Тәңкәләрне җыеп кайткач, әтием: «Улым, җыеп куй, саклый күр! Боларда – бабаларыбызның тарихы! Бүген булмаса, бәлки, киләчәктә кирәк булырлар. Кызыксынуың өчен рәхмәт», – дип әйтә торган иде. Әти үзе дә тарихны ярата торган, бик укымышлы кеше булды, мәрхүм.

Үзем Аллабирдедән мин. Тәңкәләрне Әтрәч малайлары белән сугыша-сугыша җыя торган идек. Болгар шәһәрлеге урынына, тау битенә үтәр өчен Әтрәч авылы аша барырга кирәк. Шунда, Әтрәч егетләре чыгып, безне кыйнаштыргалап та җибәргәли иде, кайтканда тагын сагалап торалар… Без Аллабирдедән бер-ике малай киләбез, ә алар күп. Әмма моңа карап кына тарих белән кызыксыну кимемәде. Җиде чакрым килдек, кайту да шул чама, әле велосипедны тауга да этеп менәргә кирәк.

> «
> **Болгар шәһәрлеге урынына, тау битенә үтәр өчен Әтрәч авылы аша барырга кирәк. Шунда, Әтрәч егетләре чыгып, безне кыйнаштыргалап та җибәргәли иде, кайтканда тагын сагалап торалар…**

Ул вакытта нумизматик материаллар бик күп иде, соңгы елларда гына читтән «кара эзләүче»ләр килеп, татар мирасын чит-ятларга таратып бетерде.

***– Димәк, Сездә сакланып калганнары шушылар…***

– Әйе, коллекциямнең бер өлеше генә калды инде. Кайсын, башкалар да күрсен дип, музейларга, кайберләрен, бәлки, тарих белән күбрәк кызыксыналардыр, дип, белгечләргә бүләк иттем инде.

***– Бу тәңкәләр кайларда сугылган?***

– Галимнәр, Әтрәчтә Болгар дәүләтенең акча суга торган остаханәсе булган, дип әйтәләр. Әлбәттә, биредә Болгар, Сарай, Сарай әл-Җәдид, Барҗым калаларында сугылганнарын да күрәсез. Билгеле, сәүдә әйләнеше нәтиҗәсендә чит шәһәрләрдән дә килгәннәре бар. Археологлар белән элемтәдә торам. Алар миңа тәңкәләрнең даталарын, кайсы хан вакытында сугылганын ачыкларга ярдәм итә.

***– Коллекциядәге тәңкәләр арасында аеруча кызыклылары бармы?***

– Минем өчен аларның барысы да кызыклы. Монда VIII гасырдан алып 15 нче йөзгәчә кадәр булган тәңкәләрне күрергә мөмкин. Мәңгү-Тимер, Җанибәк һәм Үзбәк хан акчалары да бар. Менә XI-XII гасырдагы тиеннәрне күрәсез. Элек сәүдә әйләнешендә тиен тиресен акча берәмлеге рәвешендә файдаланганнар. Белгәнегезчә, 1240 нчы елларда гына Болгарда тәңкә суга башлыйлар.

Безнең мирас №12 декабрь 2020

***– Хәзер дә тәңкәләр җыясызмы?***

– Әлбәттә, кулга килеп кергәненә битараф кала алмыйсың инде. Әмма тарих белән кызыксынуым хобби гына. Үзем – шәхси эшмәкәр, кибет тотам. Буш вакытта эретеп ябыштыру, өйләргә җылылык системасын үткәрү белән шөгыльләнәм. Болгар бабаларыбыз кебек, сәүдә һәм һөнәрчелек белән кәсеп итәбез. Күршедәге Аллабирде авылында яшим. Мөнир абыйга рәхмәт! Ул әлеге бай тарихны киң җәмәгатьчелеккә җиткерүдә зур эшләр башкара. Безне дә шуңа җәлеп итә, белгечләрне, иганәчеләрне туплый. Кызганыч, хәзер белемебез, тарихтан мәгълүматыбыз артса да, кырларда археологик табылдыкларның саны бик кимеде. Дәүләт тарафыннан тиз арада тиешле археологик казулар оештырырга кирәк дип саныйм. Югыйсә бөтенләй соңга калуыбыз бар.

## Ильяс Мөлеков:
## *«Тимер Хуҗа тәңкәсе – иң кызыклысы»*

***– Ильяс әфәнде, коллекциягездә Әтрәч тәңкәләре генә түгел дип беләм...***

– Үзем Буа районыннан. Әнием – Яңа Тинчәледән, әтием – Кишер-Аксуы авылыннан. Тинчәле якларында да борынгы тәңкәләр табыла торган булган. Балачагымда әнием Миңнур Рәхимҗан кызы үткән вакыйгаларны еш сөйли торган иде. Яңа Тинчәле авылында ике су катышкан җир (инешнең Тинчәле елгасы белән кушылган урыны. ***– Ред.***) бар. Анда зәңгәр төстәге мунча ташы чыга. Үземнең аннан симбирцит, пирит минералларын, аммонит моллюскаларының кабырчыкларын да тапканым бар. Әниемнең сөйләве буенча, бервакыт шуннан безнең бабайның абыйсы, ма-

монт башы сөяген һәм мөгезен табып алып кайтып, ызбаның рәшәткәсенә элеп куя. Шунда ук Буага шалтыратып, музей хезмәткәрләре килеп алсын иде, ди. Мамонтның тулы скелетын казырга мөмкин булган урынны да күрсәтәчәген әйтә. Әмма аның сүзләрен игътибарсыз калдыралар. Шулай итеп, әлеге палеонтологик хәзинә озак еллар киртә башында эленеп тора, яңгырларда коелып бетә. Битарафлык нәтиҗәсендә, төбәк тарихы турындагы кызыклы бер ядкяр юкка чыга.

Үзем 2005-2011 нче елларда Мисырда югары дини белем алдым, гарәп телен үзләштердем. Андагы бай мирасны, музейларны күреп таң кала идем. Кызганыч, безнең бабаларыбыз шанлы дәүләтләр корсалар да, алардан сакланып калган тарихи әйберләр бик аз. Элегрәк туплаган акчаларым да, нигездә, көнчыгыш илләренеке, империя, ягъни патша заманыннан калган иде. Әле күптән түгел генә Буа музеена көмеш дирһәмнәр калдырдым. Балаларыбыз тарихны белеп үсәргә тиеш дип саныйм.

***– Татар мирасын коллекционерлык эше белән саклап буламы?***

– Иң күп коллекционерлар Мәскәүдә яши. Алар табылган барлык татар материалларын да Мәскәүгә озаталар. Кызганыч, үзебезнең музейларга, галимнәребезгә бик азы гына эләгә. Мондый хәл бездә генә түгел. Сәгуд Гарәбстанында еш булам, андагы музейларга баргалыйм мин. Гарәпләрдә дә үз дәүләтләреннән калган тарихи ядкярләр күп түгел. Госманлы империясе аларны яулап алгач, затлы материаллар Истанбул һәм Әнкара музейларына күчкән. Шулай итеп бер дәүләтнең фәнни чыганаклары башкалар кулына китеп беткән.

Үзебезнең татар, ханлык чоры коллекциясен туплау белән нибары өч ел элек кенә шөгыльләнә башладым. Әле X гасырда ук бу җирләрдә габбаси хәлифәләре акчасы булган икән! Рус патшасы заманыннан калган акчаларны татар ханлыклары тәңкәләренә алмаштырып алдым. Үз дәүләтеңнең тарихына бәйле тәңкәләр күпкә кадерлерәк бит! Бу эштә миңа Тәтеш егетләре ярдәм итте. Алар, махсус эзләнүләр оештырып, бай хәзинәгә юлыккан икән. Әтрәч кырыннан да табылган акчаларым бар. Коллекция туплый башлавымны белгәч, башка егетләр дә болгар-татар акчаларын бүләк итте.

> **«Кызганыч, безнең бабаларыбыз шанлы дәүләтләр корсалар да, алардан сакланып калган тарихи әйберләр бик аз. Элегрәк туплаган акчаларым да, нигездә, көнчыгыш илләренеке...**

***– Күргәзмәдә Тимер Хуҗа тәңкәсе дә бар...***

– Коллекциямдә иң кызыклысы Тимер Хуҗа тәңкәсе дип әйтер идем. Бу ханның яшәгән еллары Алтын Урданың бөек чуалышы чорына туры килә. Ул 1361 елда дәүләт белән нибары биш атна гына идарә итеп кала. Үзен якларлык хәрби көчләр туплый алмау сәбәпле, Мамайга каршы сугыша алмый һәм Сарайдан Идел буена качып китә, соңрак шунда үтерелә. Шулай да Тимер Хуҗа Сарай әл-Җәдид шәһәрендә үз исеме белән тәңкәләр сугарга өлгерә.

Дөрес, коллекциям бай түгел. Бу эш белән махсус шөгыльләнгәнем дә юк, мәгънәле кызыксыну гына дип әйтергә мөмкин. Тәрҗемәче булып эшлим, гид-инструктор буларак, ватандашларымны изге сәфәргә – хаҗга алып барам. Ә башка вакытта биек йортларның түбәсен ябу белән шөгыльләнәм. Мине төзелеш альпинисты дияргә дә була.

*Нумизмат-коллекционерлар белән*
***Ленар Гобәйдуллин** әңгәмә корды.* ■

# «Әтрәч укулары»ннан фоторепортаж

*«Әтрәч укулары»ннан тулы фоторепортаж белән*
***beznenmiras.ru** сайтыннан танышырга мөмкин*

Безнең мирас №12 декабрь 2020

# Әзгәри суккан Әтрәч

**Мөнир Вәлиев**

*Ир язмышы ил язмышы икән,*
*Тарихны да санлау кирәктер,*
*Башкаларга, бәлки, гыйбрәт булыр –*
*Туар буыннарга өйрәтер.*
***Әхмәт Рәшит***

## Тау ягы – Идел алды

**Мөнир Вәлиев «Әтрәч укулары»нда катнашучыларны тарихи зират белән таныштыра. 2020 ел, 3 октябрь**

Республикабызның көньяк-көнбатыш районнары – Тау ягы борынгы язма чыганакларда «Җәбәлстан» дип аталган географик җирлеккә урнашкан. Җәбәл – тау, стан (ыстан) – тору урыны дигән сүз. Бу төбәкне «Дагстан», ягъни даг/тау иле дип тә йөрткәннәр. География фәнендә туган ягыбыз «Идел алды» дип тә атала. Әлеге киңлекләрне самолеттан очканда яки Иделдә «Метеор»да йөзеп барганда күзәтсәң, бу атаманың хаклыгына тулысынча инанасың. Безнең төбәкне «кара як» дип тә атап йөрткәннәр. «Кара»лыгы халыкның мәгариф үзәгеннән читләшеп, сәүдә, һөнәр, игенчелек белән генә шөгыльләнүенә бәйле түгелме икән?! Ә бәлки, 1552 елны дәүләтчелегебезне югалткач, шундый хәлгә төшкәнбездер. Мәгариф системасында совет чорында да проблемалар җитәрлек булды. Заманында Апас районында ике генә урта мәктәп бар иде: Иске Йомралы һәм Апас урта мәктәпләре. Анда уку өчен безнең буынга бик күп михнәтләр чигәргә туры килде. Ярый әле, документлар биреп, авылдан

**«Әтрәч укулары»ннан бер мизгел. Уртада – мәкаләнең авторы, төбәкне өйрәнүче, «Шонгат» ТРОФ директоры Мөнир Вәлиев**

укырга җибәрсәләр! Белемгә омтылган яшьләрнең күбесе бу бәхеткә ирешә алмый иде. 1964 елда Зур һәм Кече Әтрәч, Аллабирде авыллары, мәгънәсез реформалар нигезендә, Апас районыннан алынып, Тәтеш районы составына кертелде. Ә Тәтеш районы биләмәсеннән кисеп алынган Идел буе авыллары исәбенә Кама Тамагы районы оештырылды. Тиешле шартлары булмаган бу ике мәктәп, болай да укучылар күплектән, бик мөшкел хәлгә калды. Алай да без конкурс нигезендә уку бәхетенә ирешә алдык...

Тау ягы авылларының тарихы тулысынча өйрәнелеп бетмәгән, өйрәнелгән кадәрлесе дә халыкка килеп җитмәгән, дип әйтү урынлы булыр. Имәнкискә культурасы, Бөек Болгар, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда чорларында бабаларыбыз ошбу җирдә дәүләт корган, җир-суларны биләгән, мал-мөлкәткә хуҗа булган. Дөрес, Имәнкискә чоры турындагы мәгълүматларны Татарстан тарихы китапларыннан табарга мөмкин, ә менә борынгы болгар чорындагы Әтрәч турындагы белемнәребез бик сай.

## Әтрәчкә кайдан күченгәннәр?

VI-VII гасырларда Азов буе болгарлары, башка күчмә кабиләләр белән берлектә, Бөек Болгар берлеге (союзы) төзи, әмма, төрле сәбәпләр аркасында, дәүләт таркала. Кодрак хан урта Идел буена күченеп, Болгар дәүләтенә нигез сала. Галимнәр, әлеге күчеш процессы Иделнең уң як ярлары буенча булган, диләр. Болгарлар ул вакытларда Сембер чигеннән алып хәзерге Кама Тамагына чаклы аралыкта Тархан, Ашлы (Ошель), Хулаш, Юматиха, Тәтеш, Зур Әтрәч (Мең өйле Шонгат) кебек уннан артык шәһәргә нигез салалар.

Үзәге Тархан булган җирлектә радиусы 40-60 чакрымлы зур шәһәр булганлыгы мәгълүм. Хәзер урман астында калган Мантово дип аталган җирдә 3 меңләп борынгы каберлек бүгенге көнгәчә өйрәнелмичә ята. Тархан – идарәче, эре җир биләүче дигән мәгънәне белдерә. Әгәр дә дәүләткә куркыныч янаса, бер

«

**Әтрәчкә күченүнең башка дулкыны да булган дип уйларга нигез бар. Төрле һөҗүмнәр нәтиҗәсендә Идел буе Болгар дәүләте калалары туздырылганнан соң, халык Идел һәм Чулман елгаларының уң як яр буендагы урман һәм чокыр араларына күчеп утырырга мәҗбүр булган.**

тәүлек эчендә унбиш-егерме мең чамасы сугышчы җыярга сәләтле булган алар. Тархан атамасы бу чорда аеруча еш кулланылган.

Тәтеш кальга-кала ролен үтәгән. Әлеге борынгы шәһәрнең X гасырда да эзләре бар. Тарих институты галимнәре, Тәтешнең яшен, бер дә икеләнмичә, 1000-1300 ел дип билгеләргә мөмкин, диләр. Мамайның да ставкасы вакытлыча Тәтештә урнашкан була.

Мең өйле Шонгат (Иске Шонгат, Олы Әтрәч, Зур Әтрәч, Олуг Әтрәч, Тенеш – болары легендар, серле шәһәрнең төрле чордагы исемнәре) шәһәрлеге һәм Кече Әтрәч-Мөртәбәкләр Пүчинкәсенең (иярчен авыл) тарихы да гаять бай. Тарихчы Гайнетдин Әхмәров, җирле халык сөйләгәннәргә нигезләнеп, «монда алты мең өйле Шонгаты», башка мәкаләсендә «ике мең өйле Шонгаты шәһәре» булганлыгы хакында яза. Ул Шонгаты шәһәренең халкы болгарлар белән кыз алышып, кыз бирешеп яшәгәнлеге, Шәһре Болгарга йөргән туры юлларын да күрсәтүләре турында да әйтә. Әтрәч авылы мөселманнары үзләрен шул Шонгаты шәһәреннән күчеп утырганнар дип сөйләгәнлекләрен язып калдыра.

Әтрәчкә күченүнең башка дулкыны да булган дип уйларга нигез бар. Төрле һөҗүмнәр нәтиҗәсендә Идел буе Болгар дәүләте калалары туздырылганнан соң, халык Идел һәм Чулман елгаларының уң як яр буендагы урман һәм чокыр араларына күчеп утырырга мәҗбүр булган. Тәтеш тирәсендәге татар авылларында, аеруча Болгаер, Әтрәч, Борнаш һәм Яңа Салада яшәүчеләр еш кына: *«Безнең бабаларыбыз Болгардан күчеп килгән»,* – дип әйткәннәр. Бу турыда тарихчы Г.Әхмәров та: *«Тәтеш, Зөя, Лаеш өязләренең бәгъзе авылларына «безнең бабаларыбыз күчеп килгәннәр» дип сөйләгәнне тәкърар ишеткәнебез бар»,* – дип яза. Ул, Хисаметдин Мөслими мәгълүматларына нигезләнеп, болгарларның төрле тарафларга таралуын искәртә, шулай ук: *«Тәтеш карты ыругы берлә Ик Идел ( хәзерге Идел) ярына төште – Тәтеш авылы булды»,* – дип тә өсти. Тау ягы татарларының үзенчәлекле диалекты, уртак гореф-гадәтләр һәм, әлбәттә, археологик табышлар моңа ныклы дәлил булып тора.

## Әтрәч – Болгар дәүләтенең акча сугу ыстаны

Әтрәчне Болгарның акча сугу ыстаны булган, дип тә әйтәләр. Бу җирләрдә, шул исәптән Болгаер һәм Борнаш авыллары биләмәләрендә нумизматик хәзинәләр әле дә табылып тора. ТР Милли музее фондында Әтрәч белән бәйле Болгар чоры акчалары саклана. Аларны А.З.Сингатуллина тикшерә. Нумизматлар А.И.Бугарчев һәм О.В.Степановлар җирле археолог М.Н.Минһаҗев коллекциясендәге 31 акчага тәфсилле анализ ясады. Бу акчаларны безнең якларда «әзгәри» дип атап йөртәләр.

## Кем соң ул Әтрәч?

Әтрәч исемен иң борынгы чыганак – «Идегәй» дастаныннан таптым. Сезгә шуннан бер өзек тәкъдим итәм:

*«...Бу җиһанның фетнәсе –*
*Аксак Тимер дошманны*
*Сарайга алып китердең,*
*Йорт-җиреңне бастырдың.*
*Әзгәри суккан Әтрәчне*
*Эргәсеннән җимереп...»*

Болгар ханнары арасында мондый исемлесе юк. Әмма эпиграфия галиме Һарун Йосыповың китабында Әтрәчнең кем икәнлегенә ачыклык кертә торган ике факт бар. Шуның беренчесенә мөрәҗәгать итик. *«Мең суарлар ыруы... Гали (Али) хаҗи улы, Әтрәч хаҗи, (аның) улы Әбү Бәкерхаҗи, (аның) улы Алып хаҗи зиярәте»,* – дип язылган анда. Аңлашыла ки, Әтрәч хаҗи – хаҗда булган мәртәбәле кеше. Алар төбәктәге ыкта* җирләренә дә хуҗа булганнар.

Борынгы зиратта табылган кабер ташындагы язма XIV гасырда тагын бер соционимның киң таралган булуын күрсәтә: *«Храброго Арс-Сираджи-йори сын Йагкуб-йори, (его) сын Айуб-йори, (его) сын Хасан-йори, (его) сын Гали-йори, (его) сын Атряч-йори, (его) сын Мухаммадамир Махмуд».* Йори (йувари) – сугыш кешесе, сугышчы дигәнне аңлата. Йори (йувари) дигән сүзләргә археолог Альфред Халиков нәселдән-нәселгә күчеп килгән хәрбиләрне ялланып хезмәт итүче хәрбиләрдән аеру өчен кулланылган термин, дип карый. Бу катлауның (сословиенең) күпчелеген Алып батырлар белән бәйле булган батыр сугышчылар тәшкил иткән икән. Аларга да ыкта җирләре гомерлеккә бирелә торган булган. Тыныч тормышта йувари тәхәллүс буларак та кулланылган, чөнки абыйлы-энеле Әтрәч бабайлар «салкынлык иле» – Югра халкы белән сәүдә иткәннәр, төньяктан металл рудалары да ташыганнар. Инде бу фактларны анализласаң, Әтрәч бабай нәселенең ике сословиегә дә ия булганлыгын чамалап була. Алар бер үк вакытта дин-иман әһелләре дә, сәүдәгәрләр дә һәм, әлбәттә, батыр сугышчылар да булганнар.

## Изгеләр зираты

Изгеләр зиратының саны төрле чыганакларда өч-биш дип күрсәтелә, әмма хәзерге көндә фәкать икесенең генә урыны төгәл билгеле. Зур Әтрәч авылы кырында Урта Идел буенда сакланып калган иң зур Изгеләр зираты искиткеч зур әһәмияткә ия булган тарих ядкяре булып тора. Аның гомуми мәйданы 9 гектар тәшкил итә. Хәзерге вакытта бу комплексга 11 таш сакланып калган. Галим Марсель Әхмәтҗанов сигез ташның текстын тәрҗемә итеп, авылдашларыбызны алар белән таныштырды.

Гайнетдин Әхмәров: *«Тәтеш өязендә Олуг Әтрәч исемле карьянең кырында Болгар заманыннан калган бер иске зират бар, егерме-утыз кадәр язулы ташлары да бар, бәгъзеләре хатты куфи белән, бәгъзеләре хатты сөлси белән язылган. Шул зиратка якынрак урыннарда җирдән төрле болгар нәрсәләре табыла, хосусан көмеш акчалар. Табылган акчаларның күплегеннән һәм алты-җиде йөз еллардан бирле таш-*

---
* Ыкта – батыр сугышчыларга һәм дин әһелләренә гомерлеккә бирелә торган җир.

*ланып ята торган иске ziratta шулкадәр язулы ташларның калуы – бу урында бер зур шәһәр булганлыкка галәмәттер. Без шул зиратны карарга барганда, бер карт кешедән сораштык: «Зиярәт кылырга килүчеләр бармы, ниндәен халык һәм кайдан күбрәк киләләр?» – дип. «Килгәлиләр, кичә дә, бер пар ат белән килеп, Коръән укып киттеләр», – диде»,* – дип яза.

Әлеге зиратның ташлары төрле җирләргә таралган. Гайнетдин Әхмәров шундый ике ташны тасвирлый. *«Әтрәч карьясенә якын Җанбакты дигән рус авылының кәнисә чиркәү янында ике язулы таш бар. (Шул Әтрәч зиратыннан алган булмак кирәк.) Берсе хатты куфи илә язылган, кәнисәнең баскычында ята. Ул кеше аяк астында булганлыктан, язуы бик ачык түгел, бу сүзләр генә язып алынды:*

*«Рәхмәте Аллаһы галәйһи рәхмәтән*
*Васыйгатән җийат җүр туати җийат».*

*Икенчесе гүзәл рәвештә хатты сөлес илә язылган, мәгәр кәнисәнең уң ягындагы ишек бусагасына куелганлыктан, ике башы да дивар астына кереп калган, шул сәбәпле, бу сүзләрне генә уку мөмкин булды: «Алдында 84 яшендә гадәде тарих 642дә (Румия илә{миладе} 1244 ел була) «Әл хөкме лилләһи әл-галиел-кәбир Мир Ибраһим Инал улы Шәһид Хаҗ бәлүви... рәхмәте Аллаһы Галәйһи рәхмәтән васыйгатән Вафат йа тауый тарих Җийат җур җийарминши Җал мөхәррәм бер йәхи икенҗе күән әти». Тәрҗемәсе: «Бөек, олуг Аллаһының хөкеме Мир Ибраһим Инал улы Шәһид хаҗи билгесе... Аңа Аллаһның киң рәхмәте ирешсен. Вафат тарих җиде йөз егерменче ел, мөхәррәмнең беренче яки икенче көне иде».*

Г.Әхмәров хәзерге Апас районындагы Каратун дигән рус авылындагы бер язулы ташны да барып каравы турында, бу ташның Әтрәч зиратыннан алынган булырга тиешлеге хакында әйтә. Әтрәч ташлары Апас-Тәтеш юлын төзегәндә кулланылган дигән хәбәр дә бар.

Г.Әхмәров төрки-татар зиратлары проблемасын күтәргән бер мәкаләсендә тарихи ядкярләрнең сакланмавына ачынып, болай дип яза: *«Һәр милләт – нәсари (христиан) булсын, яһүд булсын, хәтта мәҗүс таифәләре дә, ата-бабаларының зиратларын мөкаддәс санап, мөмкин кадәр тәрбияле тоталар, мондаен эшләр дин исламда хосусән мактаулы булса да, вилаятебезнең мөселманнары иске зиратларын бик тәрбиясез, кызганыч хәлдә тоталар. Мәсәлән, Тәтеш өязенең Әтрәч карьясендә Болгар заманыннан калган бер иске зират бар, ихатасы юк, бәгъзеләре авып ята, бәгъзеләре сынгалап, берничә еллар мөкаддәм (элекке) араларын сукалап, иген дә чәчкәннәр иде, шул сәбәпле, бер баруыбызда бәгъзе ташларны күрер өчен иген арасыннан эзләп таптык, икенче мәртәбә баруыбызда такыр басу иде. Шул зират өстендә Әтрәч карьясенең сыерсарык көтүе йөргәнен күрдек, бәгъзе хайваннар ташлар арасына ятканнар, бәгъзеләре ташка ышкылып торалар. Хайван йөрү сәбәпле, зират өстендә тирес тә күренде. Бу ике авылның халкы (Олы һәм Кече Әтрәч) мондаен нәрсәләрне мөкаддәс күреп, шул зиратны ихата кыйлып куйсалар, яки тирән чокыр гына казып әйләндерсәләр дә, бу ташлар, бәлки, тагы алты йөз ел торырлар иде».*

Олуг тарихчының әлеге теләген йөз елдан соң гамәлгә ашыручы игелекле шәхес танылган драматург, ТР Дәүләт Советы депутаты, мәрхүм Туфан ага Миңнуллин булды. Дөрес, дин кайта башлагач, мөмкинлектән чыгып, авылдашларыбыз, авыл советы бу зиратны карап торды. 1980 нче елларда, Казанда яшәүче Г.З.Садыйровның матди ярдәме белән, зират мәйданы агач арата белән әйләндереп алынды, әмма еллар узгач, ул череде. 2009 елда Т.Миңнуллин үз акчасына – ике пьесасына бирелгән гонорар хисабына каберлекне металл киртә белән уратты. Кылган гамәленең әҗерсавабына ирешсен, тар кабере нурлы булсын игелекле Туфан аганың!

## Әтрәч белән идарә итүче Алиш (Галишаһ) бәк

XVII гасырдан бу җирләрдә Касыйм ханлыгыннан күчеп килгән Галишаһ морза идарә иткән. Һәммәбезгә дә таныш балалар язучысы, фронтовик шагыйрь Абдулла Алиш (1908-1944) – шул нәселдән. Азат Сөнкишев исә Галишаһ шәҗәрәсендә 66 саны белән теркәлгән. Ул – күп китаплар авторы, танылган журналист. «Галишаһ морза нәселе» трилогиясенең авторы Сәлам Алишев та – шушы нәселнең күренекле бер вәкиле. Аның китабыннан алып, Галишаһның улы Хәкимҗан морзаның Ф.И.Шереметев белән әңгәмәсеннән бер өзек китерик: *«Безнең нәсел Болгар әмирлегеннән. Зур Әтрәч авылы элек болгар әмирлегенең үзәге булган. Анда Исән (Хәсән?) бабай акчалар суктырган, каберлегендә бабаларыбызның болгар ташъязмалары сакланган. Минем бабам Казан ханы Сафагәрәйгә каршы чыккан. Аның ачуыннан качып, Мәскәүгә, бөек кнәзь Иван Васильевичка хезмәткә килгән. Яхшы хезмәте өчен патша аңа Кострома шәһәрендә бер йорт һәм шул тирәдән җир бирдерткән. Бабай үлгәч, минем әти ул йортка һәм җиргә мөһерле язу – грамота алуга ирешкән. Менә ул грамота. Хәзер аны минем исемгә яңартасы иде! Мин дә бит начар хезмәт итмим үзегезгә...»*

Шулай итеп, кенәз Ф.И.Шереметев Галишаһка авыру әтисе белән тарихи Ватанына – Олы Әтрәчкә кайтырга рөхсәт бирә. Моның өстенә, әтисенә, хезмәтләре өчен, 500 дисәтинә җир дә бүләк ителә. Галишаһ морзаның Олы Әтрәчтәге утарында Тау ягы авылларында көн күргән йомышлы игенчеләр эшләгән.

* * *

Кеше, үзе туып үскән җирнең тарихын белмичә һәм өйрәнмичә, алга карап яши алмый. Бу – хакыйкать. Һәр бәләкәй тарих – зур тарихның мөһим бер кисәге ул. Татар халкын, аның телен һәм мәдәниятен саклап калу, алга таба үстерү юнәлешендә ата-бабаларыбыздан калган бай тарихи-мәдәни мирасны үзләштерү, өйрәнү, эшгамәлләребездә файдалана белү зарур. Тарих һәм заман бездән шуны таләп итә. ■

**«Әтрәч укулары»нда катнашучылар Зур Әтрәч авылының тарихи зиратында. 2020 ел, 3 октябрь**

# Әтрәч тәңкәләре

Алексей Бугарчев, Олег Степанов*



XIV гасырдагы бакыр тәңкәләрнең төрләре

Татарстан Республикасы – нумизматик табышларга гаять бай төбәк. X-XV гасырларга нисбәтле урта гасыр тәңкәләре тулы бер хәзинә яки аерым табылдыклар рәвешендә даими очрап тора. Боларның иң борынгылары – X гасырда Урта Азиядән китерелгән куфи дирһәмнәре. Көмештән эшләнгән мондый тәңкәләрнең авырлыгы уртача 3-5 грамм тәшкил итә. Урта Идел буенда, читтән китерелгән акчалардан тыш, дәүләтнең үз тәңкәләре дә сугылган. Шуның нигезендә без Идел буе Болгар дәүләтендәге әмирләрнең исемнәрен, алар идарә иткән елларны төгәл әйтә алабыз.

Республикабызның аерым районнарында Монгол империясе һәм Алтын Урда чоры (XIII-XV гасырлар) тәңкәләре дә еш табыла. Бу акчаның күләменә карап, без Болгар шәһәре һәм аның тирә-ягы, Җукәтау, Биләр, Иске Казан кебек археологик объектларда сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләр үсеше турында сөйли алабыз. Тәтеш районындагы Әтрәч авылы җирлеге – элеккеге Шонгат шәһәрлеге дә шундый төбәкләрнең берсе.

## Аерым табышларның хронологиясе

2015 елда «Идел буе археологиясе» журналында профессор К.А.Руденко белән Олы Әтрәч авылы тирәсендәге археологик һәм нумизматик материалны анализлауга багышланган зур мәкалә бастырып чыгардык. Бу вакытта Әтрәчтә хәзинә буларак түгел, ә аерым табылган һәм безгә билгеле булган (кызганыч, күбесе «кара эзләүчеләр» кулында кала һәм аларга фәнни анализ ясалмый) нумизматик чыганакларның саны 73 тәңкәдән гыйбарәт иде. Алар Монгол империясе һәм Алтын Урда дәүләте чорына нисбәтле, ягъни XIII-XV гасырларда сугылган. Соңгы биш елда безгә 6 көмеш һәм 95 бакыр тәңкә турында да билгеле булды. Шулай

* Алексей Бугарчев һәм Олег Степанов – ТР ФАнең А.Х.Халиков исемендәге Археология институты галимнәре.

**«Әтрәч укулары»нда күргәзмәгә куелган тәңкәләр.** ***Ильяс Мөлеков коллекциясе***

итеп, Олы Әтрәч тирәсеннән аерым табылган нумизматик ядкярләрнең гомуми саны 17 дирһәм һәм 157 бакыр тәңкә тәшкил итә.

Табышларны хронологик чорларга бүлеп анализлау кызык. Идел буе Болгар дәүләте Җучи Олысы составына кергән вакыттан, ягъни 1230 нчы еллар ахырыннан алып 1267 елга кадәрге аралыкка нибары биш бакыр тәңкә туры килә. Аларның дүртесе – Багдад хәлифе Насреддин, берсе Монгол империясе каһаны Мүнкә исеменнән сугылган.

12 көмеш һәм 24 бакыр тәңкә Токта һәм Үзбәк ханнар идарә иткән чорга – XIV гасырның беренче чирегенә нисбәтле.

1330 елгы реформадан соң һәм 1360 нчы еллар уртасына кадәрге чорда Әтрәч төбәгендә сәүдә әйләнеше гөрләп үскән дип уйларга нигез бар. Бу хронологик аралыкка нисбәтле 111 бакыр тәңкә һәм 2 дирһәм табылды.

Алга таба сан түбәнгә тәгәри: 1370-1390 нчы елларга караган 17 бакыр тәңкә һәм 3 дирһәм бар.

## «Шонгат» атамасы сугылган тәңкәләр

1360-1370 нче елларда Шонгат шәһәрлегендә тәңкә сугу остаханәсе булган. XIV гасырның икенче яртысында, Болгар илендә бакыр акчалар җитмәү сәбәпле, элек чыгарылган тәңкәләр өстенә яңа тамга яки идарәче исемен суга башлыйлар. Мондый күренешне без Болгар һәм Иске Казан шәһәрләрендә дә күзәтәбез. Болгар шәһәрлегендәге әлеге тәңкәләрнең хронологиясе күренекле нумизмат һәм эпиграфист Җәмил Мөхәммәтшин тарафыннан эшләнгән инде. Әтрәч төбәгендә мәсьәлә башка юл белән хәл ителә. Әйткәнебезчә, биредә акча сугу остаханәсен оештырып җибәрәләр.

Шонгат шәһәрлегендә табылган тәңкәләрдә төрле тамгаларны, орнамент-ларны, ике башлы бөркет, арыслан һәм барс рәсемнәрен күрәбез, хан яки шә-

**Гайнетдин Әхмәров (1864-1911), тарихчы:**

«Бу зиратның янында күп болгар нәрсәләре дә табыла, хосусан «әзгәри» дип атала торган болгар тәңкәләре, элегрәк, Болгар заманында, акча урынына йөртелгән көмеш кисәкләре күп табылган».

«Иске зиратлар хакында», 1906 ел

«Табылган акчаларының күплегеннән һәм алты-җиде йөз еллардан бирле ташланып ята торган иске зиратта язулы ташларның калуы – бу урында бер зур шәһәр булганлыкка галәмәттер, шул тирәдәге мөселманнарның сөйләвенчә, монда алты мең өйле «Шонгаты» шәһәре булган».

«Болгар тарихы»ннан, 1909 ел

һәр исемнәрен укыйбыз. Сарай, Сарай әл-Җәдид, Әзәк, Кырым, Гөлестан, Болгар, Мокшы атамалары арасында «Шонгат» дип язылган тәңкәләр дә бар. Болары инде Әтрәчнең үзендә, ягъни борынгы Шонгат шәһәрлегендә сугылган тәңкәләр. Аларга беренче мәртәбә фәнни анализ ясаган С.В.Гумаюнов һәм И.В.Евстратовларга 9 данә генә мондый тәңкә билгеле була. 2017 елда шундый ике бакыр тәңкә Иске Казан шәһәрлегендә табылды. Шул ук елның көзендә Зур Әтрәч авылы янында да «Шонгат» исеме язылган ике бакыр тәңкә килеп чыкты. Шулай итеп хәзерге көндә әлеге серле шәһәр атамасы сугылган нумизматика ядкярләренең саны 13кә җитте. Тәңкәләрнең уртача авырлыгы 1,88 грамм тәшкил итә. Алар 1361-1362 нче елларда Түбән Идел буенда, Сарай каласында сугылган акчаларга тәңгәл.

Бу тәңкәләр җирле базарның бакыр акчага ихтыяҗына янә бер дәлил булып тора. Шуңа нигезләнеп, төбәктә товар-акча әйләнеше кайсы вакытта актив булганлыгы турында сөйләргә мөмкин.

## Әтрәч хәзинәләре

Җучи тәңкәләренең аерым табылдыклары гына тулы картинаны күз алдына китерергә мөмкинлек бирми. Әтрәч һәм аның тирә-ягындагы кырлардан табылган хәзинәләрне дә махсус өйрәнү сорала.

XIII һәм XIV гасырның уртасына кадәрге Әтрәч хәзинәләре турында берни дә мәгълүм түгел.

1856 һәм 1954 нче елларда Кече Әтрәчтә XIV гасыр азагына нисбәтле ике хәзинә ачылган. Шулай ук 1986 елда Каратун станциясеннән 2,5 км төньяк-көнчыгышта табылган атаклы Каратун хәзинәсе дә фәнни кыйммәткә ия.

XV гасыр башында Олы Әтрәчтә ике хәзинә яшерелгән булган. Аларның икесе дә соңгы елларда гына табылды. Шулай ук 1963 һәм 1970 нче елларда Шонгаттан ике хәзинә һәм XXI гасыр башында Тәтеш шәһәре тирәсеннән бер хәзинә килеп чыккан. Алар да – XV гасыр башында сугылган тәңкәләр.

XIV гасыр ахырындагы хәзинәләрнең иң мөһим үзенчәлеге – бу елларда Алтын Урданың үз тәңкәләренең күплеге. 1856 елда ачылган Кече Әтрәч хәзинәсендә – 10 меңнән артык тәңкә, 1954 елда табылган Кече Әтрәч хәзинәсендә 20 мең чамасы

**«Әтрәч укулары»нда күргәзмәгә куелган тәңкәләр.** *Марат Минһаҗев коллекциясе*

дирһәм һәм Һиндстаннан китерелгән берничә алтын динар бар. Каратун хәзинәсе 24103 көмеш тәңкәдән гыйбарәт. Бу – искиткеч зур байлык! Чагыштыру өчен XV гасыр хәзинәләренең саннарын да күрсәтербез. Олы Әтрәч комплексларында табылган хәзинәнең берсендә – 177, икенчесендә – 31 данә, Шонгат хәзинәсенең берсендә – 41, икенчесендә 84 тәңкә сакланып калган. Боларны, XIV гасыр ахырындагы хәзинәләрдән аермалы буларак, «хәзинә-янчыклар» дип кенә атарга мөмкин. Кечкенә акчалар 1430 нчы елларда Мөхәммәд (бәлки, Олуг Мөхәммәдтер) исеменнән сугылган. Шуннан соңгы Әтрәч тәңкәләр безгә мәгълүм түгел.

***

Кызганыч, төбәктә масштаблы археологик казу эшләре башкарылмаган. Алда әйтеп үтелгән аерым нумизматик табышлар туган якны өйрәнүчеләрнең энтузиазмы, беренче чиратта, **Марат Минһаҗев** һәм **Ильяс Мөлеков**ларның тырыш хезмәте, тарихка битараф булмаулары сәбәпле генә сакланып калды. Егетләргә бу гамәлләре өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез. Аларның хезмәте һәм Әтрәч нумизматик мирасы Татарстанның Тәтеш районы тарихын язганда нигез булып хезмәт итәргә тиеш. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2020

# Әтрәч керәшеннәренең ислам өчен көрәше

**Эльмира Сәлахова**

**Тәтеш районындагы Кече Әтрәч авылының мәчете. 2020 елгы фото**

Татар тарихының иң авыр чоры – чукындыру елларында хәзерге Тәтеш районындагы Әтрәч мөселманнарының тарихи һәйкәлләре, кабер ташлары, мәчетләре кадерсезләнә. Татар авылларына яки аның янәшәсенә илнең башка төбәкләреннән урыс крестьяннары күчереп утыртыла. Тарихчы Гайнетдин Әхмәров: «Һәр авыл исеме алдында «татар» яисә «урыс» сүзе язылу бу хакта сөйли», – дип белдерә. Мисал өчен, аның туган авылы Татар Наратлысыннан ерак түгел Рус Наратлысы авылы бар. Гомумән, Тау ягында мондый авыллар бик күп. Әтрәч авыллары янында да Зур һәм Кече Монастырск (Зур Каратун, Кече Каратун), Ямбахты, Лаптевка, Сюкеево, Христофоровка, Марьевка, Никифирово, Васильево кебек урыс авыллары барлыкка килә. Татар крестьяны болай да үзенә җитмәгән җирне башкалар белән бүлешергә мәҗбүр ителә. Җир гасырлар дәвамында безнең милләт өчен тамак туйдырырга мөмкинлек бирә торган бердәнбер чыганак була дип әйтергә мөмкин, чөнки һөнәрчелек бары тик өстәмә табыш кына бирә алган. Шуңа да татар кешесе җирен иманы кебек үк кадерләгән, саклаган, аның өчен көрәшкән. Шушы төбәктәге морза нәселенең дәвамчысы булган мәрхүм тарихчы

Сәлам Алишев үзенең «Галишаһ хан» дигән китабында әлеге тарихи хәлләрне җанлы итеп, халык күңеле аша үткәреп, әдәби әсәр рәвешендә сурәтли. Анда бу як халкының иман өчен көрәше кеше язмышлары аша бирелә.

## Имана өчен иман

Тау ягы авыллары тарихында чукындыру сәясәтенең барлык этапларын да күзәтергә мөмкин. Керәшенлеккә тулысынча күчкән авыллар да бар, ә күп өлеше чукындыруның соңгы елларына гына эләгә. Без аларны яңа керәшеннәр дип атыйбыз. Әлбәттә, болар үз теләкләре белән түгел, ә түрәләрнең ихтыяры белән «чукынырга» мәҗбүр булганнар. Дөрес, араларында үзләре теләп тә керәшенлеккә күчүчеләр бар, чөнки иманны документта гына булса да алыштыру аларга, мөселман крестьяннарыннан аермалы буларак, шактый зур өстенлекләр биргән. Беренчедән, җир бүлгәндә, чукынган булсаң, уңдырышлы кишәрлек эләккән. Озын-озак солдат хезмәте өчен шобага салынганда да керәшеннәр өчен тиешле бу авырлыкны мөселман егете күтәргән. Шул рәвешле иман ныклыгы зур түземлек, ихтыяр көче таләп иткән. Күпләр бу авырлыкларны горур күтәрә алса, кайберләре сынган. Безнең буын кешеләре элгәреләрнең карар-гамәлләрен яхшы яки яман дип бәяли алмый. Бар да Аллаһы Тәгалә хөкемендә. Күп еллар үтсә дә, чукынган нәселләрне авылдашлары яхшы хәтерләгән, имана өчен «иман саткан»нарга тискәре мөнәсәбәт буыннан-буынга күчеп килгән, элегрәк алар белән никахлашмаска, алыш-биреш итмәскә тырышканнар.

## Уйлап табылган исемнәр

Документларга чукындырылган татарларның мөселман исемнәре урынына поплар тарафыннан уйлап табылган урыс исемнәре язылган. Авыл кешеләре еш кына үзләренә нинди исем бирелгәнен дә белмәгән, бер-берсен мөселман исемнәре белән атауны дәвам иткән. Рәсми керәшен саналса да, алар өстеннән тикшерү, басым нык булмаган, шунлыктан, күбесе ата-бабалары тоткан ислам гадәтләренә тугры калып, кача-поса булса да намаз укыган, ураза тоткан, хәтта балаларын да мәдрәсәгә йөрткән. Яңа чукындырылган керәшеннәр хакимият өчен куркыныч тудыра торган тотрыксыз катлам тәшкил иткән. Алар җай чыккан саен баш күтәргән, исламга кайтуны сорап гаризалар язган, христиан дине таләп иткән кагыйдәләрне бөтенләй диярлек үтәмәгән. Әлбәттә, бу халыкны күзәтү астында тоту өчен попларның да, түрәләрнең дә көче җитмәгән.

## Әтрәч керәшеннәренең изге ялганы

XIX гасыр-20 нче йөз башында Әтрәчтә керәшеннәр авыл халкының якынча 15 процентын тәшкил итә. Мөселман татарларыннан аермалы буларак, аларга мәчеткә йөрү катгый тыелган. Христиан дине таләпләрен үтәтү өчен православие руханилары Әтрәчкә килеп йөрмәгән диярлек. Указлы мулла да аларга хезмәт күрсәтергә курыкканлыктан, керәшеннәр үз араларыннан иң укымышлы, ислам гадәтләрен белә торган кешене мулла итеп сайлап куйганнар. Кызганыч хәлләр

дә булгалаган. Мәсәлән, 1876 елны мулла Мөхәммәдсадыйк хәзрәткә гаепләү эше ачыла. Аның белән сүзгә килгән берәү, мулла Корбан бәйрәмендә керәшеннәргә мәчеткә керергә рөхсәт итте, керәшеннәрдән дә сәдака акчасы алды, дип шикаять яза. Тикшерү вакытында мулла гаепсез дип табыла. Корбан гаете башланганчы, старостага керәшеннәрне мәчеттән чыгарырга кушкан булган икән ул.

Документта керәшен дип язылган төркем, әйткәнебезчә, ислам йолаларын өйдә генә үтәгән. Әмма аларның җәмәгать намазын калдырырга теләмәүләре – мөселманнарның иң зур бәйрәмнәреннән берсе булган Корбан гаетендә катнашырга омтылышы табигый күренеш. Имам, әлбәттә, керәшеннәргә мәчеткә керергә рөхсәт итә алмый, чөнки юл ачса, һичшиксез, аның Указын алачаклар, моның өстенә, җирле түрәләргә дә штраф салыначак. Ә менә урамда гыйбадәт кылган өчен имам кеше җавап тотмый. Шулай итеп, керәшеннәр гает намазын мәчет янында укый, ә мулла, әлбәттә, тышкы яктагы халыкны күрми, бу турыда белсә дә, берни дәшми.

Кызганыч, әлеге гамәлне күзәтеп, полициягә җиткерүче, әләкләүче дә була. Мулла өстеннән шикаять язылганнан соң, керәшен татарлары мулланы «сатмыйлар», үзләрен мәчеткә килмәгән, ә шәхси эшләре белән Аллаһ йорты яныннан узып барган кебек кенә күрсәтәләр. Берсе: «Мин авыру абыемның хәлен белеп кайтып бара идем», – ди. Ә икенчесе: «Мин зиратка бара идем», – дигән изге ялган белән котыла.

### «Керәшен татарлары мәчетенең төзелеп бетүенә юл куймаска!»

1866 елдан соң керәшен саналган мөселманнар, үзләренең ике арада эленеп калган төркем булуларыннан зарланып, исламга рәсми кайтуны сорап гариза язалар. *«Без барыбер ислам гадәтләрен үтибез, беркайчан да христиан булмадык, безнең болай язылуыбыз документлар белән эш иткәндә буталчыклыкларга китерә»,* – дип зарлана алар. Шулай итеп, чукындырылган татарлар күпләп үз диннәренә кайта башлыйлар. Керәшен саналып яңадан үз диненә кайтучыларны «мәкруһлар» дип атап йөрткәннәр.

**«Документта керәшен дип язылган төркем, әйткәнебезчә, ислам йолаларын өйдә генә үтәгән. Әмма аларның җәмәгать намазын калдырырга теләмәүләре – мөселманнарның иң зур бәйрәмнәреннән берсе булган Корбан гаетендә катнашырга омтылышы табигый күренеш.**

Әтрәч керәшеннәре үз балаларын мөселман метрика дәфтәрләренә терки алмаган, шул ук вакытта аларның зур күпчелеге чиркәү документларына да язылмаган, димәк, чукындырылмаган. Теркәлгән очракта да, бу кешеләр урыс исеме белән булганлыктан, хәзерге вакытта кемнең әби-бабасы икәнлеген ачыклавы бик кыен. Кайбер авылларда урыс исемнәре татар исемнәре белән бергә «Посемейный список» дигән документларда гына язылып калган. Гайнетдин Әхмәров әлеге крестьяннарның аяныч язмышын үзенең «Мәкруһлар хәленнән» дигән мәкаләсендә Чистай төбәгендәге бер авыл мисалында күрсәтә. Башка тө-

бәкләрдә дә әлеге мәкаләдә сөйләнгән хәлләр булган дип уйларга нигез бар. Керәшен саналган, аннан мәкруһ булган ата кеше үз баласын метрикага яздыра алмагач, анасы исемен күрсәтеп теркәтергә тырышканлыгы языла анда. Мисал өчен, Гайшә улы Гайшин фамилиясен ала.

Әтрәч авылының мәкруһлары, вазгыять берникадәр йомшарып, дингә кайтырга мөмкинлек ачылгач, 1881 елны хакимият рөхсәтеннән башка үзләренә аерым мәчет сала башлыйлар. Моны белеп алып, 43 кешегә икешәр сумлык штраф салына. 1882 елның 11 декабрендә Нигъмәтулла Галиев әлеге кешеләр исеменнән мәчетне төзеп бетерергә рөхсәт итүләрен сорый, һич булмаса, башка урынга күчерергә ризалык бирүләрен үтенә. Әмма Тәтеш полиция идарәсенә: *«Керәшен татарларының үз теләкләре белән мәчет төзүләренә юл куймаска, әлеге мәчетнең төзелеп бетүен булдырмаска. Суд эше кузгатырга»,* – дигән әмер бирелә.

## Мәчеткә – палас «ишек»тән

Иман өчен көрәшүнең мәкруһлар тормышындагы бер гыйбрәтле күренешен тарихчы Гайнетдин Әхмәров та язып калдырган. Мәчеттә намаз укырга ризалык булмагач, алар, гадәти ишектән узмыйча, арткы яктан яңасын ясап, аңа палас элеп куялар да, шуннан кереп йөри башлыйлар. Моны белеп алган түрәләр бу гамәлгә юл куйган мулланы эзәрлеклиләр. Кыйналган, авызы-борыны канга баткан дин әһелен халык алдына китереп бастыралар да авылдашларын христианлыкта калырга өндәргә мәҗбүр итәләр.

> **«Мәчеттә намаз укырга ризалык булмагач, алар, гадәти ишектән узмыйча, арткы яктан яңасын ясап, аңа палас элеп куялар да, шуннан кереп йөри башлыйлар. Моны белеп алган түрәләр бу гамәлгә юл куйган мулланы эзәрлеклиләр.**

Әтрәч керәшеннәре дә, зур авырлыклар аша үтеп, үз ата-бабаларының динен кайтаралар, ә узган михнәтле елларын онытлар, башкалар да аларның җан әрнеткән яраларына тимәскә тырыша. Хәзерге күп кенә авылларда яшәүчеләр үз бабаларының кайчандыр мәкруһ булып, дин-ислам өчен көрәшүе хакында берни белми. ТР Милли архивында мәкруһ булган кешеләрнең урыс исеме белән татар исеме янәшә язылган документлары сакланып калмаган булса, аларның нәсел шәҗәрәләрен ачыклау бөтенләй мөмкин булмас иде. 1895 елгы шундый документта Олы Әтрәчтә – 95 хуҗалык, аның күршесендәге Аллабирдедә 26 хуҗалык теркәлгән. ■

# Без дә ярлы түгел...

Айгөл Әхмәтгалиева

Бу язмага тотынуыма гади генә бер очрак сәбәпче булды.

Җәй көне кызым белән бакчада түтәл арасында мәш килгән көнебез иде. Аныкы яшьләрчә: телефон кесәгә кыстырылган, колакта – колакчын. Инглиз һәм алман телләрен тагын да камилләштерү өчен, чит ил әдәбиятын аудиокитаплар аша оригиналда «укуы». Вакыт-вакыт тукталып, тыңлаганнарын минем белән дә бүлешә, соклануы хәттин ашкан. Студент елларында үзем дә чит ил әдәбиятына нәкъ шулай гашыйк булган идем, дөрес, ул елларда безгә китапларны кулга тотып, тәмләп уку бәхете тиде... Кызым үзе тыңлаган әсәрләргә шулкадәр мөкиббән: «Шундый бай әдәбият! Нишләп бездә мондыйлар юк икән?!.» – дигән сорау белән башын чайкый.

Һай, тарих тәгәрмәченең кабатлануы түгелме? Аның яшендә мин дә Флоберны, Голсуорсины һ.б. үз-үземә шундый ук сорау бирә-бирә укыган идем ләбаса! Җавап исә соңрак, тормыш тәҗрибәсе аша табылды.

– Нишләп булмасын?! – дим кызыма, бүген инде ныклы ышаныч белән. – Теләсәң, аудиокитапны рәхәтләнеп татарча тыңлый аласың. Аяз Гыйләҗевнең «Яра» әсәрен эзләп кара әле...

...«Яра»ның азагын без икәүләп өйгә чәй эчәргә кергәч тыңлап бетердек. Габдулланың, әти-әнисенә үзен танытырга теләмичә, китеп бару күренеше, сөйгәне Зәйтүнәнең аны куып җитеп: «Габдулла!» – дип эндәшүе... Бу әсәрне ничә укыган, спектаклен караган булсам да, мин янә өр-яңа тетрәнү кичерәм, җаным актарыла, күземә мөлдерәп яшь тула. Карыйм, кызымның да бар хис-кичерешләре чишмә булып бит алмасыннан тәгәри...

«Бу җәһәттән татар әдәбияты үрнәкләрен төрек теленә тәрҗемә итеп Төркиядә таратуда Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тәрҗемәче, публицист Фатиһ Кутлуның өлеше бик зур лабаса!

– Күрәсеңме, тирәнлеге ягыннан чит ил әдәбиятыннан бер дә ким түгел, – дим, һичьюгы шушы сүзләремә хуплау өмет итеп.

Беркадәр тынлыктан соң:

– Әнием, күпкә көчлерәк тә әле! – димәсенме кызым?!

Шул рәвешле башланган сүзебез «ни өчен безнең менә шушындый татар әсәрләре дөньякүләм киңлеккә чыгып, үзенең югарылыгын дәлилли алмый» дигән фәлсәфи һәм катлаулы сорауларга ук барып җитте. Чыннан да, әгәр Мәхмүт Галәү, Фатих Әмирхан, Хәсән Сарьян, Аяз Гыйләҗев һ.б. кебек әдипләрнең роман һәм повестьларын төрле чит телләргә тәрҗемә кылып тәкъдим итсәңме?! «Фәтхулла хәзрәт» әсәре үзе генә дә бүген бөтен дөньяны шаккатыра алыр иде...

Бу җәһәттән татар әдәбияты үрнәкләрен төрек теленә тәрҗемә итеп Төркиядә таратуда Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тәрҗемәче, публицист Фатиһ Кутлуның өлеше бик зур лабаса! Кызыксынуымны җиңә алмыйча, аның эшчәнлегенең кайбер сәхифәләренә күз төшерәм: 2005 елда Измирда чыккан «Васыять» җыентыгында Фатиһ бәй тарафыннан тәрҗемә ителгән җәүһәрләр – Миргазиян Юныс, Фатих Әмирхан, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Шәриф Камал хикәяләре тупланган. Истанбулда – Разил Вәлиевнең шигырьләре, Анкарада Рабит Батулланың роман-әкияте, Ркаил Зәйдулланың «Ак япанчалы карт» исемле китабы дөнья күргән. «Тавышсыз курай» җыентыгында – хәзерге татар әдәбиятыннан сайланма повесть һәм хикәяләр, «Сөяк саплы пәке» китабында татар балалар хикәяләре урын алган. «Алтын тиен» (башлангыч сыйныф укучылары өчен татар балалар хикәяләре) җыентыгына 28 татар язучысының – Фирүзә Җамалетдинова, Ләлә Гыймадиева, Галимҗан Гыйльманов, Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова, Алмаз Гыймадиев, Рөстәм Галиуллин, Ләбиб Лерон, Фоат Садриев, Айгөл Әхмәтгалиева, Эльмира Шәрифуллина, Ркаил Зәйдулла, Гәрәй Рәхим һ.б. авторларның хикәя-әкиятләре кертелгән.

Габдулла Тукай – татарлар өчен генә түгел, төрки телле халыкларның барчасы өчен үзгә бер биеклектә торган шагыйребез. Иҗатындагы халыкчанлык, гомумкешелек позициясе, тормыш чынбарлыгын бөтен тирәнлеге белән чагылдыру аның шигъриятен барлык милләтләрнең уртак хәзинәсе итә дә инде. Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулган көннәрдә, Ф.Кутлу һәм А.Акбаш тарафыннан шагыйрьнең 130 шигыре төрекчәгә тәрҗемә ителеп, Анкараның «Бәнгү» нәшриятында дөнья күрүе үзе үк олы бәягә лаек. Шул ук 2016 елның

апрелендә «Кардәш каләмнәр» журналы Габдулла Тукайга багышланган махсус сан рәвешендә басылып чыкты, анысы да Ф.Кутлу идеясе. Язмаларны сайлау, табу, күрсәтмә материаллар, тәрҗемә итү, урнаштыру да – аның хезмәте.

Саннарга күз төшерсәк, сокланырлык: Ф.Кутлу тәрҗемәсендә Төркиядә 12 татар китабы (роман, повесть, хикәя, шигырь) һәм әдәби журналның 2 махсус саны дөнья күрергә өлгергән!

Фатиһ бәйнең тәрҗемә эшчәнлегендә Аяз Гыйләҗев мирасы аерым бер урын алып тора. «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән», «Яра», «Язгы кәрваннар», «Берәү», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» кебек әсәрләр төрекчәгә тәрҗемә ителеп, аларның бик күбесе инде нәшриятларда басылырга өлгергән. («Берәү» белән «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» Төркиядәге нәшриятта үз чиратын көтә.) Биредә шунысын да өстәү урынлы булыр: Ф.Кутлу тәрҗемә иткән «Өч аршын җир» әсәре 2012 елда Ауразия Язучылар берлегенең «Төрки телләрдән төрек теленә тәрҗемә ителгән иң яхшы повесть-роман» номинациясендә җиңү яулый. Аяз Гыйләҗев иҗаты да нәкъ менә гомумкешелек идеяләрен, мәңгелек темаларны чагылдыру җәһәтеннән игътибарга лаек. Характерлар каршылыгы, геройларның эчке дөньясын гаҗәеп дәрәҗәдә төгәл итеп ачып бирү, хис-кичерешләр тирәнлеге, психологик осталык – болар барысы да аның әсәрләрен дөнья әдәбияты югарылыгына куярга мөмкинлек бирә дә инде. Тел-сурәтләү чараларының байлыгы турында әйтеп тә торасы юк. Кулланылган һәр сүз, тасвирланган һәр хәрәкәт, сюжет коруга ярдәм иткән һәр вакыйга әдипнең талантын раслауга хезмәт итә.

> **«Характерлар каршылыгы, геройларның эчке дөньясын гаҗәеп дәрәҗәдә төгәл итеп ачып бирү, хис-кичерешләр тирәнлеге, психологик осталык – болар барысы да аның әсәрләрен дөнья әдәбияты югарылыгына куярга мөмкинлек бирә дә инде.**

Истанбулда чыгып килүче «Тәмрин» журналы быел апрель аенда А.Гыйләҗев иҗатына махсус сан багышлаган. Журналның баш мөхәрриренең: «Хәзерге заман татар әдәбиятының бөек вәкиле Аяз Гыйләҗевкә багышланган аерым сан әзерләргә телибез, безгә булыша алмассызмы?» – дип, Фатиһ Кутлуга мөрәҗәгать итүенә гаҗәпләнергә дә кирәкми. Чөнки олы әдибебез А.Гыйләҗев әсәрләре нәкъ менә аның тәрҗемәсендә Төркиядә дистә елдан артык дөнья күреп килә, һәрчак «әйләнештә», дип, алдарак та искәртеп үттек. («Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән», «Яра» әсәрләре турында төрек әдипләре даими язып торалар. Ул мәкаләләрнең кайберләре, тәрҗемә ителеп, татар матбугатында да урын ала.) Ф.Кутлу бу хезмәткә дә җиң сызганып алына һәм әлеге махсус сан тышлыгында «Татар әдәбиятының шанлы сакчысы Аяз Гыйләҗев» атамасы белән дөнья күрә.

Төрек галиме Абдүлкадир Чәкичнең Аяз Гыйләҗев әсәрләре буенча кандидатлык диссертациясе яклавы аерым бер хуплауга һәм игътибарга лаек. Фатиһ бәйнең әйтүенчә, Абдүлкадир Чәкич «Өч аршын җир» әсәренең күп өлешен, төрекчә тәрҗемәсе аша, бүгенге көндә инглиз теленә тәрҗемә итеп бетергән. Хәзер Канада, Америка кебек илләрнең берсендә бастыру буенча

нәшриятлар белән сөйләшүләр алып бара һәм тиешле финанс табылганда басылачагын хәбәр иткән.

Төрки телле дәүләтләр арасында үткәрелгән хикәяләр бәйгесенә татар язучыларының әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә кылып тәкъдим итүдә дә Фатиһ Кутлуның хезмәте зур. Шәхсән үземнең «Капка» хикәясе 2014 елда шул бәйгедә катнашты, Татарстанда беренче урынны яулаганнан соң, аны, төрекчәгә «аударып», бәйгенең алдагы турына җибәрергә кирәк иде. «Кирәк» дип әйтүе генә җиңел: анда бит вакытның санаулы һәм тыгыз булуы да чабудан тарта! Тәүлекләрне тулаем шул эшкә багышлады микән – Фатиһ бәйнең искиткеч җаваплы карап эшләве нәтиҗәсендә, хикәя төрек теленә тәрҗемә ителеп өлгерде. Һәм, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте-хикмәте белән, 13 дәүләттән вәкилләр катнашкан халыкара бәйгедә икенче урынны яулады. Монда тәрҗемәченең ролен һич кенә дә инкяр итеп булмый!..

Төркиядән килеп, Татарстанда яшәп ятучы ир-егетнең татар әдәбиятына мәхәббәте һәм игътибары да, зур көч, тырышлык, үҗәтлек һәм вакыт таләп итүче тәрҗемә эшенә алынуы да, ул әсәрләрне киң күңел белән үз ватандашларына җиткерергә омтылуы да соклангыч гамәл.

Сүз башым бит Шүрәле, дигәндәй, әгәр башкаларныкыннан һич тә ким булмаган әдәби мирасыбызны шул рәвешле төрле телләргә даими тәрҗемә итеп, зуррак киңлеккә чыгару мөмкинлеге табылса, Фатиһ бәй кебек фидакяр җаннар күбрәк булса, бәлки, чит ил яшьләре дә дөньяда «Татар әдәбияты» дигән гаҗәеп бай хәзинә барлыгын белер, колакчын киеп, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев әсәрләрен инглиз, кытай һәм алман телләрендә тыңлар иде... ■

**«Җәй». «Ел фасыллары» сериясеннән. 2003 ел**

# Диләрә Нәүрүзованың китап дөньясы

*Китап – кешенең гомерлек юлдашы. Уч төбенә сыярлык беренче китапчыкларның рәсемнәренә карап, балалар дөньяны танып-белергә, «Әлифба»дагы сурәтләргә сокланып, дөрес, матур сөйләргә өйрәнә. Мәхәббәт романнарындагы рәсемнәр исә сөю хисен бөтен җаның белән тоярга ярдәм итә. Тарихи басмалардагы сурәтләрне карагач, иркен дала җилләрендә тирбәлеп үскән әрем исләрен сизгәндәй, дала буйлап чапкан атларның тояк тавышларын ишеткәндәй буласың. Китап бизәү сәнгате, шагыйрь, прозаик, драматург иҗатлары кебек үк, кешелекне мәгърифәткә илтә. Каләм әһелләренең иҗат эшчәнлеге ни дәрәҗәдә мөһим булса, китап бизәүче рәссамныкы да шундый ук зур әһәмияткә ия. Язучыга иярүдән туктап, аның автордашына әйләнә башлаганнан бирле, китап бизәүче рәссамның роле бигрәк тә үсте.*

*Китап сәнгатендә үз йөзен булдырган шундый рәссамнарыбызның берсе Диләрә Нәүрүзова матур гомер бәйрәмен билгеләп үтә. Диләрә чал тарихлы Казанда туган. Казан сәнгать училищесының театраль-декорация бүлеген тәмамлаганнан соң, ул 1990 елда журналлар белән хезмәттәшлек итә башлый. График дизайн белән кызыксынуы арткан-нан-арта барып, 1994 елда Мәскәү дәүләт басма китап институтына укырга керә. Анда совет чорында балалар китапларын бизәүче буларак танылган РСФСРның атказанган рәссамы, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе,*

*профессор В.В.Перцовта белем ала. Казанда махсус дипломлы белгечкә сорау зур була. Диләрә, Татарстан китап нәшрияты, «Мәгариф», «Рухият», «Идел-Пресс», «Заман» һ.б. нәшриятлар белән хезмәттәшлек итеп, Габдулла Тукай, Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллин, Равил Бохараев, Клара Булатова һ.б. әдипләребезнең йөзгә якын китабын, шуның белән бергә Г.Х.Андерсен, Р.Киплинг, А.Конан Дойлның татарчага тәрҗемә ителгән әсәрләр җыентыкларын бизи. Төрле елларда «Идел», «Салават күпере», «Сәхнә», «Безнең мирас» журналларында эшли.*

*Форсаттан файдаланып, рәссам* **Диләрә Ленар кызы Нәүрүзова** *һәм республикабызның күренекле графика белгече, сәнгать фәннәре кандидаты* **Ольга Львовна Улемнова** *белән әңгәмә кордык.*

***– Диләрә ханым, китап бизәү – авыр, четерекле сәнгать. Ничек китап бизәүче булып киттең?***

– Кечкенәдән рәсем сәнгатенә гашыйк булып үстем. Китаплардагы матур рәсемнәрне озаклап карый торган идем. Әнием бу мавыгуымны үстерергә тырышты. Әнием, Фәһимә Хәлим кызы Абдрахманова, Татарстан китап нәшриятында эшләүче хезмәткәр буларак, миңа күрсәтергә дип, күренекле рәссамнарыбыз Байназар Әлминов, Иван Язынин, Тавил Хаҗиәхмәтов, Александр Туманов, Фәридә Хәсьянова, Юрий Денисов һәм башкаларның рәсемнәре оттискларын алып кайта иде. Татар китапларын бизәүче олпат рәссамнарыбызның иҗаты белән беренче танышуым шулай булды. Әнием рәсемнәргә әсирләнеп каравымны күреп: «Үскәч, син дә китаплар бизәрсең, зур кеше булырсың», – дип үсендерә иде. Аның бу сүзләре хак булып чыкты... Сәнгать училищесында Суриков институтын тәмамлаган талантлы рәссам, оста мөгаллимә Наилә Кумысниковада уку бәхете эләкте. Танылган актриса Асия Хәйруллина һәм сәнгать белгече Халит Кумысников гаиләсендә тәрбияләнеп үскән затлы-зыялы шәхес буларак, ул бездә дә нечкә зәвык тәрбияләде, ныклы белем, күнекмә бирде, мөстәкыйль фикер йөртергә, бертуктамый эзләнергә этәрде. Театр сәнгатенә карата мәхәббәт уятып кына калмыйча, күпләп рус, совет чорындагы, дөнья драматургиясе классикларының пьесаларына кызыксыну тудырды. Таләпчән, алдан уйлап эшли белгән акыллы педагогыма мин бүген дә бик рәхмәтле. Укуны тәмамлагач, нәшриятларда беренче чирканчык алырга җай чыкты. Шулай китап бизәү эшенә кереп кителде. Әмма аның белән генә канәгатьләнмичә, белемне үстерү өчен, Мәскәүгә укырга юл тоттым. Мәскәү дәүләт басма китап институты – совет заманыннан бирле махсус һөнәр бирә торган данлыклы уку йорты. Биредә безгә төрле графика материалларын һәм техникаларны, аларның үзенчәлекләрен үзебезгә файдалы итеп кулланырга өйрәттеләр, китапны бербөтен итеп карау, бөтен элементларның бер-берсе белән бәйләнешен, бер идеягә буйсынганын, бер стильдә иҗат ителгәнен күрү кирәклеген төшендерделәр. Нәтиҗә буларак, диплом эшемнең бер өлеше студентлар арасында уздырылган «Золотой апельсин» иң шәп басма продукция халыкара бәйгесендә беренче урын алды.

***– Ольга Львовна, диплом эшенең икенче өлеше дә бар бит әле. Сез аны югары бәяләгәнсез дип беләм.***

– Чыннан да, Л.Кэрроллның «Алиса в стране чудес» әсәре буенча башкарылган диплом эшендә үк Диләрә үзен оста график буларак күрсәтә. «Рәсемнәр матур, җиңел, укучыны мавыктырырлык итеп башкарылган», – ди алар турында күренекле рәссамыбыз Наилә Кумысникова. Тормыштагыча сурәтләнсә дә, әсәр геройларына һәм предметларга үзенә бер төрле стиль хаслыгы күренә. Рәссам, инглиз җәмгыятенең рухын һәм Кэрролл әсәренең башка сыймас-

**«Дөнья халыклары әкиятләре» китабындагы «Ай юрганы» дигән Норвегия әкиятенә иллюстрация. 2011 ел**

лык сәерлеген чагылдыру өчен, гадәти булмаган композицияләр корган.

***– Диләрә ханым, синең иҗатта аерым китаплар гына түгел, озак еллар дәвамында чыгарылган китап шәлкемнәре дә бар. Мәсәлән, күренекле драма артистлары турында мәкалә һәм истәлекләр җыентыклары бик бай эчтәлекле, матур булып чыкты, театр сөючеләр аларны кибет киштәләреннән кырып-себереп алып бетерә торды. Хәтерем ялгышмаса, бу серия ун елга сузылды. Бер китаптан башланып, эшнең дәвамлыга әйләнүенең берәр сере бармы?***



**«Ак бүре» китабындагы «Алпамша» татар халык әкиятенә иллюстрация. 2012 ел**

– Бервакыт «Таһир-Зөһрә» газетасы журналисты Рәйсә Юсупова язучы, драматург Шәриф Хөсәенов турында китап чыгару тәкъдиме белән мөрәҗәгать итте. Аның бу идеясен академия театрының директоры Шамил Закиров күтәреп алып, хәленнән килгәнчә ярдәм күрсәтте. Аннары олуг артистыбыз Әзһәр Шакиров турында шундый ук мәкаләләр һәм очерклар җыентыгы дөнья күрде. Бу ике китап талантлы актерыбыз Ринат Таҗетдинов, актриса Нәҗибә Ихсанова, җырчылар Зифа Басыйрова һәм Зөһрә Сәхәбиева турындагы китаплар сериясенә нигез салды. Шулай итеп, Рәйсә апаның куллары җиңел булды. Алга таба кабатланмас актриса Асия Хәйруллина, академия театры директоры Шамил Закиров турында «Балкыш» истәлекләр китабын, Татарстанның халык шагыйрьләре Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, бөек җырчы Хәйдәр Бигичев турында саллы басмаларны бик кызыксынып бизәдем. Нәтиҗәдән дә бигрәк, миңа эш үзе кызык. Һәр китабымны күңел биреп эшлим. Каһарманнарымның иҗаты үземнең дә күңелемне баета.




**Р.Бохараевның «Пьеса-әкиятләр» («Пьесы-сказки») китабына иллюстрация. 2016 ел**

***– Ольга Львовна, ә Сез китап серияләре турында ни диярсез?***

– Татарстаныбызда сәнгатьне, әдәби сүзне Диләрә Нәүрүзовадан да нечкәрәк тоемлаучы графикны табуы кыен. Ул бизәгән китаплар уңышлы чыгып, җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп иткәч, серияләр барлыкка килде. Югарыдагыларга өстәп, тагын бер китап шәлкеме турында әйтмичә булдыра алмыйм. 2011 елда «Ай юрганы» әкиятләр китабы Татарстан китап нәшриятында дөнья халыклары әкиятләре шәлкеменә нигез салды. Шуннан соң 2012 елда – «Ак бүре» татар халык әкиятләре китабы, тагын бер елдан – «Мең дә бер кичә» гарәп әкиятләре җыентыгы, 2014 елда «Казлар-аккошлар» рус әкиятләре китабы дөнья күрде. Рәссам һәрбер китапта гаҗәеп могҗиза дөньясы тудырган. Андагы мавыктыргыч хәлләрне, кызыклы геройларны, төрледән-төрле предмет-атрибутларны сәгатьләр буе өйрәнергә мөмкин. Халыкларның милли үзенчәлекләре, пейзаж, архитектура, геройларның төс-кыяфәте, костюмнары, композицияләрдә өстенлек иткән буяу төсмерләре һәм бизәкләр аша чагылдырылган. Шул ук вакытта сызымнар, композиция төзелеше, нечкә колорит авторның рәсемләү үзенчәлеген хасил иткән.

***– Диләрә ханым, әкият китапларын бизәгәндә күңелең мәтәлчек аткандыр, ник дигәндә, хыял байлыгын күрсәтергә мөмкинлек зур. Әкиятләрдән соң дәреслекләр бизәү күңелсез тоелмадымы соң? Дәреслекләр чыгаруда да өлешең зур бит. «Мәгариф-Вакыт» нәшриятында чыккан татар теле һәм татар әдәбияты дәреслекләре матур булып истә калган. Әле бүген***

***дә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре гомуми белем бирү мәктәпләре өчен төзегән «Туган тел (татар теле)», «Әдәби уку» дәреслекләрен бизисең дип беләбез.***

– Иркенәеп китәргә мөмкинлек булмаса да, дәреслек бизәү кызык түгел, димәс идем. Һәр эшнең үзенең максаты бар. Дәреслек бизәүдә төп максат – татар балаларына ана телебезнең көен-моңын тагын да тирәнрәк тоярга ярдәм итү, татар телен өйрәнүче рус балаларына исә телебезгә, милли мәдәниятебезгә, гореф-гадәтләребезгә кызыксыну уяту. Рәсемнәрем мәктәп балаларында татар халкына хөрмәт-ихтирам һәм телебезне өйрәнү теләген тудырырга тиеш. Дәреслек бизәү – милли сәясәткә бәйле бик җаваплы эш.

***– Инде әңгәмәбезнең иң тәмле өлешенә – Равил Бохараевның 2016 елда «Kazan-Казань» нәшриятында чыккан «Тень Тамерлана» китабына һәм әкият-пьесалар җыентыгына килеп җиттек. Равил ага бу поэмасын студент елларында ук иҗат итсә дә, моңа кадәр бер тапкыр да нәшер иткәне булмаган. Ә иң мөһиме – ике китапта да, бигрәк тә «Тень Тамерлана» әсәре бизәлешендә бөтен дөньяны күңеленә сыйдырган әдипнең фәлсәфи рухы чагыла. Күптән түгел Аксенов йортында шагыйрь, прозаик, гомумән, киң кырлы талант ияcе Равил Бохараевны искә алу кичәсендә китапларны тамашачыларга тәкъдим итү бик күтәренке рухта узды. Аңлавыбызча, «Тень Тамерлана» һәм әкиятләр җыентыгы – рәссам Диләрә Нәүрүзова иҗатында гына түгел, Татарстан китап бизәү сәнгатендә дә истә калырлык вакыйга. Графика буенча зур белгечебез Ольга Львовнаның бу китапларга бәясен белү журнал укучыларына да кызык булыр дип уйлыйм.***

– Чыннан да, бу китапларда рәссамның моңа кадәр тупланган бөтен тәҗрибәсе, милли тарихка булган кызыксынуын билгеле бер форма аша күрсәтү омтылышы чагыла. Диләрә һәр ике басмада да китап бизәү чараларын мул кулланган – тышлыклар, форзац, титул, шмуцтитул, иллюстрацияләр, тексттан алда һәм ахырдан килә торган рәсемнәр өчен кабатланмас композицияләр иҗат иткән. Иллюстрацияләре күп фигуралы композицияләрдән гыйбарәт. Аларда тарихи дөреслек, сюжет вакыйгалары, үткәннәрнең рухы бергә үрелгән. Беренче карауда гына бөтен мәгънә һәм символларны ачып бетерә торган түгел. Шул ук вакытта китапларның бизәлеше кирәгеннән артык купшы булып та тормый. Нечкә сызымнар белән, буяу төсмерләрен сайлап кына кулланып, акыл, мантыйкка таянып иҗат итү нәтиҗәсендә, рәссам текст һәм бизәлеш тигезлегенә ирешкән.

***– Китап сәнгатендә шулкадәр көч куйгач, станок графикасы өчен вакыт та калмыйдыр. Әмма белгечләребез рәссам Диләрә Нәүрүзованың иллюстрация буларак түгел, мөстәкыйль иҗат ителгән рәсемнәрен дә бик югары бәяли.***

– Сәнгать белгече буларак, рәссам иҗатының бу өлкәсе турында да үзем әйтим әле.

***– Рәхим итегез, Ольга Львовна!***

– «Ел фасыллары» рәсемнәр шәлкемендә кылкаләм остасы Диләрә Нәүрүзованың бөтен иҗатына хас алымнар-ны – теманы ачканда, фәлсәфи якын килүне, сюжет артында торган символизмны, сурәтләрдәге тормышчанлык һәм шартлылыкны, график фактураларның байлыгын һәм төрлелеген күрергә мөмкин. Рәсемнәр шәлкеме графит карандаш белән башкарылган. Рәссам кулында ул сурәткә көмеш нур сирпегән гаҗәеп материалга әйләнә. Сизелер-сизелмәс акварель

таплары рәсемнәргә яз, җәй, кыш, көз төсмерен бирә. «Шагыйрьнең соңгы көзе» рәсемендә графит карандаш төрлечә ят-кан. Бер җирдә сызымнар җете, ап-ачык булса, икенче урында үтәкүренмәле һәм җиңел. Кайбер өлешләрдә ул мул һәм ты-гыз булып, кайберләрендә күл өстендә таң алдыннан таралган сихри томан сы-ман. Шуларны бергә кушкач, кичектермәс трагедия хисе белән сугарылган шәһәр пейзажы барлыкка килгән. Җылы, ко-яшлымы, әллә, киресенчә, яңгырлы, караңгымы ул көз? Ничек кенә булма-сын, татар халкы тарихында ул иң моңсу көз булып сакланачак. Рәсемдә Тукай үзе сурәтләнмәсә дә, җир йөзендә нибары 27 ел яшәп, 1913 елда бакыйлыкка күчүенә карамастан, хәзерге заман татар әдәби теленә нигез салган бөек татар шагый-ре Габдулла Тукай хакында сүз барга-нын шунда ук аңлап алабыз. Рәссам ап-ачык шәһәр күренеше ясамаса да, төгәл архитектура, күңелгә якын мохит аша Казаныбызның Татар бистәсе образын ту-дырган. Рәсемдә символик яңгырашка ия детальләр байтак. Җил-давылдан бөгелеп төшкән нык агачлар, яралы яугирләр сы-ман, бау белән чорналган. Җимерелеп төшеп калган арба көпчәге юлның бетүен искәртә сыман. Кара каргалар – хәвеф билгесе. Суда чайкалган ялгыз көймә борынгы грек мифологиясендәге Лета елгасында соңгы юлга озатыр өчен пассажирны көткән Харон көймәсен хәтерләтә... Сүземне йомгаклап тагын шуны әйтәсем килә: рәссам Диләрә Нәүрүзованың үзенчәлекле иҗатында шәрык һәм көнбатыш рәсем сәнгате традицияләре бергә үрелгән. Иҗат куәсе, хыял байлыгы зур. Милли тема тирәсендә эзләнүләре яңа матур иҗат җимешләре булып әвереләчәгенә өметләнә алабыз.

***– Диләрә ханым, якын киләчәккә планнарың нинди?***

– Татар әкиятләрен күп бизәсәм дә, мавыгуым артканнан-арта гына бара. Милли хис яши-яши көчәя, күрәсең. Булган бөтен тәҗрибәм белән кабат

Р.Бохараевның «Тень Тамерлана» китабына «Шүрәле» иллюстрациясе. 2016 ел

татар әкиятләренә әйләнеп кайтыр идем. Әкиятләр буенча станок графи-касы иҗат итәсе килә. Киләчәктә алар китап булып та басылып чыгар иде, бәлки. Нәшир, меценат Иосиф Кнебель үз заманында, эчтәлеге онытылса да, китаптагы рәсемнәр озак еллар, бәлки, гомер буе да баланың күңелендә сак-ланырга мөмкин, дигән. Чыннан да, буыннан-буынга тапшырыла килгән матур китапларыбыз бар. Алар кебек үк, минем китапларымны да кадерләп сакласалар, шат булыр идем.

***– Рәхмәт, уңышлар Сезгә!***

*Әңгәмәдәш* – ***Миләүшә Галиуллина*** ■

**Редакциядән:**

***Элекке хезмәттәшебез, танылган рәссам һәм дизайнер Диләрә Нәүрү-зованың 27 декабрьдә гомер бәйрәме. Аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек, бәхет һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!***

Безнең мирас №12 декабрь 2020

# Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

## Буддизм

Өченче һәм дүртенче бүлекләрдә буддизм хакында кайбер мәгълүматлар бирелгән иде. Бу юлы Япониядәге буддизм турында кайбер фикерләрем белән уртаклашырга телим. Японнарга пәйгамбәр килгән микән? ***«Без бер рәсүл җибәргәнчегә кадәр газапламаячакбыз»*** (Исра: 15), – дигән бөек аять дәлил булып тора: японнарга да пәйгамбәр килгән. Тик ул кем һәм кайчан килгән? Бу безнең өчен билгесез, шуңа күрә, әлбәттә, бу хакта берни әйтә алмыйбыз. Шулай да фикеребезне белдермичә дә үтмәячәкбез.

Японнарның 2500 елга якын тарихы теркәлгән, димәк, билгеле. Бу вакыт эчендә берәр пәйгамбәр килгәнме-килмәгәнме – японнар моны белми.

Инде килеп, японнар дин дип кабул иткән буддизм нәрсә икән соң ул? Кем ул Будда? «Безнең Ислам китапларында бу хакта берни юк», – дип әйтә алабыз.

Бездә, гомумән алганда, дин дип беленгән ислам, христианлык һәм яһүдилек, ягъни иудаизм бар. Болардан башкасына гел «мәҗүси» дибез. Ул мәҗүсиләр арасында ниләр бар? Болар турында һич мәгълүматыбыз юк. Югыйсә хәзерге вакытта дөньяда яшәгән халыкның күпчелеген болар тәшкил итә. Аларга пәйгамбәрләр җибәрелде микән соң? Яисә аларны дингә чакыру кирәкме? Әгәр кирәк икән, кем чакырырга тиеш? Болар турында борынгылар уйламаган. Мөселманнар, нигездә, гафләт эчендә тәгәрәп барганнар һәм әле дә тәгәриләр. *«Синең аша Аллаһның бер кешене һидаятькә ирештерүе синең өчен көтү-көтү кызыл сарыкларыңнан хәерлерәк»*, – дигән изге хәдисне «мондый нәрсә очраса» мәгънәсендә аңлатканнар,

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

«бу юлда иҗтихад итсәгез, ягъни тырышсагыз, көч куйсагыз» мәгънәсен башларына да китереп карамаганнар.

Икенче яктан: *«(Хәзрәте Мөхәммәд) соңгы пәйгамбәр һәм моннан соң инде пәйгамбәр килмәячәк», – дип белдерәбез»*, – диелә. Алай булгач: *«Без, бер рәсүл җибәргәнчегә кадәр газапламаячакбыз»* (Исра: 15), – дигән бөек аятькә нинди мәгънә бирергә? Безнең голәмә бу хакта фикер йөртергә тиеш дип уйлыйм. Әгәр без уйланмасак, соңыннан безгә бик яхшылап хәтерләтерләр. Болай да динебезнең дошманнары мондый нәрсәләрне гел тикшереп кенә торалар.

Инде биредә мин башта шуны әйтергә телим: Тибетта ламалар өйрәтә торган буддизм башка, Япониядәге буддистлар өйрәтә торган буддизм башка. Күп кенә яктан хәтта берсенең икенчесе белән һич кенә дә бәйләнеше юк кебек. Бигрәк тә гамәли нәрсәләрдә бик зур аермалар бар. Гыйбадәтләрендә дә, потханәләрендә дә бик зур аерма булуы күренә. Хәтта диннең нигезе дә бер үк түгел. Мәсәлән, Тибет ламаларының инанулары болай: *«Табынырга лаеклы бер зат була, аны эзләргә кирәк, колның вазыйфасы – аны эзләү»*. Моңа тәүхид дип әйтергә була. Пот табу, потлы булу – таләпләрендә булган хаталары ул. Ислам голәмәсе моны төзәтсә, бик төз юлга салыначагын өмет итәргә була.

Япон буддистлары илаһилекне инкяр итәләр. Әмма могҗизаларны раслап, үзеннән берәр могҗиза барлыкка килгән кешене шунда ук илаһи зат дип саныйлар. Могҗизалары да без белгән нәрсәләр түгел, элек булмаган берәр нәрсә уйлап табып, аны бар халыкка кабул иттерү дә бер могҗиза булып санала. Менә Микадоның илаһилеге дә шулай барлыкка килгән. Башта: *«Аерым булган милләтләрне бергә җыйган, димәк, куәте бар. Менә шул куәт илаһилек кодрәте инде»*, – диләр. Боларда да кодрәтле дип тану бар. Кеше мөмкинлекләреннән өстен берәр нәрсә булса, ул табынырга лаеклы дип таныла. Һиндстанда Брахманың да һәр яңалыкка илаһилек бирүе шушы ук мәгънәдә дип уйлыйм. Борынгы заманнардан бирле Брахма сихерчеләрнең илаһилеген таный торган булган. Соңгы вакытларда хәтта телеграфны, телефонны, поездны да илаһи дип саный башлаганнар.

Боларның бөтенесен игътибарга алып яхшылап уйлансаң, Имам Газали әйткәнчә, максат гел бер үк, хаталар бары тик таләптә генә булып тоела.

Менә шуларны исәпкә алып, мин Япониядә дин мәсьәләсенә бераз артыграк та әһәмият бирдем һәм моңа бик күп япон шәхесләренең игътибарын җәлеп иттем. Акыл ияләренә боларны сөйләп-аңлатып бирүгә үк, кызыксынуларын күреп ала идем.

## Омихара белән күрешү

Омихара – японнарның дини рәисләренең берсе. Мин бу кеше белән башта очраклы гына танышкан идем, аннан соң күп тапкырлар күрешеп сөйләштек, арабызда дуслык, якынлык хасил булды. Беркөнне әңгәмәбез арасында миңа болай диде: *«Буддизм бүгенге көндә нигезен югалткан. Бигрәк тә безнең Япониядә динне тәмам чыгырыннан чыгарганнар. Бездә илаһи затлар шулкадәр күбәйгән ки, санап бетерерлек түгел. 50 елдан соң Принц Ито да, Можохито да илаһ булачак. Боларны уйлап, чымырдап куям. Сез биредә бераз озаграк калсагыз, бу дин мәсьәләсен ныклы бер нигезгә утыртыр идек. Бүгенге көндә минем ун меңнән артык фикердәшем бар, мин ни дисәм дә, яхшы, шулай булсын, дип кабул итәчәкләр. Мин, гомумән, үземнән күбрәк, алар өчен борчылам. Шулкадәр кеше үзен минем вөҗданыма ышанып тапшырган. Ә мин үзем дә икеләнеп кабул иткән динне ничек итеп башкаларга «хак дин»*

*дип тәкъдим итим, инандырыйм, нәсыйхәт бирим? Боларны уйлап, минем вөҗданым бик газаплана».*

Менә карагыз сез бу хәлгә һәм бу вөҗданга! Үзе уйланып, үзе борчылып, вөҗдан җаваплылыгы хис итә.

Мин бу шәхес белән бик самими аралаша идем. Беркөнне ул мине Токио шәһәрендә Кандабаши дигән җирдә оештырыласы бер конференциягә чакырып, дин һәм милли әхлак турында бераз булса да мәгълүмат бирүемне үтенде. Ул көннәрдә минем башка очрашуларым да бар иде, шул сәбәпле бу конференцияне бераз күчереп торуларын сораган идем дә вакытын күчергәннәр иде.

## Сарай министры Хиҗиката җәнаплары белән күрешү

Хиҗиката – император сарае министры һәм императорның бик күптәнге дусты булганга, гаять мәгълүматлы һәм «Япониянең аяклы тарихы» дип аталырга лаеклы шәхес. Бу мөхтәрәм зат белән дә берничә тапкыр күрештем, дәүләт йортында кунакта да булдым, үзеннән шактый бай мәгълүмат алдым. Бу шәхес, Япониянең бик күптәнге дәүләт кешесе булуы белән бергә, япон милләтенең иң бөек хезмәткәре дә иде. Моннан тыш, Микадо җәнаплары шәхсән бу кешенең өенә килеп кунак булган, ул Микадоның дусты икән.

Микадо җәнаплары үз халкы арасыннан бу кешедән башка берәүнең дә өендә кунак булмаган, шуңа күрә дә әлеге шәхеснең япон халкы арасында үзенә аерым бер урыны бар.

Беркөнне дәүләт йортында бу шәхес белән күрештем, кунак булдым. Башта мине Аурупа ысулында кабул итте. Аурупадан килгән кунаклар өчен билгеләнгән бүлмәдә бер 15 минутлап утырдык. Берәр чынаяк чәй эчкәннән соң, Хиҗиката җәнаплары миңа болай диде: *«Мин рәсмилекне үтәдем. Безнең бу бүлмә Аурупадан килгән кунаклар өчен. Рөхсәт итсәгез, үзебезнең залга күчик, анда озаклап сөйләшеп утырырбыз. Бакчада да йөрербез».*

Аурупа ысулы белән хәзерләнгән бүлмәне калдырып, бакча уртасындагы кечкенә генә япон өенә килдек.

Монда җиһаз дип әйтерлек бер мангал һәм утырыр өчен ике-өч мендәр генә бар иде. Өй эче иң фәкыйрь бер японның өеннән берни белән дә аерылмый, шулкадәр гади.

Бирегә килеп җитүгә, Хиҗиката җәнаплары болай диде: *«Гафу итегез, без балачактан биредә яшәдек, үстек, тәрбияләндек һәм башка җирдә үзебезне рәхәт хис итә алмыйбыз. Шуңа күрә Сезне ардырып, монда кадәр алып килдем. Без Сезнең белән Көнчыгыш халыклары, әңгәмәбезне дә Көнчыгыш ысулында корыйк».*

**Хиҗиката**

Мин башта хөрмәтле укучыларымның игътибарына Хиҗиката җәнапларының рәсемен тәкъдим итәргә телим, чөнки йөзен күрү бик мөһим.

Японнар, гомумән, күп уйлый, аз сөйләшә торган милләт. Бервакытта да уйламыйча сүз сөйләмәсләр, шаян сүз әйтергә уйлаганда да, япон кешесе башта уйлар, аннары гына әйтер. Хиҗиката җәнаплары японнар арасында бик күп уйланучы, фикер йөртүче булуы белән танылган. Йөзенә игътибар белән карасагыз, фикер ке-

шесе икәне аңлашыла. Сөйләшкәндә өздереп-өздереп сөйли, сүзләрен тулысынча аңлап барырга мөмкин, чөнки сөйләгәндә дә уйлый-уйлый сөйли.

Игътибарыгызга бу мөхтәрәм зат белән өендә утырганда арабызда булып үткән сөйләшүне тәкъдим итәм.

Хиҗиката җәнаплары өйгә кергәндә миңа болай диде:

– Минем үз гомеремдә бер генә тапкыр да Русия эчендә яшәгән татарларны күргәнем булмады, менә беренче тапкыр Сезне күрәм. Тик татар тарихын күп укыдым, элек-электән татарларга карата аерым бер мәхәббәт хисем бар. Бигрәк тә Тимергә олы ихтирамым бар. Ул кеше – җир шарындагы иң бөек кешеләрнең дә иң бөеге. Шул нәселдән бер кешенең минем өемдә кунак булуы һичвакыт онытылмаячак вакыйга, истәлек булачак. Мине бәхетле иттегез, бик рәхмәтлемен. Мин заманыбыз татарлары турында берни белмим, тик өмет итәм: **үткәне бөек булган милләтнең киләчәге дә бөек булачак. Бик нык өшәнгәннән соң, бер торгынлык чоры килә, зыян юк, арыслан ул – һәрвакыт арыслан.** «Зынҗырга төшү арысланга гарь түгел», – диләр. Хәзер мин Сездән татарларның бүгене һәм киләчәге турында бераз мәгълүмат бирүегезне сорыйм. Русиядә татарларның саны бик күптер, шулаймы?

– Русиядә татарларның саны бик күп, утыз миллионга якын дип санала. Ләкин озакка сузылган әсирлектән, золым һәм тиранлыктан бик нык яньчелгәннәр. Урыслар татарларга сулыш алырга да мөмкинлек бирмәгәннәр. Белем һәм мәгарифтән мәхрүм итәр өчен, кулларыннан килгәннең барысын да эшләгәннәр. Үзләрен бетерергә тырышканда, табигый сәләтләрен дә бетәр дәрәҗәгә китергәннәр, өмет тудырачак берни калдырмаганнар. Тик татарларга өметсезлек килмәгән, табигый эшчәнлекләре элеккечә үк диярлек дәвам итә. Шулай бара торгач, әгәр күңел төшенкелеге килмәсә, тырышып-тырмашып һәм киләчәктә үзен тагын бер тапкыр исбатлар. Әлбәттә, урыслар да тырышачак, алар да тезгенне кулларыннан ычкындырырга теләмәячәк.

– Кеше бар нәрсәне дә аулый ала, тик арысланның вазыйфасы – зынҗырны өзү. *(Елмаеп куйды.)* Русиядәге татарларның тормышлары ничек бара? Бай, чиндәрәҗәсе булган, җитештерү җитәкләгән татарлар бармы? Думада күпме татар вәкилегез бар?

– Гомумән алганда, татарлар ярлы-фәкыйрь. Тик тормыш итү рәвешләрендә электән килгән үзенчәлекләрен саклаганнар һәм саклыйлар. Татар авылына читтән карасаң, аның татар авылы икәнлеге шунда ук аңлашыла. Ул урыс авылларына бөтенләй охшамаган. Өй эчендә дә, иң ярлы татар кешесенең өендә иң бай урыс кешесенең өендә булган кадәр арулык була. Кыскасы, тормыш-көнкүреш, гадәт һәм әхлак ягыннан һич кенә дә җиңелгәннәр дип әйтеп булмый. Мөселманнар сан ягыннан шактый күп булган төбәкләрдә, саннары урыслар кадәр үк булмаса да, бик күп яктан урыс үзе татарга җиңелгән, дип әйтеп була. Уфа, Казан якларында татарлар урыс телен белмиләр, киресенчә, урыслар татарча өйрәнгәннәр һәм бик яхшы татарча сөйләшәләр. Әйе, беренче карашка, татарларның урыс телен белмәүләре зур кимчелек, тик әйләнә-тирәдәгеләрне үз телләрендә сөйләшергә мәҗбүр итү, әлбәттә, җиңү көче булып тора. Кайбер төбәкләрдә хәтта урыс халкының зур бер өлеше үз гаиләсе эчендә дә татарча сөйләшә. Кыргыз далаларында татар теле җәелгән. Моннан соң ел үткән саен татар теле киңәячәк һәм киңәя бара. Кайбер җирләрдә бу телнең йогынтысы астында исламга килүчеләр дә бик күп. Байлык һәм дәрәҗә ияләренә килсәк, кызганыч, болар бик аз. Капитал ияләре бөтенләй юк дияргә мөмкин. Берничә фабрика тотучы, берничә миллионы булган сәүдәгәрләр

бар. Моңа ирешкәннән соң, сәүдә идарәсендә үз сүзләрен тыңлата ала торган булалар. Чин-дәрәҗә ияләре бөтенләй юк, дисәм дә, дөрес булыр. Дөресен генә әйткәндә, була да алмый, чөнки Русия хөкүмәтенең кануны моны рөхсәт итми. Хәрби хезмәттә булса, иң зур дигән чины – полковник. Паша дәрәҗәсендәге иң зур хәрби чинга ирешә калса, шунда ук лаеклы ялга озаталар. Җәмгыять тормышында ирешә алачак иң зур дәрәҗәсе – прокурор. Шуннан да югары күтәрелә алмый, күтәрелә калса, лаеклы ялны сайларга мәҗбүр калачак. Дәүләт кануннары шундый. Шуның белән бергә, татарларның үзләрендә дә ул кадәр чин-дәрәҗә һәвәсе юк.

– Татарларның хәлләре һәм холык-табигатьләре турында әллә ни белмәсәм дә, офицерларыбыздан ишеткәнем булды: Рус-кытай сугышында да, Рус-япон сугышында да татар сугышчыларының файдалары күп булган. Урыс хәрби отрядларында татар кешеләре сугышчанлыклары белән шөһрәт казанган, сугышта һәрвакыт кыю хәрәкәт иткәннәр. Шулай булгач, бу куәтне, бер вакыты килер дә, үз милләте мәнфәгатендә сарыф итәргә теләсә, кыска гына вакыт эчендә гаять зур уңышларга ирешәчәге шик тудырмый. Билгеле булганча, әсирлек рухи яшәешкә тәэсир итсә, ул милләттән киләчәк өмет ителә алмый. Менә мисал. Тагын да шул ук кытайлар белән булган сугышта Һиндстан гаскәре дә бар икән. Атланган атлары сөлек кебек, коралфәләннәре дә искиткеч, киемнәре яхшы, башларында исең китәрлек чалмалар, тик сугышның кайсы җиреннән генә керсәләр дә, күп дигәндә, ике-өч сәгать кенә каршылык күрсәтә алалар икән. Биш сәгать буе сугышканнары бик сирәк булган, шунда ук чигенәләр икән. Моны безнең сугышчыларыбыз һәм офицерларыбыз алар белән бергә булган вакытларында сынаганнар.

– Әйе, ул яктан татар сугышчысы һәрвакыт өстенлек казанган. Башка сугышларда да күп тапкырлар сыналган. **Татарлар, һичшиксез, табигый яратылышлары белән сугышчан милләт.** Моны беркем дә инкяр итә алмас. Әмма золым күреп бик яньчелгәннәр. Шулай булса да, өметебезне өзмәячәкбез.

– Татарларда уку-язу һәвәсе ничек? Уку һәм язу сәнгате дә олы киләчәк дигән сүз.

– Бу яктан да урыслардан күп тапкырлар өстен торалар. Моннан 20-30 ел элек уку-язу бик арттa калган иде. Әмма бу елларда мәктәпләр саны бик күпкә артты һәм әле дә арта бара. Мәктәбе булмаган авыл бик аз калыр. Урыста исә хөкүмәт ачкан мәктәпләр генә бар, халык тарафыннан ачылган бер генә мәктәп тә юк.

– Бу – күңелгә хуш килә торган, бик матур һәм зур өмет. Безнең Японияда алга китүнең иң беренче чарасы да шул булды. 6 ел мәҗбүри белем канун белән ныгытылгач, шул көннән башлап мәдәният һәм алга баруның нигезләре салынды. Милләтнең акылы да бу нәрсәне аңлап алды, шуннан соң нәтиҗәләре күренә башлады. Ул хәлдә татарлар урысларның җаһиллегеннән файдалана белсәләр, алга китеш булыр. Бигрәк тә Госманлы төрекләре дә тәрәккъый итсәләр, татарлар өчен ныклы арка булырлар. Татарларның тиешле хокукларын саклаганнан соң, Русияне дәвамлы тикшерү, шүрләтү астында тота алырлар. Минем фикеремчә, төрекләр дә күп файда күрерләр, бигрәк тә Балкан мәсьәләсендә уңайлык туар. Урыслар христианлык, славянлык хакына Госманлы хөкүмәтенә даими рәвештә һөҗүм итеп торалар. Без бу мәсьәлә турында үз арабызда гел сөйләшәбез, ләкин хәлнең чын дөресен белми идек. Бары шундый бер фикер килә иде башка: татарларның төрекләр белән бер үк тамырдан булуларын һәм диннәре дә уртак булуын исәпкә алып, бервакыт, кардәше белән кулга-кул тотынышып, мәйдан уртасына чыкмасłармы?

– Һич шик юк, төрекләр белән татарларның бер үк тамырдан, бер үк нәселдән булулары, уртак дин тотулары зур өмет уята. XX гасырда раса мәсьәләсе дә гаять зур мәсьәләгә әйләнде. Шул ук вакытта Көнчыгыш мәсьәләсен дә игъти-

барга алганга күрә, без япон халкының да үзебезгә таяныч була алачакларын өмет итәбез. Ник дигәндә, бу хәлдә, иң мөһим мәсьәлә булып яшәү мәсьәләсе тора һәм ул яктан безнең японнар белән бәйләнешебез булачак. Аурупалылар үз яшәешләрен безнең һәлакәтебездән эзләгән кебек, японнарның да бүгенге яшәешләренең шулай дәвам итеп китүен бик теләмиләр. Менә шул яктан безнең сезнең белән дә берләшә алуыбыз мөмкин булып күренә.

«Рус-кытай сугышында да, Рус-япон сугышында да татар сугышчыларының файдалары күп булган.

– Гомумән дә, бер кавем булуыбыз мотлактыр, мәнфәгатебез һич берләшмәсә дә, үзебез берләшә алырбыз. Бу теләк татарларда булган кадәр японнарда да булачак. Япон кешесе һичвакыт татар кешесен урыс белән бер итеп күрмәс, йөрәгендә аларга карата дәвамлы яратмау, кабул итмәү хисе яшәткән кебек, татарларга карата йөрәгендә мәхәббәт яшәтер. Мин бик күп урыс кешесе белән күрешеп сөйләштем, дәүләт йортыбызга рәсми күрешүгә килгәннәр күп булды. Тик мин аларның берсен генә дә менә бу өемә алып килмәдем. Сезнең белән беренче күрешүдә үк сөйләшүебезнең бу рәвешле самими була алуын рухи бәйләнешебез булганга дип уйлыйм.

Чәйләр эчтек, җиләк-җимешләр ашадык. Хиҗиката җәнаплары болай диде:

– Бакчабызны да күрергә теләсәгез, әйдәгез, бераз бакчада йөрик. Безнең бакчабызның Япониядә тиңе юк. Мин бакчага элек-электән агачларның һәм җимеш куакларының бөтен төрләрен утырттым һәм, ничек бар – шулай калдырдым. Өстәмә карау, тәрбия бирмичә, табигатьнең үз тәрбиясенә тапшырдым. Монда үзгә бер матурлык бар.

Бакчага чыктык, йөрибез. Хиҗиката җәнаплары сүзен дәвам итте:

– Игътибар итегезче, биредә кеше кулы белән матурайтылган бер генә агач та юк. Мин болар белән тәҗрибә үткәрдем: кискечләр, кайчылар белән бирелгән матурлык агачларны озак яшәтми, җимешләрнең табигый тәменә зыян китерә. Табигатькә тыкшынып тәрбия бирүнең тискәре йогынтысы аркасында агачларның гомере дә кыскара. Безнең күршедә финанс министрының бакчасы бар. Бакча караучылар тота, болар бакчаны бик нык тырышып карыйлар, тәрбиялиләр, ләкин җимешләрендә минем бакча җимешләремдә булган кадәр тәм-ләззәт юк. Моҗохито Тенси Сама – табигатьне бик яратучы кеше, мин бәндәгезнең бу өенә кунакка килгәч, бөтен бакчаны карап йөрде. Аннары менә шунда килеп утырды, аның хөрмәтенә, ядкяр дә булсын дип, әнә теге ташны куйдырдым, күрәсезме?!. (Биредә дүрт аршын биеклегендә таш утыртылган иде.) Ул да: «Синең бакчаңдагы матурлык безнең бакчаларыбызда юк», – дигән иде. Бу сүзләрне шул ташка чокып яздырттым. Телисезме, бирегә җиләк-җимеш китерсеннәр, Сез дә биредә бераз ял итеп алыгыз. Моҗохито да менә шушында утырып җиләк-җимеш ашаган иде.

Бик зур горурлык белән шунда утырып, бераз бакча җимешләре ашадым. «Бик күркәм истәлек булды. Фотограф та чакыртыйм әле, безне биредә рәсемгә төшерсен», – дип чакырырга кеше җибәргән иде, ләкин, ни кызганыч, фотограф килә алмады, аннан соңгы вакытларда да җае чыкмады.

Хиҗиката җәнаплары белән күңелгә хуш килә торган шундый күрешеп сөйләшүдән соң, саубуллашып китеп бардым.

*Төрекчәдән* ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

*Мөһаҗирлектәге татар китабы*

# Хәсән Хәмидулла (1960-1986) шигырьләре[1]




**Хәсән Хәмидулла «Тормыш моңнары». Хельсинки, 1971**

## Уян, бәгърем

*(«Уян, татар» көенә)*

Тор син, бәгърем, күзеңне ач,
Уян бу гафләтлекләрдән *(ваемсызлыклардан. – **Х.М.**)*.
Киер канатың, селкен дә,
Уян бу мескенлекләрдән.

Уйла син ул бабаңларны,
Көчле, милекле шаһ-ханларны.
Кайда киткән ник ул заман,
Башла сагнырга анларны.

Эзлә син, ач тарихыңны,
Тапсаң, син анлар кайдалар –

[1] Аларның күпчелеге, нигездә, Хәсән Хәмидулланың «Йөрәк әрнүләре» җыентыгыннан алынды (Хельсинки, 1980. Гарәп һәм латин язуында). – ***Х.М.***

Ерткан дошман, яккан барсын,
Юктыр үз телеңдә анлар.

Дәртең кайда?! Дәрманың да
Бармы синең, татар углы?!
Күрмисеңме, кан-яшь берлән
Бәхетсез милләтең еглый.

Углы син бит – син шул кандан,
Сөяргә мәҗбүр син җандан.
Уйла, эшкә башла, бәгърем,
Котыл әрнүле вөҗдандан.

Ник калдык без бу көлкегә?
Кол булып бетәмез әл дә.
Безнең кебек гафилләр күк
Юкдыр һичбер бүтән бәндә.

## Иркәләнү

Без, димез, хот (хоть. – ***Х.М.***) без дисәк тә, бездә бар ислам дине,
Чатнаган булса да мең төрле золымлардан биле.

Бездә булган әүлиялар, шаһлары һәм ханлары,
Әл дә мәшһүрләр бу көндә – мәңге бетмәс данлары…

Мең түгел, йөз мең дә булган чалмалы шәп муллалар,
Бик күбе язган китап, меңләп түгел, миллион алар.

Бар Тукай, Мәҗид Гафури, Дәрдемәнде һәм башкалар,
Бар Гаяз, Идрис Галимҗан, бар Муса Җаруллалар…

Батталын да әйтми узмыйк һәм Зәки Вәлидине дә, –
Тик бәхетсезләр алар, илсез бәхет юк бернидә.

## Куанычым

Сүәм мин бик татарлыкны, татар булып үлим, Раббым,
Сүгән бер эшне эшләү берлә мин гомремдә тәм таптым.

Күченмәк юк бу фикеремдән, оялмыйм һич татарлыктан,
Үкенмим, сакласын Аллам мине андый начарлыктан.

Көләм мәсхәрәле күз берлән татарлыкны яшергәндән,
Итәм нәфрәт эчем берлән, көләм мин инде ул «мән»дән *(«зат»тан. –* ***Х.М.****).*

Татар булгач, татармын мин, шуңардан бәхтиярмын да,
Көләрмен һәм татар бәхтенә, хәсрәткә җылармын да.

Сүләрмен мин татарча һәм язармын да шигырь әл дә,
Тырышам, күрсәтәм бу тел белән нишләгәнен бәндә.

Үзем мангул, бабам мангул, шуңардан миндә көч күп тә,
Шуңардан бит бабамларга Ходай биргән урын күктә!

## Илгә

Әткәм-әнкәм һәм бабайлар сөйләгән шул тел белән,
Чөнки анлар бик сүгән бергә яшәргә ил белән.

Ул мөкатдәс ил минем һәм ул иде татар иле,
Күпме күрсә дә агырлык[2], чатнамады һич биле.

Шат яшәгәнләр, бу телдән бит алар ямь-тәм табып,
Бу мөбарәк тел эчендән төрле үрнәкләр алып.

Телгә бай һәм сүзгә бай татар иле – бу үз илем,
Чөнки анда күп белем һәм дөньясы тулган гыйлем.

Мин әле (әһле) «бабай» үзем дә – сезгә калсын җәүһәрем,
Сезгә саклап, башкаларга мин бирергә җәлләдем.

## Мөселманнар

Урысы да урыс, татары да – дин тотмаган бар да урыслар,
Динсезлектән дөнья бит бозылды, кайда бакма – анда орышлар.

Динсезләргә бездә, урыс, диләр, динлеләрнең аты – мөселман,
Кайда гына барма, кайда йөрмә – анда мөселманнар кысылган.

Тормыш түгел җиңел мөселманга, хөрлек, берлек киткән кулындан,
Арган бар да, чөнки шайтан һич адаштырмас инде юлындан.

## Нәтиҗә

Язмыйм инде яхшы вә әдәби тел белән,
Чөнки аны кем дә укый белмәгәнен мин беләм.

---

[2] Агырлык – авырлык. – ***Ред.***

**«Яңапар тарихы» Хәсән Хәмидулла хезмәте нигезендә язылган**

Кайвакыт шайтанча язам, кайвакыт мин – әүлия.
Уйлыймын: кемдән дә булса, бәлки, төшәр бер дога.

Төшмәде һичбер берәүдән, каргалып беттем үзем,
Күргәнем саен аларны, бик кызарадыр йөзем.

Каргалып беткән халык без: син дә, мин дә – һәммәбез.
Менми күккә тикле безнең һәм догамыз, тәүбәбез.

* * *

Исемдә әниемнең шад йөзе берлән мине җуатканы,
Сыйпап йомшак кулы берлән минем өчен җан атканы.

Исемдә кыр-болыннар һәм тирән елга, биек таулар,
Кызау, капкын белән кайчак күгәрченнәр идем аулар.

Китә идем чиләк белән җыярга йир җиләкләрне,
Ура идем, билем агыртса[3] да, кыстырып беләкләрне.

Урак берлән кисә идем йә тырнакны, йә учларны,
Ташыйм көлтә өчәрләп, күрсәтим дип миндә көч барны.

*Шигырьләрне журналга филология фәннәре докторы,*
*профессор **Хатыйп Миңнегулов** әзерләде.* ■

[3] Агыртса – авыртса. – ***Ред.***

Безнең мирас №12 декабрь 2020

# Утыз-Имәни һәм «Госман Коръәне»

Рәмил Исламов

**«Госман Коръәне»н Урта Азия мөселманнарына тапшырыр өчен төзелгән комиссия әгъзалары. Сулдан уңга: Шәһер Шәрәф, Кәшшафетдин Тәрҗемани, Габдерахман Гомәри, Габдерахман Гыйсмәти. Уфа, 1923 ел**

## Ш.Мәрҗани: «Утыз-Имәни ертылган кәгазьләрне төзәткән»

Г.Утыз-Имәнинең Сәмәркандта «Госман Коръәне» белән танышуы хакында күренекле дин белгече, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889) үзенең «Китаб мөстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар турында файдалы хәбәрләр») дигән хезмәтенең «Фасыл фи зикер җәмәгать мин мәтаэхри голәмаэ әт-татар вә мин гайре мин лә нәсәбә али Казан ул бәләд Болгар» («Казан һәм Болгар җирләренә нинди дә булса мөнәсәбәте булган яңа татар галимнәренә һәм башка кешеләргә багышланган бүлек») дигән өлешендә болай хәбәр итә: *«Шул исәптән, Габдерәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырыйм әл-Утыз-Имәни, башлангыч белемне Ташкентта алып, Бохарага һәм*

* Ахыры. Башы журналның 11 нче (2020) санында.

*Маварәэннәһер шәһәренә, янә башка җирләргә килеп, Хаҗи Багдадидан соң Мәгакь мәчетендә имам булып, Сәмәркандта Хуҗа Әхрар мәчетендә булган, Сәмәрканд һәм Бохара халкы фикерендә «имам Госман мосхәфе» диелгән мосхәфне төзәтеп, кайбер югалган урыннарын язып, ертылган кәгазьләрне төзәткән...»* Бу хакта аның гарәп телендә язылып, хәзерге көнгә кадәр кульязма хәлендә Казан (Идел буе) федераль университеты карамагындагы Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең Шәрык бүлегендә саклана торган «Вафийәтел-әсляф вә тәхийәтел-әхляф» («Элгәреләр һәм аларның киләчәк буынга сәламе») дигән хезмәтенең 6 нчы томында да әйтелә. Ләкин ул әлеге мәгълүматны кайдан алганлыгын белдерми. Шулай да аның карамагында «Дөррәтел-фахирә»нең ниндидер бер күчермәсе булганлыгын фаразларга мөмкин.

Галим 1844 елда Сәмәркандта «Ширдар» мәдрәсәсендә укыган вакытында Коръәнне тикшерә. Аның бик борынгы, бик кыйммәтле ядкяр икәнен расласа да, хәзрәти Госман шәһит ителгәндә аның алдында булган нөсхә түгеллеген әйтә. Ш.Мәрҗанинең бу хакта язган мәкаләләре 1872 елда Истанбулда нәшер ителгән басмаларда дөнья күрә.

Г.Утыз-Имәнинең шигъри тексты, тикшеренүебез күрсәткәнчә, Р.Фәхреддиннең «Асар»еннән алынып, «Госман Коръәне» хакында кайбер мәгълүмат алга таба Г.Мәгазый тарафыннан «Дин вә мәгыйшәт» журналының 1917 елгы 4 нче санында бастырылган мәкаләдә дә урын ала.

## А.Шебунин: «Ул таплар җуелган»

Сәмәрканд нөсхәсен А.Шебунин тәфсилле һәм әтрафлы анализлый һәм бу хакта «Записки восточного отделения Императорского русского археологического общества» дип аталган журналның 1892 елда нәшер ителгән 6 нчы томында махсус мәкалә бастыра. Ул, Димәшекъта, Мәккәдә, Мәдинәдә, Күфәдә, Басрада саклана торган Коръән нөсхәләре турында алман шәркыятьчесе Теодор Нельдеке (1836-1930) тикшеренүләренә, Берлин һәм Париж тупланмаларында булган Коръәннәрнең тасвирламаларына, факсимилеләренә нигезләнеп, шундый фикергә килә: бу күчермәнең тексты өчен Басра нөсхәсе оригинал булган һәм аның чыгышын Гыйрактан эзләргә кирәк һәм ул VIII гасырга карый.

Шәркыятьче аның бер мәртәбә һәм бер кеше тарафыннан гына төзәтелгән булуы хакында яза. Югалган 69 бит пергаментка охшаш калын, йомшак бер үк кәгазьләргә алмаштырылган. Язу өчен кара да бер үк кулланылуы, язу ысуллары, битләрдәге юл саннарының төрле күләмдә булулары, җибәрелгән хаталар, диакритик билгеләрнең булмавы, сүрәләр бүленеше һәм башка үзенчәлекләр бер кул белән башкарылган. Мосхәфнең 68x53 үлчәме шигырьдә әйтелгән «Олугдыр, катгый тула дүрт карышдин, Дәхи гарза кылыбтыр өч карышдин» дигән сүзләргә тәңгәл килә. Гәрчә Г.Утыз-Имәни битләрдәге юл саннары хакында: «Җәли хаттыр, уникедер сәтырлар», – дип күрсәтсә дә, А.Шебунин аның бары тик 45 битнең ике ягында гына күзәтелүен яза. Мосхәф битләрендәге кан тапларына килгәндә исә, мулла Габделҗәлил һәм мулла Могыйни Мөфтидән язып алган риваять буенча, 300 ел элек Төркестанда аларны күрүчеләр булган. Әмма вакытлар үтү һәм китапны еш файдалану сәбәпле, ул таплар җуелган. Галим хәзерге вакытта төпләмдә булган кызыл төсне китапны төзәткәндә буямадылармы икән дигән шик белдерә.

## Ризаэддин Фәхреддин һәм Михаил Массон фикерләре

Югалган битләр хакында сүз барганда, Р.Фәхреддиннең «Асар»ендә бәян ителгәнчә, аларның кайберләрен Минзәлә өязе Утар авылының Шаһиәхмәт ибне Рәфыйк әс-Симаки (1787-1837) шәкертләреннән берсе Ибраһим исемле мулла 1835 нче елларда Сәмәрканд шәһәрендә суфилык тарикатендә булганда алып кайта. Кайтышлый аларны Эстәрлебаш (хәзерге Башкортстан Республикасында) авылындагы могтәбәр затларга күрсәтә. Моны ишеткән шәех Нигъмәтулла ибне Биктимер (1772-1844) хәзрәтләре болай ди: *«Бу кеби мөбарәк әсәрләре вә вәкыф шәргыйләре (шәригать кануннары) улындыклары йирләреннән алып күчереп йөртмәк яхшы эш дәгел... һәм дә сәламәт хәлендә урынына тапшырып куймак лязем (тиешле)».* Аннары Ибраһим мулла, Эстәрлетамак шәһәренә барып, Габделхаликъ ибне Габделмәҗит исемле сәүдәгәргә үзенең ниятен белдерә. Әмма Шәрәфетдин ибне Зәйнетдин (1761-1846) исемле мәшһүр имам һәм мөдәрриснең бу эшне муафыйк күрмәве сәбәпле, Габделхаликъ андый кара гамәлдән баш тарта. Ләкин байның Рәхмәтулла исемле хезмәтчесе аларны яшерен рәвештә сатып ала һәм бер битне үзендә калдырып, башкаларын Уфада мөфти Габдессәлам ибне Габдерәхим ибне Мөхәммәдкә (1765-1840) акчага бирә. Мөфти хәзрәтләре вафат булгач, Оренбургта яшәгән Гадерәүф исемле улы 1872 елда аларны Казанда сата. Р.Фәхреддин яшәгән вакытларда бу ядкярләрнең Эстәрлетамакта һәм Казанда кемнәр карамагында булганлыгы билгеле була. Галим аларны Петербургтагы асыл нөсхәсе саклана торган китапханәгә тапшырырга чакырса да, ни аяныч, үз вакытында җыйналмый кала.

Р.Фәхреддин хезмәтеннән күренгәнчә, Коръән белгечләренең берсе хафиз Әбү Габид әл-Багдади бу мосхәфнең Госман тарафыннан яздырылган төп нөсхә булмавын әйтә. Ә галим үзе болай дип яза: *«Бу нөсхә хәзрәте Госман мосхәфе улыб-улмаячагы хакында Шебунин җәнаплары муллалар кабиленнән (аңлавыннан) дәгел, бәлки, тәдкыйклар бабы (төгәллек рәвешендә) вә мөстәшрикълар гадәте үзерендә гариз (киң) вә гамикъ (тирән) тәдкыйкларда улыныр...»*

Танылган археолог, шәркыятьче тарихчы Михаил Массон (1897-1986) Үзбәкстанның Кәттә Ләнгәр кышлагында Госманга нисбәт ителгән Коръән барлыгын һәм дәлил өчен «Фәсәйәкфикәһум Аллаһу вәһуас-сәмигъуль-галим» аяте язылган биттә махсус ясалган кан тапларын күрсәтүләрен яза. Әмма текст куфи белән түгел, ә соңрак барлыкка килгән һәм бары тик XIV гасырда гына кулланылышка кергән нәстәгълик язу ысулы белән башкарылган.

## Ленин һәм Сталин: «Выдать немедленно!»

1917 елның 2 декабрендә Петроград милли округы мөселманнарының 1 нче Төбәк съезды (Петроград, Олонец, Архангель, Вологда губерналарыннан һәм Балтыйк буе краеннан 50дән артык делегат) үзенең эшен башлый. Сәүдәгәр һәм керем китерүче йортлар хуҗасы Мөхәммәтгалим Мәкъсутов (1857-?) (рәис), Кәрим Сәгыйдов (1888-1939) (рәис урынбасары), мулла Лотфулла Исхаков (?-1925) (дин бүлеге), мулла Муса Бигиев (1873 яки 1875-1949) (финанс бүлеге), Ф.Хәсәнов (мәдәни-агарту бүлеге) составында Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең Петроград округ бүлеге башкарма комитеты төзелә. Шунда «Госман Коръәне»н мөселманнарга кайтару турында мәсьәлә тикшерелеп, 3 декабрь көнне тиешле Карар кабул итә. Аны үтәү съездның рәисе Әхмәтбәк

Цаликовка (1882-1928), Бөтенроссия мөселман хәрби шурасы рәисе урынбасары Госман Токумбәтовка (1888-?) һәм Милли мәҗлес әгъзасы К.Сәгыйдовка йөкләнә. 1917 елның 1 (14) декабрендә Ә.Цаликов әлеге Карар белән Милләтләр эше буенча Халык комиссариатына мөрәҗәгать итә. Ул вакытта эшнең кая китәргә мөмкин булганлыгын яхшы аңлаган Халык комиссары И.Джугашвили-Сталин һәм Халык комиссарлары Советы Рәисе В.Ульянов (Ленин) мөрәҗәгатькә 6 декабрь көнне: «Выдать немедленно!», – дип язалар.

9 декабрьдә В.Ульянов (Ленин), Мәгариф халык комиссары Анатолий Луначарскийга (1875-1933) 34 нче сан белән теркәлгән рәсми хат юллап, бу мәсьәлә буенча тиешле күрсәтмә әзерләргә куша һәм ул 29 декабрьдә документны имзалый.

«Госман Корьәне»нең аннан соңгы язмышы хакында тарихчы, Үзбәкстан Республикасы Фәннәр академиясе Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре Ринат Шиһабетдиновның тикшеренүләре игътибарга лаеклы. Аның Үзбәкстан Республикасы Үзәк дәүләт архивында саклана торган бу хосустагы документларга нигезләнеп язган хезмәтләреннән күренгәнчә, 1917 елның октябрь азакларында Г.Токумбәтов китапханә җитәкчелегенә мөселман оешмаларының Вакытлы хөкүмәткә Петроград Дәүләт китапханәсендә саклана торган «Госман Корьәне»н сорап мөрәҗәгать итүләре хакында белдерә. Аның белән сөйләшүләр алып бару ул вакытта китапханәнең Шәрык бүлеге мөдире Александр Шмидтка (1871-1939) йөкләнә. Ул, компетентлы оешмалардан күрсәтмә булмыйча, бу ядкярне бирү мөмкин түгеллеген аңлата.

Берникадәр вакыттан соң Г.Токумбәтов тиешле документлар белән янә А.Шмидтка мөрәҗәгать итә. Соңгысы тапшыруның закон нигезендә формаль шартлары үтәлергә, алга таба ядкярнең сакланышы һәм Сәмаркандка тапшырылу ышанычлылыгы булырга тиешлеген белдерә. Аңа барлык тиешле шартлар да үтәләчәге, Изге китап махсус вагонда каравыл сагында Уфага Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтенә озатылачагы һәм Сәмаркандтан мөрәҗәгать булу белән шунда тапшырылачагы аңлатыла.

«

**Тиз арада Китапханә советы киңәшмәсе җыела. Сөйләшүләр киеренке төс ала. Делегацияне озатып килгән хәрбиләр кораллы көч куллану белән яный башлыйлар.**

А.Шмидт, шул вакыттагы вазгыятьне истә тотып, тиешле саклау чаралары булдырып, «Госман Корьәне»н вакытлыча китапханәдә калдырып торырга тәкъдим итә. Г.Токумбәтов, бу фикер белән килешсә дә, озакламый мәсьәләне кичектереп булмаячагын телефон аша хәбәр итә.

1917 елның 29 декабрендә (иске стиль буенча) мөселман сәяси эшлеклеләре һәм хәрбиләре Ә.Цаликов, Г.Токумбәтов, И.Еникеев, сәүдәгәр М.Мәкъсутов, шәһәрнең 4 нче мәхәллә имамы Л.Исхаков Петроградның Дәүләт китапханәсенә килә. Алар А.Луначарский күрсәтмәсе нигезендә китапханә җитәкчесе Эрнест Радловтан (1854-1928) «Госман Корьәне»н бирүне таләп итәләр. Тиз арада Китапханә советы киңәшмәсе җыела. Сөйләшүләр киеренке төс ала. Делегацияне озатып килгән хәрбиләр кораллы көч куллану белән яный башлыйлар. Нәтиҗәдә, ике яктан да катнашучылар имзалаган акт төзелеп, «Госман Корьәне» витринасы белән алына. Ул 1918 елның гыйнварына кадәр Бөтенроссия мөселманнары шурасы Башкарма комитетының бер бүлмәсендә саклана.

## «Госман Коръәне»н Уфадан Ташкентка кайтару

1918 елның 19 гыйнварында Уфада Милли идарә бинасында Бөтенроссия мөселманнары шурасы Башкарма комитеты әгъзасы А.Әхмәтович, Петроград мөселманнары җәмгыяте рәисе М.Мәкъсутов, Мөселман хәрби шурасының Петроград бүлеге рәисе флот генерал-майоры Исхак Ислямов (1865-1929) «Госман Коръәне»н мөфти Галимҗан Баруди (1857-1921) Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте әгъзалары Кәшшаф Тәрҗемани (1877-1943), Салихҗан Урманов, Габдулла Сөләйманов (1886-1937) һәм Мөхлиса Бубига (1869-1937) тапшыралар. Ул аерым бүлмәгә урнаштырыла һәм, илдә барган катлаулы вазгыятьне кичереп, 1923 елга кадәр шунда саклана.

Музейлар һәм борынгы ядкярләрне, сәнгатьне һәм табигатьне саклау эшләре буенча Төркестан комитеты 1922 елның 8 февралендә уздырган киңәшмәдә «Госман Коръәне»н Төркестанга кайтару мәсьәләсе карала һәм бу ядкярне Петроградтан Уфага алып китү хакында инде ул вакытта Ташкенттагы Төркестан Шәрык институты ректоры булган профессор А.Шмидтка тәфсилле мәгълүмат әзерләү йөкләнә. Документ 12 мартка әзерләнә һәм 15 мартта уздырылган чираттагы киңәшмәдә укыла.

Алга таба музейлар һәм борынгы ядкярләрне, сәнгатьне һәм табигатьне саклау эшләре буенча Төркестан комитеты һәм Төркестан АССР Мәгариф Халык комиссариаты җитәкчелеге «Госман Коръәне»н Сәмәркандка кайтару хакындагы мәсьәләне РСФСР Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты каршында берничә тапкыр күтәреп чыга.

1923 елның 10 июнендә Төркестан Үзәк Башкарма комитеты рәисе вазыйфасын вакытлыча башкаручы Нәдирбай Айтаков (1894-1938) Төркестан Совет Социалистик Республикасының РСФСРдагы тулы вәкаләтле вәкиллегенә телеграмма белән «Госман Коръәне»н Уфадан Ташкентка озатуда катнашу, Төркестан Үзәк башкарма комитеты Карары нигезендә, Касыйм Хуҗаев һәм А.Шмидтка йөкләнүен хәбәр итә.

А.Шмидт 5 июльдә Мәскәүгә Төркестан Республикасы вәкиллегенә килгәч, рәис ярдәмчесе Исеев аңа, дин әһелләренең зур канәгатьсезлеге нәтиҗәсендә, Уфага барырга туры килмәячәген белдерә. Ул, хәлне аңлатуны сорап, 10 июльдә Ташкентка телеграмма җибәрә. Н.Айтаков 15 июльдәге җавабында К.Хуҗаевның 12 июльдә юлга чыкканлыгы һәм, Төркестан Үзәк Башкарма комитеты вәкиле буларак, А.Шмидтка аның бу чарада катнашырга тиешлеген хәбәр итә.

К.Хуҗаев килгәннең икенче көнендә А.Шмидтның Уфага бармаячагы тәгаен билгеле була. Әмма ул Төркестан Республикасының югары җитәкче оешмасы тарафыннан бу чарада катнашу өчен бирелгән дерективаны үтәмәскә бернинди дә нигез булмавын аңлаткач, Исеев, Төркестан Үзәк Башкарма комитеты рәисе исеменә юллаган рәсми хат нигезендә, аңа Ташкентка кайтырга формаль юллама бирә.

Музейлар һәм борынгы ядкярләрне, сәнгатьне һәм табигатьне саклау эшләре буенча Төркестан комитеты рәисе Дмитрий Нечкин 1923 елның 10 августында Төркестан Коммунистлар Партиясе Үзәк комитетына язган хатында Төркестан Үзәк Башкарма комитеты Пленумында Исеевның хаталы гамәлләре катгый тәнкыйтьләнгәнлеген хәбәр итә һәм «Госман Коръәне»н «Мәхкәмәи шәргыя»гә тапшыру мөселманнарның дини хисләре көчәеп китүенә, совет

хакимиятенә каршы кузгалышларга нигез булырга мөмкинлеген искәртә.

1923 елның 19 июлендә Төркестан Совет Социалистик Республикасының РСФСРдагы тулы вәкаләтле вәкиллеге, Уфадан Төркестанга кайтарыла торган «Госман Коръәне»н кабул итү комиссиясенә Г.Гыйсмәтуллинны (1883-1938) җибәрүне сорап, Милләтләр эше буенча Халык Комиссариатына мөрәҗәгать итә һәм барлык чыгымнарны күтәрүне үз өстенә алачагын белдерә. Бу документның читенә: «Командировать т. Гисматуллина 27/III. д. №5», – дип язылa.

1923 елның 25 июлендә Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитеты Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтендә саклана торган «Госман Коръәне»н Ташкент шәһәрендәге «Мәхкәмәи шәргыя» йөзендә Төркестан мөселманнарына тапшыру турында Карар кабул итә.

> **«Музейлар һәм борынгы ядкярләрне, сәнгатьне һәм табигатьне саклау эшләре буенча Төркестан комитеты 1922 елның 8 февралендә уздырган киңәшмәсендә «Госман Коръәне»н Төркестанга кайтару мәсьәләсе карала һәм бу ядкярне Петроградтан Уфага алып китү хакында инде ул вакытта Ташкенттагы Төркестан Шәрык институты ректоры булган профессор А.Шмидтка тәфсилле мәгълүмат әзерләү йөкләнә.**

1923 елның 10-21 июнендә Уфа шәһәрендә мөселманнарның 2 нче Бөтенроссия съезды уздырыла. 285 делегат катнашкан әлеге форумда Төркестан мөселманнары вәкилләре: Куканд «Мәхкәмәи шәргыя» рәисе Сәедногман Сәедмәгъсүмхан угылы, әгъзасы – Миян Кодрәтулла хәзрәт Ишанхан угылы, Ташкенттан мөфти Мөхәммәдхуҗа Нархуҗа угылы да була. 14 июнь көнне «Госман Коръәне» турында Р.Фәхреддиннең докладын тыңланыла. Нәтиҗәдә, съезд аны Төркестан мөселманнарына кайтару хакында Карар кабул итә һәм моның барлык рәсми якларын билгели. Изге китапны Ташкентка кадәр озатып бару һәм анда тапшыру өчен комиссиягә Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте ягыннан мөфти Р.Фәхреддин һәм Әстерхан шәһәреннән мөхтәсиб Габдерахман Гомәри (1867-1933) кандидатуралары тәкъдим ителә. Карарның бер нөсхәсе съездда Үзәк хакимият вәкиле сыйфатында катнашкан Г.Гыйсмәтуллинга тапшырыла.

Төркестанның Сырдәрья өлкәсе Мөселманнар эшләре идарәсе делегатлары, «Госман Коръәне»н Уфадан Ташкентка кайтаруны сорап, Үзәк хакимияткә мөрәҗәгать итәләр. Шул заман рухында язылган документта мөселманнарның II Бөтенроссия съезды Карары да искә алына.

Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитетының 1923 елгы 25 июль Карарын гамәлгә ашыру юнәлешендә 1923 елның 30 июлендә Милләтләр эше буенча Халык Комиссариатында «Госман Коръәне»н Уфадан Ташкентка озату хакында киңәшмә уздырыла. Анда Үзәк хакимият ягыннан Густав Клингер (1876-1937) (рәис), Г.Гыйсмәтуллин, Төркестан ягыннан Заһиретдин Касыйм Әгъләм, мөфти Мөхәммәтхуҗа Нархуҗаев, Шәмсетдинхуҗа Хуҗаев («Мәхкәмәи шәргыя» әгъзасы), Солтан Хуҗаев (Төркестан Үзәк Башкарма комитеты әгъзасы), Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте казые К.Тәрҗемани катнаша. Куелган

**«Муи мөбарәк» мәдрәсәсе**

мәсьәләне хәл итү өчен, Р.Фәхреддин (рәис), Г.Гомәри (сәркатип), З.К.Әгъләм (рәис урынбасары), М.Нархуҗаев, Ш.Хуҗаев, С.Хуҗаев, Г.Гыйсмәтуллин составында комиссия төзелә. Изге китапны озату шартлары, тиешле кешеләрнең вазыйфалары билгеләнә, тапшыру-кабул итү актлары тәгаенләнә. Актлар дүрт нөсхәдә язылып, Эчке Россия һәм Сибирия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтенә (Уфа), «Мәхкәмәи шәргыя»гә (Ташкент), Милләтләр эше буенча Халык Комиссариатына (Мәскәү), Петроградтагы Дәүләт китапханәсенә бирелергә тиеш була.

## Изге китап Ташкентта

«Госман Коръәне» 1923 елның 18 августында Ташкент шәһәрендәге Хуҗа Әхрар мәчете бинасында «Мәхкәмәи шәргыя»гә тапшырыла. Габделхәмитнең әтисе Г.Гомәри турында язылган истәлекләре буенча, «Ташкентта рәсми һәм хөрмәтле вазыйфаны үтәгәннән соң, Ризаэддин бине Фәхреддин белән Габдерахман Гомәри хәзрәтләре, Ташкент галимнәренең юлбашчылыгында, Сәмәрканд, Бохара, Куканд һәм Мәргыйлән шәһәрләренә сәфәр итеп, аларның галимнәре, шәехләре белән очрашып, алар белән дини әдәби һәм гыйльми әңгәмәләр үткәреп, атаклы урыннарны һәм хөрмәтле-кадерле каберләрне зиярәт итеп, Урта Азия белән саубуллашып, ватаннарына кайталар».

Тарихчы Булат Солтанбәковның «История Татарстана: Сталин и «татарский след» (1995) дигән китабында, «Госман Коръәне»н Ташкентка озатыр алдыннан алдырылган, тарихчы Сөләйман Рәхимов тарафыннан төзеп нәшер ителгән «Габдерахман Гомәри: Фәнни-биографик җыентык»та (2003) бу эшне башкару өчен төзелгән комиссиянең фотосурәтләрен күрергә мөмкин. Б.Солтанбәков китабында Р.Фәхреддинов кызы Әсма Шәрәф (1906-1993) истәлегеннән күренгәнчә, мөфти хәзрәтләре, Ташкенттан кайтканнан соң, бу вакыйгалар хакында китап язган

булган. Ләкин, ни аяныч, аның вафатыннан соң, башка хезмәтләре белән бергә, әлеге кульъязма да урлана. Г.Гомәринең дә бу хактагы сәяхәтнамәсе булганлыгы турында хәбәрләр бар, ләкин ул әлегә билгесез кала.

«Госман Корьәне» башта Иске шәһәр музеена куела. 1941 елда ул Ташкенттагы Үзбәкстан халыклары тарихы музеена күчерелә. 1989 елның 14-15 мартында Ташкентта уздырылган Урта Азия һәм Казакъстан мөселманнарының IV Корылтаеның ачылышында Үзбәкстан ССР Министрлар Советы рәисе урынбасары Пулат Габдерахманов, Үзбәкстан ССР хөкүмәтенең Карары нигезендә, «Госман Корьәне»н мөфтигә тапшыра. Ул хәзерге вакытта «Хәзрәте Имам» комплексында Үзбәкстан мөселманнарының Диния нәзарәте китапханәсе урнашкан «Муи мөбарәк» мәдрәсәсендә Германиядә эшләнгән махсус пыяла саркофаг-сейфта саклана. «Госман Корьәне» 1997 елда ЮНЕСКО тарафыннан «Дөнья хатирәсе» реестрына кертелә.

Үткән елның 2 сентябрендә мин дә «Госман Корьәне»н зиярәт кылу бәхетенә ия булдым. Аңлы гомеремдә бары тик хәләл гамәлләр генә кылган кулларымны ул саклана торган пыяла савыт өстенә куйдым да, ирексездән кайнар яшьләр ургылып чыккан күзләремне Гарше көрси тарафына юнәлдереп, шушы олуг нигъмәтен насыйп әйләгәне өчен Аллаһы Тәгаләгә мең кәррә тәшәккерләремне әйттем.

## Корьәннең борынгы башка күчермәләре

Шуны да искә төшереп үтү урынлы булыр: хәзерге вакытта гомумән Корьәннең борынгы башка күчермәләре дә билгеле. Мәсәлән, Англиянең Бирмингем университетында саклана торганы VII гасырга карый. Сәнга шәһәрендәге Зур мәчеттә 1972 елда табылган күчермә 7-8 нче йөзләрдә язылган. Төркиядәге Топкапы Сарае музеендагысы VIII гасырда күчерелгән. Шундый ук нөсхәләр Йөрсәлимдә, Димәшекътәге Өммәвиләр мәчетендә бар. 7 яки 8 нче йөзләрдә күчерелгән Корьәннең 46 бите – Санкт-Петербургта, 70 бите – Париждагы Милли китапханәдә, берәр бит Ватикан китапханәсендә һәм Лондонда профессор Хәлил тупланмасында саклана. Тунис Милли китапханәсендәге Корьән (9 нчы йөз ахыры-10 нчы йөз башы) сәнгати яктан зәвыклы эшләнелгән дип исәпләнелә. Текст зәңгәр төсле (индиго) пергаментка алтын һәм көмеш белән язылган. Ул, 7 томнан гыйбарәт булып, 600 бит күләмне тәшкил иткән, ләкин Госманлы империясе вакытында төрле тарафларга таралган.

* * *

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: ничәмә-ничә гасырлар дәвамында төрле вазгыятьләр кичергән бу «Госман Корьәне»нең сакланып калуында татар зыялысы һәм әдибе Г.Утыз-Имәнинең мөкатдәс гамәле дә мөселман дөньясында биниһая тарихи әһәмияткә ия һәм ул мотлакан халыкара яңгыраш алырга тиеш.

*P.S. Мәкаләне әзерләү барышында күрсәткән ярдәмнәре өчен тарихчы галим Ринат Шиһабетдиновка, борынгы әдәбият белгече Нәҗип Нәккашка һәм филология фәннәре кандидаты Раиф Мәрдановка олуг рәхмәтемне белдерәм.* ■

# Дөнья фанатлар белән матур

Эльмира Шәрифуллина







Вакытлы матбугат битләрендә соңгы араларда китап, аны чыгаруда төп җаваплылыкны үз өстенә алган мөхәррирләр, корректорлар, аларның зур хезмәте, әмма укымышлы, үз эшенең остасы булган бу һөнәр ияләренең аз санда калып баруы турында борчылып язган фикерләр очрый. Мәсәлән, «Казан утлары» журналының 2020 елгы 1 нче санында галим һәм язучы Рамил Ханнанов үзенең *«Кызыл кара белән» дигән мәкаләсендә: «Кызыл китап»ка кертелгән редактор һәм корректор һөнәрләре буенча белгечләр әзерләүгә җәмгыять тә, дәүләт тә кул селтәгән заманда...»,* – дип яза һәм бүгенге көндә чын редакторларның ике дистәдән артмавын искәртә. Бу, чынлап та, уйлануны һәм игътибарны сорый торган мәсьәлә. Әдәбият, китап тирәсендә генә түгел, гомумән, кечкенә хезмәт хакына фанатларча эшләү бетеп бара бүген. Берара гаиләсен матди яктан тәэмин итә алмаган мөгаллимнәрне, галимнәр һәм сәнгать әһелләрен базар суырып алды. Хәзер исә иренмәгән күпме артист, җырчы, музыкант, сүз остасы тамада булып тамак туйдыра. Моңа сорау зур. Ул бер байның таң атканчыга


14

Э.Шәрифуллинаның "Мизгел" исемендәге кульяз-
масына редактор фикере

Безнең әдипләребез дөньядан киткәч, алардан соң калуч
якыннары бик сирәк очракта гына истәлекләр белән чыгалар,
әдипнең образын Г.Камал белән Ш.Усманов турындагы истәлекл
не генә беләм. Һәрхәлдә, бүтәннәре истә юк. Менә инде Фаил
Шәфигуллин турындагы язма. Бу истәлек яисә очерк кына түге
Повесть дип аталуына да карамастан, әдипне һәръяклап тас-
вирлаган һәм аның иҗатына мәдхия җырлаган, көйле бер поэма
дәрәҗәсендә килеп чыккан бу әсәр:

"Балалар өчен язылган повестьларындагы илаһилыкка табы
нам. Бу әсәрләрең салмак кына, ләкин ярларын тутырып агучы
елганы хәтерләтә. Елга ага. Аның тирә-юнендә хушыңны алыр-
лык матурлыклар очрый. Чәчәкле үзәннәр, сихри урманнар, те
кә таулар. Ә елга өстендә кояш нурлары уйный".

Автор Фаилнең биографиясен сөйләп чыгу юлын алмаган,
бәлки әнә шул биографик материалга таянып, олы җанлы, җор
күңелле, бай иҗатлы әдипнең гаҗәеп бай, үзенчәлекле образы
гәүдәләндерү юлын сайлаган. Героеның гүзәл якларына саклану
белән бергә, автор әле үзен аның истәлеге алдында бурычлы
саный:

"Билнең осталыгына соклана идең син. Ул бүләк иткән,
агачка яндырып ясалган В.И.Ленин портретын гомер буе кадер
ләп сакладың. Кулыннан гөл коя торган бу иптәшең турында
очерк язарга йөрдең син. Әнә шулай теләгең булып та, үти а
мый калган эшләрең, ничектер, минем естә амәнәт булып калг
дай тоела".

Фаилнең әти-әнисенә, туганнарына, дусларына, сабыйлары
булган мөнәсәбәтен бу чаклы оста һәм тулаем күрсәтү укучы-
лар өчен генә түгел, бәлки исән язучылар өчен дә гыйбрәтле


2

Ә инде әсәр китап булып чыкканнан соң укучыларга, бигрәк тә
яшь буынга ясаячак тәэсире искиткеч зур булачак.

Авторның икенче повесте тулаем тәрбия мәсьәләсенә ба-
гышлана. Анысы да гуманистик фикерләргә нигезләнә! Һәм дөнь
ның җыен чуар вакыйгалары арасында да ару-пакь булып калган
изгелеген саклаган Ана образы олы бер философик, гуманист
зат сыйфатында гәүдәләнә. Бала бидәү, бала багу, аны җәм-
гыятькә файдалы кеше хәленә китереп җиткерү – көннең кадагы
на суга торган, актуаль тема. Бу теманы дидактикасыз-нисез,
һичбер төрле акыл сату ише нәрсә белән мавыкмыйча, кыска
һәм үтемле, шул ук вакытта мавыктыргыч итеп сурәтләп бирә
белү, гомумән, зур осталык сорый.

Повестьлар икесе дә гүзәл әдәби зәвык белән эшләнгән,
сүзнең кадерен белеп, тәҗрибәле кул белән язылган. Бер генә
җирдә дә безнең күпчелек авторларга хас /һәм бу юлларны язу
чы да һич арынып җитә алмаган/ кимчелек –сүз боткасы, күп-
сүзлелек күрмәссең! Автор аз күләмгә сыю ягын караган һәм
морадына ирешкән: нибарысы 6 табак күләмгә дөнья хәтле мате-
риалны, гыйбрәтле хәлләрне сыйдырган. Ә инде тел ягыннан
гүзәллек үрнәге күрсәткән. Финалдагы ачынып әйткән сүзләре
генә дә ни тора бит:

"Әй, кешеләр, тирә-юнегездәге матурлыкның кадерен бе-
легез, тыныч яшәгез, гадел булыгыз!.. Мәгънәсез бер тән яшә-
ве белән гомер үткәрмәгез. Җир йөзендәге бер мизгел гомере-
гезне изге эшләргә, бөек максатларга багышлагыз!"

1984, август К.Миңлебаев

кадәр сузылган бәйрәмен алып барып, редактор яки корректорның ике еллык хезмәт хакын алып кайта лабаса! Әйе, замана үзгәреп тора. Артыннан чабып өлгерә алмыйсың икән, бигайбә: күзеңне чекерәйтеп, аркаңны бөкрәйтеп хәреф чүплә…

Тик шулай да?.. Рухи кыйммәтне матди кыйммәттән өстен куючылар юк түгел һәм дөнья шулар белән матур да. Әлеге кереш сүземдә ике китабымның редакторы – язучы һәм тәрҗемәче Кыям Миңлебаев турында искә алып, аның авторларга никадәр хәерхаһ булуы, кульязма белән эш беткәч тә, алар белән араны өзмәве, игътибарын киметмәве турында әйтеп үтәсем килә.

Беренче тапкыр 1984 елда дөнья күргән «Яңгыр җиле» исемле шигырьләр китабымның мөхәррире булды ул. Икенчесендә 1986 елда басылып чыккан «Мизгел» исемле проза китабымны редакцияләде. Ни шатлык, Кыям абыйның «Мизгел»нең мөхәррире буларак язган бәяләмәсе архивымда саклана. Менә ул:

## Э.Шәрифуллинаның «Мизгел» исемендәге кульязмасына редактор фикере

Безнең әдипләребез дөньядан киткәч, алардан соң калучы якыннары бик сирәк очракта гына истәлекләр белән чыгалар, әдипнең образын мәңгеләштерәләр. Мин шулардан Г.Камал белән Ш.Усманов турындагы истәлекләрне генә беләм. Һәрхәлдә, бүтәннәре истә юк. Менә инде Фаил Шәфигуллин турындагы язма. Бу истәлек яисә очерк кына түгел. Повесть дип аталуына да карамастан, әдипне һәръяклап тасвирлаган һәм аның иҗатына мәдхия җырлаган, көйле бер поэма дәрәҗәсендә килеп чыккан

**Кыям Миңлебаев Бакый Урманче портреты янында**

бу әсәр: *«Балалар өчен язылган повестьларыңдагы илаһилыкка табынам. Бу әсәрләрең салмак кына, ләкин ярларын тутырып агучы елганы хәтерләтә. Елга ага. Аның тирә-юнендә хушыңны алырлык матурлыклар очрый: чәчәкле үзәннәр, сихри урманнар, текә таулар. Ә елга өстендә кояш нурлары уйный».*

Автор Фаилнең биографиясен сөйләп чыгу юлын сайламаган, бәлки, әнә шул биографик материалга таянып, олы җанлы, җор күңелле, бай иҗатлы әдипнең гаҗәеп бай, үзенчәлекле образын гәүдәләндерү юлын сайлаган. Героеның гүзәл якларына соклану белән бергә, автор әле үзен аның истәлеге алдында бурычлы да саный: *«Вилнең осталыгына соклана идең син. Ул бөләк иткән агачка яндырып ясалган В.И.Ленин портретын гомер буе кадерләп сакладың. Кулыннан гөл коя торган бу иптәшең турында очерк язарга йөрдең син. Әнә шулай теләгең булып та, үти алмый калган эшләрең, ничектер, минем өстә әманәт булып калгандай тоела».*

Фаилнең әти-әнисенә, туганнарына, дусларына, сабыйларына булган мөнәсәбәтен бу чаклы оста һәм тулаем күрсәтү укучылар өчен генә түгел, бәлки, исән язучылар өчен дә гыйбрәтле. Ә инде әсәр китап булып басылып чыкканнан соң, укучыларга, бигрәк тә яшь буынга ясаячак тәэсире искиткеч зур булачак.

Авторның икенче повесте тулаем тәрбия мәсьәләсенә багышлана. Анысы да гуманистик фикерләргә нигезләнә! Һәм дөньяның җыен чуар вакыйгалары арасында да ару-пакь булып калган, изгелеген саклаган Ана образы олы бер философик, гуманист зат сыйфатында гәүдәләнә. Бала биләү, бала багу, аны җәмгыятькә файдалы кеше хәленә китереп җиткерү – көннең кадагына суга торган актуаль тема. Бу теманы дидактикасыз-нисез, һичбер акыл сату белән мавыкмыйча, кыска һәм үтемле, шул ук вакытта мавыктыргыч итеп сурәтләп бирә белү, гомумән, зур осталык сорый.




Повестьлар икесе дә гүзәл әдәби зәвык белән эшләнгән, сүзнең кадерен белеп, тәҗрибәле кул белән язылган. Бер генә җирдә дә (безнең күпчелек авторларга хас (һәм бу юлларны язучы да һич арынып җитә алмаган)) кимчелек – сүз боткасы, күпсүзлелек күрмәссең! Автор аз күләмгә сыю ягын караган һәм морадына ирешкән: нибары 6 табак күләмгә дөнья хәтле материалны, гыйбрәтле хәлләрне сыйдырган. Ә инде тел ягыннан гүзәллек үрнәге күрсәткән. Финалдагы ачынып әйткән сүзләре генә дә ни тора бит: *«Әй, кешеләр, тирә-юнегездәге матурлыкның кадерен белегез, тыныч яшәгез, гадел булыгыз!.. Мәгънәсез бер тән яшәве белән гомер үткәрмәгез. Җир йөзендәге бер мизгел гомерегезне изге эшләргә, бөек максатларга багышлагыз!»*

Кыям Миңлебаев, 1984, август.
(Имза).

Язмадан күренгәнчә, редактор: «Бер генә җирдә дә безнең күпчелек авторларга хас (һәм бу юлларны язучы да һич арынып җитә алмаган) кимчелек – сүз боткасы, күпсүзлелек күрмәссең!», – дип, үзен тәнкыйтьләп алудан да курыкмаган.

Алда, Кыяметдин Сәлахетдин улы Миңлебаевның, кулъязма белән эш беткәч тә, авторларына игътибарын киметмәве турында әйткән идем. Бу, дөрестән дә, шулай. Биографиясенә күз салсаң, искиткеч эшчән, тыгыз иҗади тормыш алып барган ул: күпсанлы рус, чит ил классикларының күләмле әсәрләрен тәрҗемә иткән; сынлы сәнгать, рәсем сәнгате әһелләренең иҗат портретларын язган, альбомнарын төзеп чыгарган; ике зур роман язып тәмамлаган; Казан дәүләт университетында мөгаллимлек иткән, әллә никадәр җәмәгать эшләре алып барган һ.б., һ.б. Шул ук вакытта бүгенге язучыларның яңа язган әсәрләрен дә даими укып, күзәтеп бара икән. Очраганда, кайда укуын әйтеп, яхшы бәясен бирә, шатландыра. Болар, билгеле, барысы да Әдип дигән олуг затның әнә шулай мәгънәле, киң күңелле, югары эчке әдәпкә ия булырга тиешлегенә тере мисал иде.

Аның шушы игътибарын сизеп, 1988 елда басылган чираттагы «Гөлләр елы» исемле шигырь китабымны бүләк иттем һәм каләм тотып карап чыгуын үтендем. Кыям абый каршы килмәде, озакка да сузмады. Бик игътибар белән укып, тамгаларын куеп, фикерләрен язып, китапны кире кайтарды. Ул куйган плюслар һәм минуслар, күреп бетерелмәгән тыныш билгеләре, шигырь янына язылган тәнкыйть яки мактау сүзләре, алдагы китапларымны төзегәндә таләпчәнлегемне арттыру, «укучы менә ничек укый икән бит китапны», дип нәтиҗә ясау өчен миңа зур дәрес булды.

Җырларны өч автор – шагыйрь, композитор, башкаручы тандемы, диләр. Хатасыз, рәссамын дөрес сайлап чыгарылган яхшы китап та, нигездә, өч кеше – язучы, редактор, корректор җимеше икән ләбаса. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2020

# КАРА ТӘКЪДИР

*(Ачы язмышлы шәхесләр)*

## БАСЫЙРОВ КӘШФИ (1906-1943)

Татар язучысы. Бәләбәй төбәгенең Мәтәүбаш авылында туган.

Кәшфи Басыйров фашист илбасарларына каршы сугышта һәлак була.

## БАТЫРОВ ОСМАН (1910-1942)

Кырымтатар журналисты.

Фашистлар Кырымны басып алгач, Осман Батыровны яшерен оешмада калдыралар.

Гестапо яшерен оешманың эзенә төшә. Нәтиҗәдә, Осман Батыровны кулга алалар һәм, каты җәзалаганнан соң, атып үтерәләр. Совет илен дошманнардан яклап сугышканда һәлак булган каһарманның гаиләсен Ватаныннан куалар.

---

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

## БАТТАЛ САЛИХ (1905-1995)

Татар әдибе. Казан губернасының Спас өязендәге Зур Тигәнәле авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туган.

Хәрби очучы-сынаучы. Аны «Батый ханга ачык хат» исемле поэмасы өчен партиядән чыгаралар.

Салих Баттал, ялгыз яшәгәндә өендә янгын чыгып, шунда һәлак булды.

## БАЯН НУР (1905-1945)

Татар шагыйре. Актаныш төбәгенең Әнәк авылында крестьян гаиләсендә туган. Подполковник.

Шагыйрь Нур Баян Җиңү көненә нибары унбиш көн кала һәлак була.

**БЕКПАСОВ РӘҮФ (1924-?)**

Татар язучысы, татар һәм уйгыр телләре белгече, тарихчы. Чүгүчәк шәһәрендә татар укытучылары гаиләсендә туган. Хәрби һөнәр алган, ул Шәркый Төркестан Республикасы гаскәренең капитаны була.

Кытай армиясе Колҗага кергәч, аны кулга алалар һәм штрафной батальонга җибәрәләр. Рәүф, көч-хәл белән исән калып, Казакъстанга качып китә.

**БЕГАНСКИЙ ИЗМАИЛ (1894-1938)**

ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары. Виленский губернасының Свентянский өязендәге Дәвгелишки авылында татар гаиләсендә туган.

Измаилны, «Партиягә каршы төркем оештыручы» дигән яла ягып, кулга алалар. Тоткынлыкта һәлак ителә.

**БОДАНИНСКИЙ УСЕЙН (1877-1938)**

Рәссам, тарихчы, этнограф, археолог. Кырымда, Акмәчет (Симферополь) тирәсендәге Бадана саласында сәнгать әһеле Абдерәфи гаиләсендә туган.

1938 елда, милләтчелектә гаепләнеп, Совет төрмәсендә атып үтерелә.

**БИГИЕВ ЗАҺИР (1870-1902)**

Татар язучысы. Ростов-Дон шәһәренең ахуны Ярулла Бигиев гаиләсендә туган.

Ул сәер шартларда һәлак була. Үлеме турында төрле фаразлар бар. Шуларның берсе: ул кара-грухчылар тарафыннан үтерелгән.

**БИГИЕВ МУСА (1875-1949)**

Дин галиме. Ростов-Дон шәһәренең ахуны Ярулла Бигиев гаиләсендә туган.

Ул, хакимият тарафыннан эзәрлекләнеп, чит илгә качарга мәҗбүр була. Әмма алты баласы белән хатыны Русиядә кала. Гаиләсе белән бер күрешергә зарынтизар булып, чит илдә вафат була. Кабере Каһирә зиратында.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

# Истә, һаман да истә!

**Композитор Салих Сәйдәшевнең тууына 120 ел**



Мәшһүр композитор, дирижер, пианист, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1939), ТАССРның халык артисты (1951) Салих Җамалетдин улы Сәйдәшев 1900 елның 3 декабрендә Казанда туган.

Башлангыч музыкаль белемне ул музыкант Заһид Яруллиннан ала.

1922-1948 нче елларда (бүленеп) Татар академия театрында музыка бүлеге мөдире һәм дирижеры булып эшли. 1929 елда исә Кызыл Армиянең 11 еллыгына багышланган һәм соңыннан киң танылу алган «Совет Армиясе маршы»н яза.

Композиторның соңгы әсәре – М.Җәлил шигыренә язылган «Җырларым» җыры.

С.Сәйдәшев 1954 елның 16 декабрендә вафат булды.

**Шагыйрь Хәсән Туфанның тууына 120 ел**

Татар әдәбиятының классигы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1966), 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Хәсән Фәхри улы Туфан (Гөлзизин, Хәзрәтов, Кусинов) 1900 елның 27 ноябрендә (яңа стиль белән – 9 декабрьдә) Чистай өязенең Аксубай волостендагы (хәзерге Аксубай районы) Иске Кармәт авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә сигезенче бала булып туган.

1914 елда Хәсән, бертуган абыйлары фатихасы белән, Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә һәм анда, Ш.Бабич һәм С.Кудаш белән бергә, Галимҗан Ибраһимовтан дәресләр ала.

1924 елда Х.Туфан Казанга килә. Башта ул Бишбалта бистәсендә балалар укыта, аннары «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә һәм радиокомитетта эшли. Шагыйрь биредә Һади Такташ, Гадел Кутуй, Муса Җәлил, Галимҗан Нигъмәти кебек шәхесләр белән дуслаша, үзенең мәхәббәтен – актриса Луиза (Гайникамал) Салиәсгарованы очрата һәм аңа өйләнә.

Ил күләмендә барган репрессияләр афәте Х.Туфанны да читләтеп үтми. 1940 елның 18 ноябрендә аны кулга алалар һәм Казан төрмәсенә ябалар. Башта ул атарга хөкем ителә, соңыннан исә бу карарны ун ел төрмә белән алыштыралар. 1950 елда, иреккә чыгарга вакыты җитеп килгәндә, аны гомерлек сөргенгә җибәрәләр.

Х.Туфан 1956 елның җәендә Казанга кайта һәм гомеренең ахырына кадәр шунда яши.

Шагыйрь 1981 елның 10 июнендә Казанда вафат булды.

Безнен мирас №12 декабрь 2020

**Җырчы Фәридә Кудашеваның тууына 100 ел**

РСФСРның атказанган (1972), БАССРның (1968) һәм Татарстанның халык артисткасы (1990), ТРның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1996), мәшһүр җырчы Фәридә Яһүд кызы Кудашева 1920 елның 15 декабрендә Башкортстанның Чишмә районындагы Келәш авылында (шагыйрь Мостай Кәрим дә шушы авыл тумасы) дөньяга килгән.

Беренче сыйныфта укыганда ул «Салкын чишмә» дигән җырны башкара. 1947-1956 нчы елларда Башкортстан радиосында эшләгәндә, аның даны еракларга тарала.

1956 елда Ф.Кудашева Башкорт дәүләт филармониясендә эшли башлый, ире – композитор һәм музыкант Бәхти Гайсин белән бергә бик күп җырлар иҗат итә.

Ф.Кудашева 2010 елның 9 октябрендә Уфада вафат булды һәм Мөселман зиратында җирләнде.

---

**Шагыйрә Роза Кожевникованың тууына 70 ел**

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1995), М.Горький исемендәге әдәби премия иясе (2003), шагыйрә һәм тәрҗемәче, 1984 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Роза Хәби кызы Кожевникова (Баубекова) 1950 елның 19 декабрендә Әстерхан өлкәсенең Красноярск районындагы Дельта станциясендә эшче гаиләсендә туган.

Ул 1969-1971 нче елларда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый, 1972-1977 нче елларда исә Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институтының тәрҗемәчеләр бүлегендә белем ала. Х.Туфан, С.Хәким, И.Юзеев, Р.Харис, Ә.Баянов, М.Әгъләм, М.Галиев кебек күренекле шагыйрьләребезнең байтак шигъри әсәрләре аның тәрҗемәсендә дөнья күрде.

Р.Кожевникова 2007 елның декабрендә Казанда вафат булды.

---

**Язучы Хөсәен Вәлиәхмәтовның тууына 70 ел**



Язучы һәм журналист, 2005 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Хөсәен Хәсән улы Вәлиәхмәтов 1950 елның 22 декабрендә Татарстанның Әлмәт шәһәрендә туган.

Вәлиәхмәтовлар гаиләсе 1956 елда Татарстанның Аксубай районындагы Иске Кыязлы авылына күчеп кайта.

1968-1973 нче елларда Х.Вәлиәхмәтов Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый. 2003 елда исә ул Казан дәүләт университетында кандидатлык диссертациясе яклый һәм шуннан бирле Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында психология фәнен татарча укыта.

Х.Вәлиәхмәтов 2020 елның 27 гыйнварында вафат булды һәм аның җәсәде Самосырово бистәсендәге мөселман зиратында җирләнде. ■

*Сәхифәне* ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.*

Безнең мирас №12 декабрь 2020

# Хәтер

Раил Садриев

**Татарстанның халык артисты Раил Садриев И.Вырыпаев пьесасы буенча куелган «Иранская конференция» спектакль-манифестында (режиссер – Егор Чернышов)**

Толымбай. Төнге 00.00. сәгать. 17 ноябрь башланып килә. Дустым Ләбиб Лерон табадан әле генә төшкән шигырен җибәргән. Ул Хәтер, киткән әдипләр турында:

*Һәрбер остаз – гүя мәгарә ул,*
*Һәр чын шагыйрь – мәңге янартау.*
*Остазларны – шагыйрь абыйларны*
*Хәтеремдә кабат яңартам...*

Гаилә Хәтере, буыннар Хәтере, милли Хәтер, ил Хәтере... Хәтер бүленешен барлый башласаң, йөзгә якын килеп чыга. Һәм шулар барысы да бер кеше гомеренә сыя. Аларның кайберсе күңелгә уела, икенчеләре, еллар үтү белән, югала... Ә кемдер аны яңарту өстендә эшли, өсти – яңа мәгълүматлар эзли һәм таба.

Милләт Хәтере... Безнең татарның милли Хәтере үзе яши торган илнең Хәтер «китабы»нда капма-каршы урын алып тора. Чөнки бүген яши торган Ватаныбыз Русия Хәтерендә безнең дәүләт буларак уелып калган милләт Хәтере дә саклана. Тарихны күпме генә төгәл дип әйтсәк тә, ул төгәл була алмый. Бүген дә ниндидер дәүләтләр, милләтләр җир йөзеннән юкка чыга. Әмма болар барысы да Җир-Ана Хәтерендә, ИЛАҺИ Хәтердә сакланып кала.

Хакыйкатьтә Ходай тарафыннан бирелгән Галәмнәр, Җиһаннар Хәтере булган зур бер «сандык» бар. Һиндлар аны «АКАШИ Хәтере» (Память АКАШИ) диләр. Кешелек дөньясы чираттагы ачышын ясаганда, үзе дә аңламастан, шушы Хәтергә таяна, аның мәгълүмат кырына керә.

Без бүген глобаль кризис алдында торабыз. Ул Хәтерне йә яңарта, йә юкка чыгара… Чөнки без аңламаган, бәяләп бетерә алмаган чор килде. Моңа безне мәктәпләрдә, югары уку йортларында өйрәтмәделәр. Дөрес, безгә совет чорында Карл Маркс тәгълиматы аша иҗтимагый формацияләр алмашыну турында күпмедер мәгълүмат бирделәр. Бүгенге кризис Маркс әйткән капитализм формациясенең бетүен искәртә. Киләчәктә аның урынына нинди формация килер – анысы билгесез…

Зур югалтулар һәм табышлар алдында торабыз. Шулай булгач, бүгенге беркем дә аңламый торган чорда безнең Хәтер, кешелек дөньясының Хәтере нинди булырга тиеш?!. Хәзерге вакытта исән калу, киләчәккә дөрес юллама алу, аны яңа буыннарга тапшыру өчен, кешегә нәрсәгә басым ясарга һәм ИЛАҺИ Хәтердән нәрсәләрне тартып чыгарырга кирәк?

Милләт буларак, без бүген югалып барабыз, чөнки безнең Хәтеребез уалды, чуалды. Хәтер «сандыгы»нда эзләнә башласаң, күз алдына – милләт, милләтне уйлый башласаң, кешелек дөньясының киләчәге килеп баса…

Татар милләте бүген бер ягында – кыя, икенче ягында упкын булган урында инде нишләргә икән, дип шаккатып басып торучы кешене хәтерләтә. Аңа тиз генә Хәтер «китабы»н яңартырга туры киләчәк. Ә Хәтер «китабы»ның ачкычы ул – аның туган теле, шул телдә фикер йөртү, уйлау.

УЙ – Галәмдәге, Җиһандагы иң көчле коралларның берсе. Мин, син, без бертөрле уйлыйбыз икән, ул дөньяга аны яшәтер, җылытыр, үзгәртер өчен гаҗәеп куәткә ия импульслар җибәрәчәк. Ә безне бер кеше бернәрсәне дә үзгәртә алмый дип өйрәттеләр. Бу каршылыклы теориядән котылып, кешелек дөньясын коткарып калырлык һәм аны позитив якка үзгәртә алырлык УЙлар белән коралланырга кирәк. Шулай булгач, кеше УЙ-фикере белән бөтен дөньяны үзгәртә ала! УЙ корал булса, Хәтер – аның патроннары. Ул коралга нинди патрон куясың, барысы да шуннан тора.

Хәтер бүген корал – яшәеш коралы булырга тиеш: дөрес диагноз кую, исән калу, алга бару өчен… Безгә Хәтер киштәләре булдырып, һәркайсын тиешле урынга урнаштырып, УЙларны тәртипкә салып, шуларга таянып, дөрес юнәлештә хәрәкәт итәргә кирәк. Кичекмәстән!

Ә Хәтер безгә нәрсәгә кирәк? Барысын да барлап, халкыбыз, илебез, гомумән, кешелек дөньясы нигә мондый аяныч хәлгә калган, бу афәттән чыгу юлы бармы – менә шулар турында уйланыр өчен кирәк.

Без бүген зур омтылышлар, зур каршылыклар алдында торабыз. Шул ук вакытта зур перспективалар да ачыла кебек. Бөтен нәрсә безнең дөрес уйлавыбыздан тора. Ә дөрес уйлау ул Хәтергә корылган.

Бу уңайдан күңелдә Марсель Галиевның шигъри юллары яңара:

*Табарлар безнең эзләрне,*
*Әйтерләр хәйран калып:*
*«Үзе тудырган еланнан*
*Чагылып үлгән халык!»*

М.Галиевның бу шигъри юллары киләчәк буыннар Хәтерендә милләтебез язмышы өчен хакыйкать булып яңгырамасын иде!.. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2020

*Салих Сәйдәшевнең тууына 120 ел*

# Аны яраталар иде...

**Нәүфәл Сәйдәшев**

**Салих Сәйдәшев. 1912 ел**

**С.Сәйдәшев Татар драма театрында эшләвенең беренче елларында**

Балачактан ук күңелдә уелып калган: әтием янында һәрвакыт кешеләр булыр иде. Ул вакытта: «Кайчан ял итә икән ул?» – дип уйлый идем.

Бөек Ватан сугышы елларында аның янына килүчеләр бигрәк тә күбәйде. Кыска гына вакытка туган якларына – Татарстанга кайткан фронтовиклар әти янына еш килеп чыгалар иде.

Елын төгәлен генә искә төшерә алмыйм, ләкин Бөек Ватан сугышы чорында икәне хәтеремдә: безгә данлы генералларның берсе килеп керде. Минемчә, ул генерал Якуб Чанышев иде. Алар бик озак утырдылар. Әтием төн буе пианинода уйнады. Ул чак яшәү авыр иде, ашау-эчү ифрат кысынкы. Генералның әтигә чиксез ихтирамы, вакыты аз булуга карамастан, хәл-әхвәлен белергә керүе безнең күңелне күтәреп җибәрде. Әти иҗатын дәвам итсен өчен, ул генерал кемнәр беләндер сөйләшкән, ахрысы: безгә матди ярдәм күрсәтә башладылар. Ярдәм сизелерлек иде.

Мин, 11-12 яшьлек малай, бернәрсәне яхшы аңладым: әтиемә халыкның ихтирамы чиксез зур икән! Дворникмы яки сугыш кырыннан ашыгыч кына кайткан генералмы, солдатмы – барысы да әтигә ярдәм күрсәтергә әзер, барысы да әтине якын-үз итә.



С.Сәйдәшев «Ил» драмасына музыка язган көннәрендә

С.Сәйдәшев. 1951 ел

Әтинең дуслары чиксез күп. Аның бервакытта да шәхси дошманнары булмады – бу нәтиҗәгә дә мин үсмер чакта килдем. Әти олы җанлы, сабыр кеше. Ул һәркемгә якты йөзле. Пөхтә киенә, вакытында кырына, чисталыкны ярата – кыскасы, матур кыяфәтле, саф күңелле кеше. Сүзгә бик оста иде. Төрле кызыклы вакыйгаларны, мәзәк хәлләрне мавыктыргыч итеп сөйли белә. Аны тыңлаучылар рәхәтләнеп, туктый алмый көләләр иде.

Гаилә тормышыбыздан кайбер детальләр әле дә күз алдында. «Нигә радионы туктаттыгыз әле? Радио һәрвакыт гөрләп торсын. Тыңлагыз: ул һәрвакыт дөресне сөйли. Радио – тормыш маягы», – ди иде әти.

Әти бик иртә тора. Мин әле тормыйм. Яткан җиремнән аны күзәтәм. Менә ул тәрәзә янына килә. Ә тәрәзәбез алдында зур-зур агачлар. Яфраклары куе. Агачларга килеп кунган кошларны әти игътибар белән күзәтә, ә үзе, акрын гына сызгырып, ниндидер көй көйли.

Чәйгә утырабыз. Суда пешкән бәрәңгене әти бик тәмләп ашый. Пәрәмәч ярата, алма бәлеше белән чәй эчү аның өчен бәйрәм була иде.

...Сугышка кадәр җәен без Идел буенда – Кызыл Байрак поселогында ял итә идек. Җәй башыннан алып көзгә кадәр Кызыл Байракта торабыз. Әти безнең янга һәр якшәмбе килә. Аның килүе безнең өчен зур куаныч.

Әти балык тотарга бик ярата иде. Яр буеннан алып Идел уртасына кадәр дамба булып сузылган комлык бар иде. Әти безне шул комлыкның аргы башына – Идел уртасына кадәр алып бара. Әйләнә-тирәбездә – тирән су. Тик, яны-

«Гаилә тормышыбыздан кайбер детальләр әле дә күз алдында. «Нигә радионы туктаттыгыз әле? Радио һәрвакыт гөрләп торсын. Тыңлагыз: ул һәрвакыт дөресне сөйли. Радио – тормыш маягы», – ди иде әти.

бызда әти булгач, тирән судан курыкмыйбыз.

Әти бик яхшы йөзә иде. Ул мине аркасына атландыра да әллә кайларга кадәр алып кереп китә. Яр буеннан безне карап торган әнием әтине ачулана… Болай күңелле су коенулар элеккеге Маркиз утравында да була иде.

Яныбыздан гына ап-ак пароходлар узып китә. Палубаларда кешеләр күп. Без аларны кул болгап озатабыз. Алар да безне сәламлиләр, кул болгыйлар. Музыка яңгырый. Ул пароходларның исемнәре әле дә хәтердә: «Урицкий», «Жданов», «Буй», «Механик». Ә бервакыт шулай «Механик» пароходы, туктап, безне үзенә алды да Шеланга пристанена кадәр илтте. Ул пароходның капитаны әтинең дусты икән. Шундый зур, матур пароходның палубасында бару безгә бик ошады, шатлыгыбызның чиге юк иде.

С. Сәйдәшев улы Нәүфәлне армиягә озатканда. Казан, 1954

Салих Сәйдәшев хөрмәтенә пароход кадәр пароходның кечкенә генә пристаньга туктавы үзе бер вакыйга булды…

…Аерата хәтердә нык сакланган көн – сугышның беренче көне.

Мин Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры парадные алдында баскычта утырып торам. (Сүз җае белән әйтеп үтим, безнең квартира шул театрның ишек алдындагы ике катлы йортта иде. Без, балалар, һәрвакыт театр алдында уйный идек.) Әти белән артист Хәким Сәлимҗанов минем янымда басып торалар. Хәким абыйлар да безнең йортта яши. Әти бер кулы белән минем чәчләремне сыйпый. Үзләре кырыс, уйчан, бик җитди сөйләшәләр. Сүз фашистларның безнең илгә хыянәтчел һөҗүме турында иде. Сөйләшүләренең эчтәлеген бәйнә-бәйнә әйтеп бирә алмыйм. Тик әтинең бик катгый итеп: «Без аларның кирәкләрен бирербез әле!» – дигән сүзләре күңелгә кереп калган.

…1954 ел. Мин, Совет Армиясе солдаты, Казанга ялга кайткан идем. Әти белән очрашырга сүз куештык. Әнием Сафия белән бергәләп әти фатирына бардык. Онытылмаслык күңелле күрешү булды. Әтинең кәефе яхшы. Шундый җылы, ягымлы, эчкерсез сөйләшү. Әйтерсең, әти белән әни арасында бернинди дә күңелсезлек, бернинди дә низаг булмаган. Әни белән икебезне пианино янына якын гына утыртты да: «Тыңлагыз, мин сезгә әле һичкем ишетмәгән көйләремне уйныйм», – диде. Ул бер-бер артлы берничә көй уйнады. Уйнаганда үзе безгә сынап-сынап карый, күзләрендә – елмаю. Ул елмаюлы карашны мин һич онытмам. «Йә, ничек, ошыймы сезгә?» – дип сорый ул. Әни белән без соклануыбыздан сүз әйтә алмыйбыз. Әлеге очрашуда тыңлаган ул көйләрне без соңыннан берәүдән дә ишетмәдек. Ул көйләр әти белән бергә киткәннәр, ахры. Искиткеч матур көйләр иде.

Берничә көннән соң әти мине Читага, хәрби частема озатты. Ирек мәйданына кадәр бергә килдек, саубуллаштык. Мин трамвайга утырдым. Әти ак кулъяулыгын, кесәсеннән чыгарып, миңа болгый. Күзләрендә яшь күрәм. Үзе елмая. Мәрхәмәтле елмаю, нурлы елмаю. Бу безнең соңгы күрешүебез һәм соңгы саубуллашуыбыз булды… ■



**Равил Фәйзуллин**

# Сәйдәш

*(Поэмадан өзек)*

*Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә*
*Һәм үләргә кыю ир булып!*
***Муса Җәлил***

Халыкларның җаны ул – җыр, диләр.
Җыр, диләр дә, бездә – моң, диләр.
Телгәләсә, киссә бәгырьләрне,
татар җыры инде – шул, диләр.
Моңда баскан, изгән, тугланган... Юк,
безнең җырлар – киңрәк, тирәнрәк!
Ничек тоташ хәсрәттән торсын
хезмәт дәрте тулы бу йөрәк!
Җиң сызганып эшли белгәннәрдә
күпме куәт, күпме ярсу бар!
Каннар кайный икән, димәк, бездә
Мәхәббәт бар, сөю, ачу бар!
Сәйдәш иҗатыннан, эзләсәң дә,
таба алмассың көйләр бер көнлек.
Халык рухы кебек сәламәт ул,
юк аларда шыңшу, мескенлек.
Яшәү тантанасын, хезмәт дәртен,
күңелләрнең җилкенүләрен
әйтә, раслый һәрбер аккордында
фани дөньяның бар ямен.
Чалгычылар чалгы янаганда,
шахтер егет күмер чапканда,
монтер егет утлар кабызганда,
кызлар өмәләрдә чакларда –
без һәммәбез алар белән бергә,
бер адымда, бер үк сулышта.
Кешеләр белән берлегегеңне тою –
үзе бер бәхет бит тормышта!

Җыр язмышы – халык язмышы ул,
ил язмышы белән беррәттән.
Ил яулаган һәрбер үр-биеклек
көйләр, җырлар белән береккән.
Илне яңа сафка бастырганда,
ашкынулы бишьеллыкларда,
күмәк хуҗалыклар төзегәндә,
Днепрогэс, Магниткаларда
Сәйдәш тә бар, төзүчеләр,
коручылар белән бер индә.
Зур сәнгатьнең, масса сәнгатьнең
өлеше бар һәрбер җиңүдә!
Сәйдәш рухы йөрде фронтларда,
окопларда, алгы сызыкта.
Туплар булып яңгырады «Марш»
фашизмга каршы, коллыкка!
Шифа-өмет булып кунды Сәйдәш
әсирләрнең туңган җанына.
Җиңү булып, яшьнәп керде Сәйдәш
Бранденбург капкаларыннан!
Сәйдәш – җыя бергә, туплый, әйди,
йокымсыраганны да кузгата.
Якты рух өсти ул. Кешелекле
тавыш-аһәңнәрне уята.
Эчке тоем белән рухка үтү –
Сәйдәш талантының иркендә.
Җырлары аның – шәхси үзенеке дә,
шул вакытта – һәркемнеке дә! ■

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

# Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

## *Филармониядә узучы фестивальләр һәм конкурслар*

**Иосиф Кобзон «Филармониада» фестивалендә**

**Роберт Юлдашев һәм «Курайсы» төркеме «Филармониада» фестивалендә**

### «Филармониада» халыкара сәнгать фестивале

Фестиваль 2008 елда барлыкка килде. Аны уздырырга Татарстанның 2013 елгы Универсиаданы Казанда үткәрү хокукын яулап алуы этәргеч булды. Чараның максаты – югары сәнгатьне, дөньякүләм танылган иҗатчылар белән берлектә, киңрәк тарату, яңа исемнәр ачу. Фестиваль программасы сәхнә сәнгатенең төрле жанрларыннан туплана: классика, фольклор, эстрада, джаз, рок, нәфис сүз, бию, балет, кино…

### Халык уен кораллары ансамбльләре һәм оркестрларының «Халык көйләре» Бөтенроссия фестивале

Ул беренче тапкыр 2015 елда оештырылды. Рус мәдәнияте һәм Россия фольклоры бәйрәменә башлангыч бирүче –Татарстан Республикасы халык уен кораллары дәүләт оркестры җитәкчесе, Россиянең халык артисты, профессор Анатолий Шутиков. Халык уен кораллары оркестры чирек гасыр дәвамында Россиянең әйдәп баручы коллективларының берсе булып тора. Оркестр елдан-ел яңа үрләр яулый, аның концертларын Татарстан һәм Россия шәһәрләрендә меңнәрчә музыка сөючеләр алкышлады. Ул Австрия, Германия, Голландия, Көньяк Корея, Италия, Болгария, Португалия концерт залларында да уңыш казанды. Фестивальнең Казанда үтүе бик отышлы: башкалабыз музыкаль коллективларны җәлеп итү, халык сәнгатен һәм халык уен коралларында уйнауны пропагандалау үзәгенә әйләнде. Бөтенроссия фестиваленең башлангычы шушы исем белән аталган халык уен кораллары ансамбльләре һәм оркестрларының конкурсына барып тоташа. Фестивальдә Людмила Зыкина исемендәге «Россия» ансамбле, Анатолий Квасов исемендәге «Дон

**Кадим Нуруллин «Бард-Арт» фестивален ачу тантанасында Гүзәл Таҗетдиновадан Казан барды, озак еллар Филармония директоры булган Марат Таҗетдиновның гитарасын кабул итә.**

казаклары» ансамбле, «Лезгинка» бию ансамбле, «Терем-квартет» ансамбле һәм башкалар чыгыш ясады.

## «Джазлы Казан» халыкара фестивале

«Джазлы Казан» халыкара фестиваленең төп максаты – джаз музыкасы бәйрәме оештыру, тамашачылар һәм анда катнашучылар өчен чын иҗади атмосфера тудыру. Фестиваль концертлар, джем-сейшеннар, иҗади остаханәләр һәм очрашулар рәвешендә уза. Алар төрле яшьтәге тамашачы аудиториясе белән башкаручылар арасында якын элемтә оештыруны күз уңында тота. Мондый иҗатташлык фестивальнең максат-бурычларын тагын да нәтиҗәлерәк гамәлгә ашырырга булыша. Фестивальнең халыкара форматта булуы Россиянең һәм чит илләрнең иң яхшы башкаручыларын чакырырга, шул рәвешле, әлеге бәйрәмгә күпсанлы джаз белгечләрен һәм джаз музыкасын сөючеләрне җәлеп итәргә мөмкинлек бирә.

## «Джаз-Кроссовер-Фест-Казан» халыкара фестивале

Стилистик чикләү кысаларына гына сыймаган, үзендә күптөрле музыкаль юнәлешләрне камил берләштергән халыкара кроссовер-фестиваль 2016 елда барлыкка килде. Аның тарихы шушы елның апрелендә үткәрелгән ике концерттан башлана. Филармония сәхнәсендә дөньякүләм танылган башкаручылар: Даниил Крамер, Денис Мажуков, Игорь Бутман һәм Арминэ Саркисян чыгыш ясады. Төрле яшьтәге тыңлаучыларны җәлеп итеп, бу чара үз тамашачысын тапты һәм ел саен үткәрелә торган фестиваль статусын алды.

## Рөстәм Яхин исемендәге классик музыка фестивале

Фестиваль беренче тапкыр 2015 елда узды. Төп максаты – татар музыка сәнгатен үстерү һәм пропагандалау, мәшһүр композиторның милли чикләргә генә бикләнмәгән, дөньякүләм биеклеккә ия булган бай иҗади мирасын тыңлаучыга

тәкъдим итү. Фестиваль югары сәнгать өлкәсендә танылган башкаручыларны җәлеп итә, яшь талантларның профессиональ үсешенә уңай йогынты ясый. Һәр елның ноябрь аенда классик музыка җәүһәрләреннән тупланган өч уникаль концерт уза. Фестиваль «ЯХИН-ГАЛА» йомгаклау концерты белән тәмамлана.

## «Бард-Арт» автор-башкаручылар фестивале

Фестиваль беренче тапкыр 2020 елның гыйнварында узды. Ул озак еллар Татар дәүләт филармониясе директоры булган Марат Таҗетдинов истәлегенә багышланды. Марат Таҗетдинов Казанның танылган бард-башкаручысы иде. Фестиваль музыка сәнгатенең әлеге жанрына яңа сулыш өрү максатында оештырылды.

## Анатолий Шутиков исемендәге «Халык көйләре» Бөтенроссия конкурсы

Бу – халык уен коралларында уйнауны пропагандалау, халык көйләренә игътибар җәлеп итү максатында оештырылган конкурс. 2021 елда 13 нче тапкыр узачак. Конкурста балалар һәм яшьләр сәнгать мәктәпләре, урта махсус музыка уку йортлары укучылары, югары уку йортлары студентлары, профессиональ коллективлар катнаша ала.

## Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсы

Ул 2008 елдан башлап ел саен үткәрелә. 2019 елда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов карары белән конкурска РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Илһам Шакиров исеме бирелде. Аның максаты – татар халык җырларын һәм татар композиторларының әсәрләрен пропагандалау, яшьләрнең игътибарын милли-мәдәни кыйммәтләргә җәлеп итү, талантлы яшь башкаручыларны ачыклау һәм ярдәм итү, аларның иҗади потенциалын үстерү.

## Әдәби әсәрләрне сәнгатьле укучыларның «TATAR СҮЗЕ» республикакүләм бәйгесе

Ул 2020 елда гамәлгә куелды. Бәйге татар телен һәм әдәбиятын популярлаштыру, татар нәфис сүзенә кызыксыну уяту, шигъри аһәңне тоярга өйрәтү максатларында уздырыла. Аның бурычлары: татар телен һәм мәдәниятен саклап калу, аларның үсешенә ярдәм итү; татар халкыбызның бай тарихи-мәдәни казанышы буларак, татар классик әдәбиятын саклап калу; татар әдәбиятына карата кызыксыну уяту; талантлы нәфис сүз осталарын барлау һәм аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерергә ярдәм итү.

Бәйгене гамәлгә куючы – Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе.

*Журналга* ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

*Җуелмас хәзинә*

# «Зиләйлүк» җыры

***Сәхифә «Тәртип» радиосында чыгып баручы «Саф вә раушан көзге» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.***

**«Эштән чыгарылган татар кызына» шигыренә иллюстрация. *Б.Урманче рәсеме*. 1955 ел**

### *Зиләйлүк*

*(Татар халык көе, Г.Тукай сүзләре)*

Сөялгәнсең чатта баганага,
Яфрак төсле сары йөзләрең.
Кызганмыйча күңелем чыдый алмый,
Бигрәк моңлы карый күзләрең.

Атылган кош, адаштырган эттәй,
Үткәннәргә мәэюс карыйсың;
Күрәм, ике иренең селкенәдер:
Кайсы татар баен каргыйсың?

Сизмисең бит син дә синең яннан
Нечкә күңел шагыйрь узганын.
Синең болай мескенләнгән хәлең
Аның күңелен ничек өзгәнен.

Гадәттә, «Зиләйлүк» җырын «Бондюг кызы Зиләйлүк» белән бутыйлар. Бу ике җыр бер-берсеннән бик нык аерыла. Соңгысын 1950 нче елларда Бондюг (хәзерге Менделеев) химкомбинатының Мәдәният сарае каршындагы Җыр һәм бию ансамблендә катнашучылар иҗат иткән.

1907-1908 нче елларда Казанда «Ончы Хаҗи» дигән бер сәүдәгәр – Гыйльметдин Ибраһимов үзенең унөч яшьлек асравын көчләгән һәм куып чыгарган дигән хәбәр тарала. Тукай, бу вакыйга турында ишетеп, «Эштән чыгарылган татар кызына» дигән шигырен яза.

*«Мин аның белән сөйләшә дә, йөрешә дә, җырлаша да торган идем. Үзенең «Сөялгәнсең чатта» дип һәм «Ишеттем мин кичә бераү җырлый» дип башлана торган җырларын Тукаев иң әүвәл миңа үтенеп җырлатты. Мәрхүм үзе музыкага гаять хисле булганлыктан, мин җырлаган вакытта минем музыка хаталарымны табып төзәтә торган иде»*, – дип искә ала язучы һәм журналист Солтан Рахманколый (1888-1916). Алга таба бу җыр байтак җырчының (әйтик, И.Шакиров, Х.Бигичев һ.б.) репертуарында була. ■

# Көлке куа килә...

## Роберт Миңнуллин (1948–2020)

### Ленин исемендәге колхоздан...

*(Студент еллары мәзәге)*

1968 ел. Казан университетына керер өчен имтиханнар биреп йөрибез. Егетләр бергә җыелышып сөйләшәбез, бергә әзерләнәбез, танышабыз. Кем кайсы тарафлардан килгән?

– Мин Мөслимнән, Түреш авылыннан...

– Мин Сарманнан, Дүсем авылыннан...

– Мин Илештән, Шәммәт дигән авылдан...

– Мин Башкортстаннан, Күгәрчен авылыннан...

Шунда Шамил Әхмәтшин дигән егетебез дә сүзгә кушыла, зур горурлык хисләре белән әйтеп тә ташлый:

– Ә мин Кукмарадан, Ленин исемендәге колхоздан...

Көнләшүдән барыбыз да тып-тын кала. Вәт бәхетле кешеләр бар да инде бу дөньяда! Ленин исемен йөрткән данлыклы университетка Ленин исемендәге колхоздан укырга кил әле син! Шамилне болай булгач имтихансыз-нисез генә дә алырга тиешләр...

Барыбыз да студентлар булдык. Шамил мәрхүм инде. Урыны җәннәттә булсын!

## Гарифҗан Мөхәммәтшин

### Дөнья хәлләре

*(Арбор авылы мәзәге)*

Утызынчы еллар ахыры.

Укый-яза белмәгән Минһаҗны Арбордагы «Социализм» колхозына рәис итеп сайлаталар. Менә беркөнне нәрәт алдыннан Минһаҗ кабинетында, бик укымышлы рәвеш китереп, газета «укып» утыра. Кеше җыйналып беткәч, башын күтәреп:

– Да-а-а, егетләр, кайный дөнья, кайда ниләр генә юк! – дип куя бик белдекле кыяфәт белән.

Карасалар, бу газетаның башын аска әйләндереп «укып» утыра икән.

безнең мирас №12 декабрь 2020

## Марсель Галиев

### Атыңны да...

*(Азнакай мәзәге)*

«Утызмеңчеләр» чорында Әхмәдиевне колхоз рәисе итеп куялар. Анда берничә ел эшләгәннән соң, район үзәгенә төзелеш-ремонт оешмасы җитәкчесе итеп алалар. Ниһаять, ул, колхоз атыннан төшеп, машинага утырып йөри башлый. Иркен кабинет. Алгы бүлмәдә секретарь кыз...

Кышның бер көнендә моның кабинетына үз урынына калган колхоз рәисе килеп керә. Ак күлмәк, галстук, шәп костюмлы Әхмәдиев, ишек катында иске авыр толыптан, силос аңкытып торган рәискә карап:

– Атыңны да алып кермисеңме?! – дигән.

## Тәлгат Нәҗмиев (1950–2014)

### Төшләнү

*(Саба мәзәге)*

Беркөнне Саба урамында таныш ханымны очраттым. Хәлләрен сорашам.

– Әйбәт түгел, – диде бу, – ирем Шәфәгать әллә нишләде. Беркөнне йокымсырап ятам. Төн уртасы. Шәфәгать, гырлый-гырлый йоклаган җиреннән уянып, бит уртасыннан «чүт» итеп үпте һәм колакка: «Аэропортта очрашырбыз», – диде. Сабада аэропорт бөтенләй юк бит!!!

– Шуннан? – дим.

– Шуннанмы? Шуннан тагын да катырак гырылдап йоклап китте...




## Рабит Батулла

### Хәтер, диген

*(Язучылар турында мәзәк)*

Фатих Хөсни Нәби Дәүлигә шылтырата:

– Карале, Нәби, язучыларның Переделкинодагы иҗат йорты ничек дип атала әле?

Нәби Дәүли:

– «Переделкино» дип атала! – ди.

– Ә-ә, шулаймыни? – ди Фатих ага. – Хәтер, диген! ■

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

# НОЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында




● Ноябрьдә Алма-Атада Казакъстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2003), медицина фәннәре докторы, профессор Морат Габделхәй улы Кәримовның «Татары Республики Казахстан: краткая энциклопедия» дигән китабы дөнья күрде.

● 2 ноябрьдә танылган журналист, нашир, 1992 елдан «Юлдаш» газетасының баш мөхәррире Ранис Газизов (Буа районының Кыр Тәүгелдесе авылында 1959 елның 27 маенда туган) 61 яшендә вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде 3 ноябрь көнне «Курган» зиратында җирләнде.

● 14-15 ноябрь көннәрендә Саба мәдәният йортында һәм Явлаштау авылында, ТАССРның атказанган артисты (1986), Татарстан Республикасының М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты (1988) Шамил Бариевның (1950-1994) тууына 70 ел тулу уңаеннан, истәлекле чаралар узды. Мәрхүмнең кызы – Татарстанның атказанган артисты, җырчы Айгөл Бариева оештырган әлеге чараларда республикабызның танылган сәнгать әһелләре, Ш.Бариевның якташлары һәм шәкертләре катнашты.




● 16 ноябрьдә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Сәүдә-сәнәгать палатасында Татарстан эшкуарлары белән очрашты. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашкан әлеге чарада РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов Казанның сәүдә үзәкләрендә мөселманнар өчен өстәмә гыйбадәт бүлмәләре булдыру тәкъдиме белән чыкты. Р.Миңнеханов бу тәкъдимне хуплады һәм Татарстан мөфтие Камил Сәмигуллинга гыйбадәт кылу урыннары кирәк булган биналар исемлеген төзү бурычын куйды.

● 17 ноябрьдә танылган этнограф, татар халкының этномәдәни тарихы һәм традицион мәдәнияте турында фундаменталь тикшеренүләр авторы Рәмзия Мөхәммәтова 97 яшендә вафат булды.

● 17 ноябрьдә КФУда «Иң яхшы студентлар фәнни түгәрәге-2020» бәйгесенә йомгак ясалды һәм анда Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының «Хәзерге татар теленең актуаль проблемалары» студентлар фәнни түгәрәге «Телне һәм мәдәниятне саклау өлкәсендә иң яхшы түгәрәк» номинациясендә җиңү яулады.

● 17 ноябрьдә Татарстанның атказанган (1988) һәм Татарстанның халык артисты (1998), Казан шәһәр филармониясе солисты, заманында Россия эстрадасының күренекле сәнгатькәрләре И.Кобзон, С.Ротару һәм А.Пугачева белән бер сәхнәдә җырлаган Равил Харисов 72 яшендә вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде 18 ноябрь көнне «Курган» зиратында җирләнде.

● 16-19 ноябрь көннәрендә Казанның «Идел» яшьләр үзәгендә «Иделем акчарлагы» яшь язучылар бәйгесенә нисбәтле чаралар узды. Бәйге нәтиҗәләреннән билгеле булганча, быел беренче урыннарны Әтнә кызы Энҗе Хөсәенова («Поэзия» номинациясе), Арча кызы Рамилә Шәйхиева («Проза») һәм Актаныш кызы Алинә Хәбибуллина («Балалар әдәбияты») алды. А.Хәбибуллина шулай ук «Проза» һәм «Поэзия» номинацияләрендә Гран-прига ия булды.

● 19-20 ноябрь көннәрендә «Корстон» кунакханә-күңел ачу үзәгендә журналистларның «Бәллүр каләм» бәйгесенә нисбәтле чаралар булып узды.

● 20 ноябрьдә Казанның «Пирамида» күңел ачу үзәгендә «Әдәби марафон»ның йомгаклау чарасы узды. Чарада язучылар һәм шагыйрьләр, аерым алганда, Р.Батулла, Р.Фәйзуллин, Д.Салихов, Н.Гыйматдинова, Л.Лерон, Й.Шәрәпова, Г.Батталова, Г.Галимуллина, Э.Сафина һ.б. катнашты һәм, бәйгедә җиңүчеләрне котлап, чыгыш ясады.

● 27 ноябрьдә Тукай районында татар әдипләре, сәнгать әһелләре катнашында шагыйрь Фәннур Сафинга нисбәтле әдәби чаралар узды. Быел Ф.Сафин премиясенә Чаллыда яшәп иҗат итүче язучылар Рәзинә Сәетгәрәева белән Галиәхмәт Шаһи лаек булды.




● Россиядә иң эре мөселман нәшриятларыннан саналган «Хозур» нәшрияты 2020 елның 10 ае эчендә 65 исемдәге төрле китап бастырып чыгарды. Аларның гомуми тиражы 150 000 данә тәшкил итә.

# «БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢ 2020 ЕЛГА БИБЛИОГРАФИЯСЕ*

## ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

Гариф Ахунов. – №9. – Б.3.
Гаяз Исхакый. – №10. – Б.3.
Җәүдәт Дәрзаман. – №11. – Б.3.
Нәкый Исәнбәт. – №1. – Б.3.
Рафаил Төхфәтуллин. – №6. – Б.3.
Ризаэддин Фәхреддин. – №5. – Б.3.
Сәгыйть Рәмиев. – №2. – Б.3.
Туфан Миңнуллин. – №8. – Б.3.
Хәсән Сарьян. – №4. – Б.3.
Хәсән Туфан. – №12. – Б.3.
Шәйхи Маннур. – №7. – Б.3.

## ТАТАР ГАМЕ

«Хәтергә уелган китап». – №1. – Б.46-47.

«Хикмәт белән эшләргә кирәк!» – №11. – Б.50-55.

А.Әхмәтгалиева. Без дә ярлы түгел… – №12. – Б.64-67.

А.Бугарчев, О.Степанов. Әтрәч тәңкәләре. – №12. – Б.56-59.

А.Хәбибуллин. Татарның игелекле улы. – №5. – Б.10-17.

Әтрәч укулары: болгар-татар нумизматик мирасы. – №12. – Б.44-49.

Бәхет биргән авылым. – №11. – Б.48-49.

Г.Гатауллина. Буыннардан күчкән якты мирас. – №2. – Б.46-47.

Диләрә Нәүрүзованың китап дөньясы. – №12. – Б.68-73.

Илкәем бар – дөньям түгәрәк! – №10. – Б.46-49.

Илшат Нуриев: «Арчада һәр кеше бай һәм матур яшәргә тиеш!» – №9. – Б.36-41.

Ильяс хәзрәт Җиһаншин: «Мирасыбызны киләчәк буынга җиткерик!» – №5. – Б.4-9.

Ирек Шәрипов: «Мирасыбыз көндәшлеккә сәләтле!» – №4. – Б.50-56.

М.Вәлиев. Әзгәри суккан Әтрәч. – №12. – Б.50-55.

М.Гәрәев. Музыка белән язылган язмышлар. – №2. – Б.48-51.

Марсель Шәйдуллин: «Азнакай – бай тарихлы төбәк!» – №8. – Б.4-11.

Рамил Муллин: «Иң мөһиме – кешенең рухи дөньясы». – №7. – Б.4-15.

Рәгать Хөсәенов: «Лениногорск – минем өчен дөньяда иң яхшы шәһәр!» – №11. – Б.42-47.

С.Галиева. Гөләйза. – №4. – Б.57-63.

Т.Биктимирова. Игелекле татар байлары. – №5. – Б.18-23.

Ф.Гайнанова. Өстәлемдәге китап – чынбарлык! – №1. – Б.44-45.

Фәнир Галимов: «Авыллар, һичшиксез, яшәячәк!» – №10. – Б.40-45.

Һәр китапханәгә – «Безнең мирас»! – №1. – Б.36-43.

Э.Сәлахова. Әтрәч керәшеннәренең ислам өчен көрәше. – №12. – Б.60-63.

## ТАРИХИ МИРАС

«Иттифакъ» газетасы. – №5. – Б.60-63.

«Сугыш сафы» газетасы. – №6. – Б.34-37.

А.Борһанов. Киләчәкне тарихка нигезләнеп кору. – №8. – Б.16-21.

А.Борһанов. Тарихи Чишмә һәм Зәй буйлары. – №11. – Б.36-41.

А.Борһанов. Ядкярләрдән безгә тарих бага… – №7. – Б.56-59.

А.Гайнетдинов. Борһанеддин Мәрҗанинең кабер ташы. – №10. – Б.38-39.

А.Гайнетдинов. Зариф Әмирханның кабер ташы. – №8. – Б.52-53.

А.Гайнетдинов. Ибраһим Идриснең кабер ташы. – №9. – Б.34-41.

А.Гафиятов. Халык белән бергә. – №1. – Б.31-35.

А.Шәрәфиева. I Бөтенроссия мөселманнар корылтаенда хатын-кызлар мәсьәләсе. – №5. – Б.49-54.

Азнакай музее турында җиде факт. – №8. – Б.12-15.

Ә.Бостанов. Бәрәңге хәзинәләре – Казан университетында. – №12. – Б.26-29.

Ә.Исхакый. Казан нигә җан бирде? – №12. – Б.16-20.

Ә.Сафуанов. Туймазы Шәкүре. – №10. – Б.24-28.

Борһан Шаһиди (1894-1989). – №5. – Б.64-75.

Г.Закиров. Апаз керәшеннәренең исламга кайтуы. – №9. – Б.22-27.

Г.Мырзагалиева. Хан Урдасы (Хан Ставкасы) татарлары. – №6. – Б.16-23.

Г.Төхфәтуллин. Исемдә калганнар. – №6. – Б.24-29.

Г.Хаҗиева. Исемең матур, кемнәр куйган? – №4. – Б.47-49.

Г.Хаҗиева. Фамилияләребез. – №6. – Б.30-33.

Г.Хисамиев. Гөләйза кыйссасы. – №2. – Б.9-24; №4. – Б.15-21; №5. – Б.43-48.

* Журналның 3 нче (2020) саны тулысынча «Яңарыш» фондының 10 еллыгына багышланды.

Г.Хисамиев. Кантончы татарлар тарихы. – №8. – Б.22-29.

Г.Хисамиев. Татар хатыны ниләр күрми: кыйналган Зөбәйдә «Эш»е. – №10. – Б.20-23.

Г.Хисамиев. Татарча талак: «Минем беләи мунча кергәне юк». – №12. – Б.4-8.

Җ.Рәхимов. Зәй-Каратай: Революциягә кадәрге тарих. – №11. – Б.16-23.

И.Миргалиев. Җүчи Олысының беренче ханбикәсе һәм ислам дине. – №4. – Б.22-25.

И.Таһиров. Кичә, бүген һәм иртәгә. – №5. – Б.24-31.

И.Таһиров. Солтангалиев кем ул? – №10. – Б.10-19.

И.Һадиев, Р.Мәрданов. Мәмәтхуҗаның борынгы ташъязмалары. – №11. – Б.34-35.

И.Шиһапов. Түмәнәкне кемнәр нигезләгән? – №10. – Б.29-33.

Итәге (Итүк батыр). – №6. – Б.6-15.

К.Тукаева. Буыннар бәйләнеше. – №6. – Б.45-49.

Кәвәл авылы (Түгәрәк уен көе). – №7. – Б.41.

Л.Гайнанова. «Зөләйха» һәм миссионер Малов. – №10. – Б.4-9.

Л.Гайнанова. Олы мирасны барлаганда. – №11. – Б.24-25.

Л.Галиева. Габдулла Тукай иҗаты поляк телендә. – №4. – Б.30-33.

Л.Гобәйдуллин. Татар кызлары – Балкан сугышында. – №1. – Б.10-11.

Л.Константинова. Керәшен тамгалары. – №7. – Б.22-27.

Л.Мортазина. «Сез бетәчәк түгел!» (Ерак Шәрыкта Тукай кичәләре). – №4. – Б.26-29.

Л.Мөхәммәтҗанова, Г.Дувалова. Мамадыш төбәге авыз иҗаты – милләт сагында. – №7. – Б.36-40.

Л.Мөхәммәтҗанова. «Идегәй» – халык дастаны. – №6. – Б.4-5.

Л.Мөхәммәтшина. Шагыйрь тормышында Сосна Пүчинкәсе. – №4. – Б.44-46.

Л.Тябина. Беренче татар фотографы. – №8. – Б.30-35.

Л.Тябина. Тукайның дусты – Мәхмүт Галәү. – №9. – Б.4-9.

М.Әбделганиева, М.Сәхапова. «Ислам динен олылагыз!» – №5. – Б.32-34.

М.Гарипов. Багбостан. – №8. – Б.36-41.

М.Госманов. Археографик көндәлек. – №1. – Б.24-30.

М.Госманов. Барданың серле балбалы. – №12. – Б.9-15.

М.Рәхмәт Паташева. Истанбул хатирәләре. – №1. – Б.12-18; №2. – Б.16-24.

М.Сәхәбетдинов. Милли көрәш төрләре. – №7. – Б.64-65.

Мирхәйдәр Фәйзи: «И Ходаем, тәнгә сихәт, саулык бир!» – №11. – Б.12-15.

Мирхәйдәр Фәйзи: «Күңелем гүя оҗмахка керде». – №6. – Б.38-44.

Мирхәйдәр Фәйзи: «Никах сәгатьләре сукмый бит!» – №4. – Б.38-43.

Мирхәйдәр Фәйзи: «Уразалар мөкатдәс миңа!» – №2. – Б.30-38.

Мөслимнең Туган якны өйрәнү музее. – №7. – Б.60-63.

Н.Гариф. Үткәннәргә сәяхәт. – №12. – Б.30-33.

Н.Исхаков. Татарларны чукындыру сәясәте Үтәмешне дә читләтеп узмаган. – №7. – Б.42-49.

Н.Каштан. Тарих көзгесендә Кыр Бикшиге авылы. – №6. – Б.50-54.

Р.Гайнанов. Галимҗан Ибраһимов һәм «Аң» журналы. – №11. – Б.26-29.

Р.Исхакова. Үтәмеш зиратының кабер ташлары. – №5. – Б.38-48.

Р.Мәрданов, И.Һадиев. Әлифба китаплары. – №12. – Б.22-25.

Р.Мәрданов, И.Һадиев. Казанда татар китабын басучы матбагалар. – №9. – Б.28-33.

Р.Мәрданов, И.Һадиев. Казандагы беренче татар матбагалары. – №8. – Б.42-47.

Р.Мәрданов, И.Һадиев. Халкыбызның рухи юлбашчысы. – №7. – Б.50-55.

Р.Муллахмәтова. Кече Сон мәдрәсәсе тарихы. – №7. – Б.31-35.

Р.Сәлиев. Галәветдин хәзрәт Җамалетдиновка ни өчен яла ягылган? – №5. – Б.55-59.

Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин. «Аваз» газетасы. – №11. – Б.30-33.

Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин. «Безнең тавыш» газетасы. – №12. – Б.40-43.

Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин. «Кызыл Урал» газетасы. – №4. – Б.34-37.

Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин. «Тартыш» газетасы. – №1. – Б.19-23.

Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин. «Тәтеш оешмасы» газетасы. – №2. – Б.25-29.

Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин. «Чулпан» газетасы. – №10. – Б.34-37.

Р.Шәрәфиева. Л.Гобәйдуллин. «Җөмһүрият» газетасы. – №8. – Б.48-51.

С.Шәмси. «Этрусклар – Рим остазлары. – №1. – Б.4-9; №2. – Б.4-8; №4. – Б.4-9; №7. – Б.12-15.

Ф.Бәйрәмова. Шәмсуар йолдызлыгы. – №12. – Б.34-39.

Ф.Ислаев. Һаваларда оча ике аккош… – №2. – Б.39-45.

Ф.Мингалиева. Мамадышым – газиз җирем! – №7. – Б.16-21.

Ф.Мусин-Мәмәтев. Мәмәтевләр нәселе – Бәрәңге төбәгенең горурлыгы. – №4. – Б.10-14.

Х.Вәлиев. Саумы, ураза! – №5. – Б.36-37.

Х.Мәхмүтов. Кышкы сынамышлар. – №12. – Б.21.

Х.Хисмәтуллин. Үткән юллар. – №11. – Б.4-11.

Э.Сәлахова, Л.Гобәйдуллин. Югары Курса

авылының рухи тормышы. – №9. – Б.10-17.
Ю.Карпов. Мамадыш крестьяннары бунты. – №7. – Б.28-30.
Югары Курсада – «Илдус» мәчете. – №9. – Б.18-21.

## ДИНИ МИРАС

Ислам дөньясы. Габдерәшит Ибраһимов. – №1-2, №4-12.
А.Дубин. 2020 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. – №1. – Б.54-55.
Ш.Максудова. «Балаларыма, җәмәгатемә тимәгез!» – №9. – Б.47.
Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин. Мәүлид ае – хәзрәти Мөхәммәд(с.г.в.)нең туган аедыр. – №11. – Б.63-65.

## ӘДӘБИ МИРАС

«Сабыр канатларым сынды...» Мәхмүт Хәсәнов – Туфан Миңнуллинга. – №8. – Б.78-79.
Ә.Шәрипов. Сиринне фаҗигагә этәргән әсәр. – №8. – Б.66-67.
Ә.Шәрипов. Тукай һәм шагыйрь Сирин. – №9. – Б.60-66.
Әйбәт истәлек. Сибгат Хәким – «Казан утлары»на. – №8. – Б.77.
Әхмәд Гәрәй шигырьләре. – №8. – Б.60-61.
Г.Ахунов. Фатих малае. – №9. – Б.54-59.
Г.Кашшаф. Шайтанлы чишмәсе буенда. – №10. – Б.62-68.
Г.Таҗетдинова. «Күңелгә җылы хис тулып тамды». – №10. – Б.69-73.
Гәүһәр Туганай шигырьләре. – №10. – Б.60-61.
Исфәндияр Ишгай шигырьләре. – №6. – Б.60-63.
К.Кәримов. Мәхәббәт чокыры. – №7. – Б.81-83.
Каһарман Гали маҗаралары. – №4. – Б.64-73.
Л.Лерон. «Авылыңны чынлап яратсаң...» – №8. – Б.74-76.
Л.Лерон. Мәскәүгә – Миргазиян абыйга. – №6. – Б.64-66.
М.Әхмәтҗанов. Әкиятче бабай. – №8. – Б.80-81.
М.Госманов. Тыйнак табигатьле каләмдәшебез. – №4. – Б.86-87.
М.Хәсәнов. Идел һәм Муса. – №4. – Б.74-77.
М.Юныс. Безнең өй өянкеләр астында иде... – №6. – Б.67-74.
Н.Гыйләҗева. Һәр солдатның үз язмышы. – №4. – Б.78-81.
Н.Фәттахова, Л.Харасова. Муса Җәлил китапханәсендә автографлы китаплар. – №8. – Б.62-65.
Р.Исламов. Утыз-Имәни һәм «Госман Корьәне». – №11. – Б.71-75; №12. – Б.84-91.
С.Зыялы. Хушлашмый да китеп бардың. – №6. – Б.75-77.
С.Шәйхи. Тальян моңы. – №5. – Б.83-85.
С.Шәйхи. Уймак-уймак уйлар. – №7. – Б.84-85.
Сирин. Ана. – №8. – Б.68-69.
Т.Галиуллин. Әдәби калейдоскоп. – №11. – Б.76-80.
Т.Миңнуллин. Тимердән дуга бөгәләр... – №8. – Б.70-73.
Үткәннән хатлар. – №11. – Б.81-83.
Ф.Бурнаш. Хөсәен мирза. – №1. – Б.56-69.
Ф.Хатипов. Кызыл артында – каралык. – №1. – Б.78-81.
Х.Миңнегулов. Мөһаҗирлектәге татар китабы. – №1. – 70-77; №2. – 58-65; №4. – Б.70-73.
Х.Миңнегулов. «Сагындыра туып-үскән җир» (Исфәндияр Ишгай). – №5. – Б.76-82.
Х.Миңнегулов. «Татар моңнары һаваларга таралсын!» – №7. – Б.72-80.
Х.Миңнегулов. Олуг мәгърифәтчебез Хәсән Хәмидулла. – №11. – Б.66-70.
Х.Миңнегулов. Фин илендә Кәрәкәшле кызы. – №9. – Б.48-53; №10. – Б.56-59.
Хәйдәр. Балдаклы хыянәт. – №2. – Б.66-71.
Хәсән Хәмидулла (1960-1986) шигырьләре. – №12. – Б.80-83.
Э.Шәрифуллина. «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер». – №4. – Б.82-85.
Э.Шәрифуллина. Дөнья фанатлар белән матур. – №12. – Б.92-95.

## ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

Габдерахман Гомәри. Мәрҗани хәзрәтнең вафаты (1818-1889). – №5. – Б.86-87.
Л.Лерон. Зөлфәт вафаты. – №7. – Б.86-89.
Л.Лерон. Мәгъсум Хуҗин вафаты. – №9. – Б.69-71.
Л.Лерон. Мәхмүт Хөсәен вафаты. – №6. – Б.78-79.
Л.Лерон. Мөдәррис Әгъләм вафаты. – №10. – Б.74-79.
Мәшһүрләребез: Бакый Урманче һәм Нури Арслан. – №2. – Б.72-73.
Нәкый Исәнбәт вафаты. Гомәр Бәширов көндәлегеннән. – №8. – Б.82-83.
Хәсән Туфан. Гомәр Бәширов көндәлегеннән. – №1. – Б.82-90.
Шәхесләребез: Галимҗан Латыйп, Хөснул Вәлиуллин һәм Зәки Нури. – №4. – Б.88-89.

Хәтер сандыгы

«Хат язар идем сезгә...» – №9. – Б.87-90.
А.Гаделша. 75 ел эзләдем. – №7. – Б.92-99.
А.Гайнетдинов. Барудиның кабер ташы. – №6. – Б.80-81.
А.Гайнетдинов. Мәрҗанинең кабер ташы. – №5. – Б.88-90.
Ә.Фәйзрахманов. Ике министр. – №1. – Б.91-93.
Ә.Шакиров. Әти. – №2. – Б.94-101.
Г.Ахунов. Без бит Арча яклары. – №9. – Б.79-

83.
Г.Җиһангирова. Сугыш еллары кайтавазы. – №6. – Б.89-91.
Г.Рәхим. Халкыбыз Илһамы. – №2. – Б.74-82.
Г.Шәмсетдинов. Олуг Мөхәммәдкә – һәйкәл. – №5. – Б.95-99.
Җәмит Рәхимовның фотомирасы. – №11. – Б.104-105.
И.Вәлиуллина. «Җырланып бетмәгән җырым». – №9. – Б.91-95.
И.Вәлиуллина. Туфан Миңнуллин юксындыра. – №11. – Б.96-101.
И.Габдрахманов. Батырлар табыла вакыт белән… – №5. – Б.91-94.
И.Нигъмәти. Үлемсез батальон солдаты. – №8. – Б.95-97.
И.Таһиров. Беренче укытучыларым. – №2. – Б.83-86.
Истә, һаман да истә! – №1-2, №4-12.
Л.Лерон. Батулла музее. – №10. – Б.100-101.
Л.Нәгыймов. Милли музейда – ГАЗ-А автомобиле. – №1. – 96-97.
Л.Нәгыймов. Милли музейда – ПО-2 самолеты. – №2. – Б.102-103.
Р.Батулла. Кара тәкъдир. – №10. – Б.90-95; №11. – Б.94-95; №12. – Б.96-97.
Р.Сәгъди. Сагыш. – №4. – Б.96-100.
Р.Туфитуллова. Зөлфәт. – №10. – Б.96-99.
С.Сәүбанова. Карлыгач оясы. – №6. – Б.92-99.
Т.Биктимирова. Әхмәтҗан хәлфә. – №8. – Б.84-88.
Т.Биктимирова. Ут эчендә татар кызлары… – №9. – Б.72-78.
Ф.Галимуллин. Казанда Гали Акышны хөрмәтләү. – №9. – Б.96-101.
Ф.Кутлу. Гомерлек үкенеч. – №4. – Б.90-95.
Ф.Нәфиев. Прокурор. – №6. – Б.82-88.
Ф.Нәфиев. Халкы өчен биреп бар көчен. – №2. – Б.87-93.
Ф.Нәфиев. Япон феномены. – №8. – Б.89-94.
Халык иҗаты хәзинәләре. – №10. – Б.102-103.
Ш.Максудова. Мөхәммәт Мәһдиев турында истәлекләрем. – №9. – Б.84-86.

## СӘНГАТИ МИРАС

«Зиләйлүк» җыры. – №12. – Б.109.
«Галиябану» спектакле: ике Хәлил, ике Галиябану. – №6. – Б.105-107.
«Шахта» җыры. – №11. – Б.112-113.
А.Хәкимова. «Туплар шартласа да, җырлар тынмый!». – №5. – Б.100-105.
Ә.Зарипов Камал III. – №1. – Б.98-103.
Ә.Фәйзрахманов. Фасилнең моң чишмәсе. – №5. – Б.106-111.
Д.Гайнетдинова. Оптимистик фикер һәм хисләр җырчысы. – №1. – Б.106-110.
З.Гыйльметдинова. Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында. – №1-2; №4-12.
Л.Лерон. Мөхәммәт Мәһдиев музее. – №9. – Б.110-113.
М.Фәйзуллин. «Урман кызы». – №4. – Б.106-108.
Н.Сәйдәшев. Аны яраталар иде… – №12. – Б.102-104.
Р.Гыйләҗев. Борынгы татар милли музыка уен кораллары. – №2, №7-12.
Р.Сәгъди. Иҗат мөһере. – №8. – Б.100-107.
Р.Фәйзуллин. Сәйдәш (поэмадан өзек). – №12. – Б.105.
Х.Җәләлов. Сау бул, авыл! Исәнме, Казан! – №4. – Б.101-105.

## ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

М.Булатова. Татар тарихи лексикологиясенә бер караш. – №6. – Б.108-113.
М.Мәһдиев. Туган як авазы. – №1. – Б.111-114.
Р.Акъегет. Тел дигән дәрья бар… – №7. – Б.112-113.
Р.Низами. Яңа тарих язылганда. – №4. – Б.112.
Р.Сәфәров. Манкорт. – №2. – Б.110-112.
Р.Сәфәров. Эт көннәре. – №4. – Б.113.
Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре. – №2. – Б.113.
Т.Миңнуллин. Тукай ул – безнең татар халкының дәүләте.– №5. – Б.112-113.
Э.Шәрифуллина. Йөрәк сүзем. – №1. – Б.115.

## СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Ә.Зарипов. Гомерем мизгелләре. – №7. – Б.100-111.

## ФИКЕР ДӘРЬЯСЫ

Р.Садриев. Театр һәм тамашачы. – №9. – Б.67-68.
Р.Садриев. Милләт. – №10. – Б.112-113.
Р.Садриев. Хәтер. – №12. – Б.100-101.

## ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

А.Сарманбәтов. Таш батыр турында риваять. – №10. – Б.80-89; №11. – Б.84-93.

## ШАЯН МИРАС

Көлке куа килә… – №2; №4-12.

«Безнең мирас» хәбәрләре. – №1-2; №4-12.
Мирасворд. – №1-2; №4-12.
«Безнең мирас» елъязмасы. – №1-2; №4-12.

*Басмага **Ләйсән Данилова** әзерләде.* ■

# МИРАСВОРД



Атлы гаскәри (бор.)

Саран; түбән җанлы кеше (иск.)

Дошманнан саклану өчен шәһәр тирәли казып ясалган ныгытма, траншея

«..., ...! Туп-туры тор, тәз утыр, яхшы утыр!» (Г.Тукай)

Европада яшәгән борынгы кельт кабиләләре кешесе

... Сараи / Вертолет

18-19 нчы йөзләрдә ике мачталы, җилкәнле кораб

Нәҗип Җиһанов операсы

Элмәк кидерү өчен аркылы агач

Җәфа, газап / ... Насыйри

Грек хәрефе / Әмирхан Еники хикәясе

Фоат Галимуллин туган авыл

... Дәүли

Борынгы Рим императоры

Шагыйрь Харрас ...

Шагыйрь ... Гамбәр

Түбәтәйнең бер төре (диал.)

Аксыл, сыек көрән (хайван төсе турында)

Шәүкәт Галиев шигырьләрендәге шук малай

Ун мең кешелек гаскәр (бор.)

Винсент ... Гог

Френкель, Арлазоров

Шәригать тарафыннан тыелмаган, рөхсәт ителгән

Эре сөякле; зур (диал.)

Язучы Тәүфикъ ...

Дон буендагы борынгы хәзәр шәһәре

... Саттаров (балалар язучысы)

Оят, намус (иск.)

Федерико Гарсиа ...

Үлгән кешенең җаны, рухы

Элекке административ-территориаль берәмлек

... Яһудин (нәфис сүз остасы, конферансье)

Ашлык әрҗәсе

Англиядә дворян титулы / Сары чәчәк атучы куак

Бизәнү әйбере / ... елан

Россия кинопремиясе

Алтын (иск.)

Рифкать Гомәров оештырган ансамбль

**11 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:**
**Сулдан уңга:** Агиев, коен, шаһ, Ләис, алафа, тәпән, маил, томага, Хәй, «Вий», Вил, Дон, әрәтә, кәлимә, оста, кәүсәр, Шер, Шабаев, Әнвәр, Иркә, шекә, Нил, Килем.
**Өстән аска:** Аспарух, Кояш, Әнәс, Илшат, йолт, «Афәт», диабаз, Ваһапов, әзи, Әминә, Ивик, най, Рене, әпә, Мишкә, Колыма, Үшнә, Вәисев, Еники, ит, әрә, Ләлә.

*Рәис Габдулла төзеде.*

# «Безнең мирас»
## елъязмасы / декабрь

**Тәбриз каласы, 1840 ел.** ***Эжен Фланден рәсеме.***

**865 ел элек (1155)**
Тимучин (Чыңгыз хан) дөньяга килә.

**760 ел элек (1260)**
Хулагу хан хәзерге Иран биләмәләрен яулап ала. Багдад каласын кулга төшерә. Берочтан ул Габбасыйлар нәселен юк итә вә Тәбриз каласын үз дәүләтенең башкаласы ясый.

**640 ел элек (1380)**
Аксак Тимер Тимермәликкә каршы яу башлый.

**385 ел элек (1635)**
Солтан Морад Дүртенче гаскәрләре Тәбриз шәһәрен яулап ала.

**110 ел элек (1910)**
Декабрь аеннан Баку шәһәрендә «Ары» («Бал корты» исемле расемле көлке журналы нәшер ителә башлый. Нашире – Гали Мөхәммәт Галиев,мөхәррире – Дәдәш Бөниятзадә.

**50 ел элек (1970)**
Алма-Ата каласында татар шагыйрьләренең «Татар җырлары» исемле китабы дөнья күрә.

**30 ел элек (1990)**
Март аенда сабыйлар өчен «Салават күпере» дигән журнал чыга башлады.

*Журналга* ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

## Содержание. Декабрь 2020

**И останется в мире слово моё…:** Хасан Туфан.

**Историческое наследие:** «Таинственный балбал Барды». М.Усманов; «Азбуки». Р.Марданов, И.Хадиев; «Парангинские сокровища – в Казанском университете». А.Бустанов; «Путешествие в прошлое». Н.Гариф; «Созвездие Шамсуар». Ф.Байрамова; «Газета «Безнең тавыш» («Наш голос»)». Л.Губайдуллин и Р.Шарафиева.

**Татарский мир:** «Атрясские чтения: булгаро-татарское нумизматическое наследие»; «Борьба за ислам Атрясских кряшен». Э.Саляхова; «Мы тоже не бедные…» А.Ахматгалиева.

**Религиозное наследие:** «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Памятные даты и праздничные дни в 2021 году». А.Дубин.

**Литературное наследие:** «Стихи Хасана Хамидуллы (1960-1986)»; «Мир прекрасен со своими фанатами». Э.Шарифуллина.

**В глубинах памяти:** «В памяти, до сих пор в памяти!»

**Океан воззрений:** «Память». Р.Садриев.

**Художественное наследие:** «Его любили все…» Н.Сайдашев; «Татарская государственная филармония в истории 100-летней ТАССР». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

## Алхәбәр:

Археограф һәм китапханәче Альберт Фәтхи

- **Азиз Али.** **Ислам хакында хакыйкать**
- **Әнвәр Шәрипов.** **Такташ һәм Сирин**
- **Мәхмүд Кашгарый.** **Диване лөгатет-төрк**
- **Фоат Закиров.** **«Казан мәгарәсе»ндә очрашу**
- **Илнур Газизуллин.** **Татарлар һәм удмуртлар**

# Әдип авылы — фотоларда

Язучылар Р.Гаташ, Р.Туфитуллова, Р.Зәйдулла, Н.Гыйматдинова һәм Р.Галиуллин Х.Туфанның Иске Кармәттәге музей-йорты янында. 2012 елның мае

**Фотолар Х.Туфанның якташы һәм кардәше, язучы Роза Туфитуллованың архивыннан алынды.**

Х.Туфан абыйсы Мөхетдиннең кызы Мөнҗия Таһирова һәм шагыйрә Нурия Измайлова белән. 1969 ел. *Н.Седов фотосы*

Хәсән Туфан туган авылы Иске Кармәттә. 1970 ел

Хәсән Туфан авылдашлары белән. Шагыйрьнең уң ягында – туганы, сабакташы, мөгаллимә Фәсыйгелбәян Галиева. 1970 ел

Безнең МИРАС

## ЯЗЫЛ һӘМ ЯҢА ЕЛГА БҮЛӘК ОТ!

**«БЕЗНЕҢ МИРАС» РЕДАКЦИЯСЕ
2021 ЕЛНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫГЫНА
ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУЧЫЛАР АРАСЫНДА БҮЛӘКЛӘР УЙНАТА:**

**· ТУЗАН СУЫРТКЫЧ · МУЛЬТИВАРКА ·
· ҖИЛӘК-ҖИМЕШ КИПТЕРҮ ҖАЙЛАНМАСЫ ·
· БЛЕНДЕР · ЭЛЕКТР ЧӘЙНЕГЕ · ҮТҮК
· һАВА ДЫМЛАНДЫРГЫЧ ·
· ФЕН · ПЫЧАКЛАР ҖЫЕЛМАСЫ ·
· КУХНЯ ТАКТАЛАРЫ ҖЫЕЛМАСЫ ·
· КАМЫР РИЗЫГЫ ПЕШЕРҮ ӨЧЕН МАХСУС САВЫТ ·**

**Бәйгедә катнашу өчен язылу квитанциясенең күчермәсен yanamiras@mail.ru электрон почтасына (хатның темасына «Язып һәм Яңа елга бүләк от» акциясенә дип язу сорала) яки элемтә бүлеге аша хат белән ошбу елның 25 декабренә кадәр юлла! Хәбәрләшү өчен телефон номерыңны да язарга онытма.**

**Җиңүчеләр 29 декабрь көнне «Безнең мирас» журналының инстаграм аккаунтында (@beznenmiras) туры эфирда ачыкланачак.**

**Искәртеп үтәбез: 3-13 декабрь көннәрендә журналга ташламалы бәядән язылырга мөмкин.**

**Яңа елда «Безнең мирас» журналыннан һәм кыйммәтле бүләктән мәхрүм калма!**

**ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru**

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»* *журналына башкача язылу:***
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»*** журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.